ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№5 (329) – МАЙ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Юдино. Хәтер һәм дан аллеясе

Шомлы чорның соңгы могиканнары

Ишми ишан: ике дәвер чигендә



16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Михаил Рябинин, Наталья Урейская,
Гадел Хәиров, Фаяз Хуҗин, Айдар Шәйхин, Луиза Янсуар
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Казан шәһәренең 155 нче гимназиясе
чыгарылыш сыйныф укучылары Зәринә Әхмәдуллина
һәм Рәмис Ярмиев. Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1150 данә,
рус телендә: 2350 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-1253
Басарга кул куелды: 24.05.2019
Басмадан чыкты: 29.05.19

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

ТӘРӘЗӘ АРТЫНДА ӨЧ МӘРТӘБӘ «УРА!» КЫЧКЫРДЫЛАР...

Май башында булды бу хәл. «Татарстан» журналы хәбәрчесе бер бик кирәкле офиска барып кермәкче булган иде, әмма төшке аш вакытына эләкте. Кояш кыздырып торган көннәр. Бер менеджердан кала, барысы да йөреп керергә чыгып киткәннәр. Тәрәзәдән Суворов училищесының плацы күренеп тора. Сәламләү авазы ап-аяз, зәп-зәңгәр күккә кадәр ишетелә, диярсең, атлап йөрүләреннән җир тетрәп тора. Суворовчылар парадка әзерләнә...

«Сөйләшеп киттек, – дип искә ала «татарстанлы». – Мин туганнарымның, «Үлемсез полк»ка кушылып, бабалары портретын күтәреп, Казан урамнары буйлап узачагы турында әйттем. Шулчак менеджер кинәт кенә гөлтләп кабынды: «Аңлый алмыйм, сезнең ул сугышка нинди катнашыгыз бар, менә?! Башкалар сугышкан һәм үлгән! Ә сез аларның яулап алган җиңүенә һәм данына мөнәсәбәтле сыман кыланасыз...»

Сискәнеп киттем. Тәрәзә артында өч тапкыр «ура» кычкырдылар. Мине бу аваз, фильмнарда күрсәткәнчә, вакыт буйлап күчешкә этәрде. Әйтерсең, кояшта уңып беткән гимнастерка – минем өстемдә, әйтерсең, нәкъ минем билемне портупея белән буып куйганнар, ә ян ягымда кобура эленеп тора. Кулым ирексездән шул кобурага таба шуды...

Әмма тынычландым да теге егетне кызганып куйдым. Ул үзе Баку татары булып чыкты. Әти-әниләре 90 нчы елларда кубарылып, күчәбез, дип чыгып киткән. Хәлләр бөтенләй мөшкелләнгәч, билгеле. Башта базарда әнисен кыйнаганнар. Аннан йорт капкасында «Чемодан – Вокзал – Россия» дигән язу пәйда булган. Башта Саратовка күченгәннәр, туганнарына, аннан – Түбән Новгородка. Соңыннан инде – Казанга. Хәзер, менә, Мәскәүгә җыеналар.

Бу яшь кенә егет – ватаны юк бер мосафир, асылда. Балачак хатирәләреннән дә юл истәлекләре, тузан, эсселек кенә сакланып калган, тагын – Каспийга барулары... Әйләнеп кайтасы килеп торган, кендек каны тамган, тәпи атлап киткән кадерле туфрагы да, болын-басулары да юк аның. Ил тарихы белән берни бәйләми бу егетне, ата-бабаларын да барлап чыгуы читен, алар кайсы кая таралган. Шуңа саклар бер генә нәрсәсе дә юк. Моннан да зуррак бәхетсезлек бармы икән, дип уйланып тордым.

Ул сөйләшү мине бик нык тетрәндерде. Үзем дә туган-тумача белән әллә ни якын аралашмыйм. Тамырларны барларга кирәк дип йөргәнем булмады. Дөнья мәшәкате, ыгы-зыгысы, дигәндәй. Бабамның фронтта һәлак булганын беләм дә, шуның белән вәссәлам. Хәтта хәрби чины, кайсы якларда сугышуы турында да ныклап сорашканым юк.

Бу хәлдән соң, кулыма диктофон тотып, фотоаппарат белән «коралланып», Җиңү проспектында яшәүче 80 яшьлек әтием янына юл тоттым...»

Журналыбызның «Буыннар» проекты – үз алдына куйган әнә шундый, кечкенә булса да, олы бурычлардан торган сәхифә. «Татарстан» хәбәрчеләре, башка бик күпләр шикелле үк, Бөек Җиңүнең оныклары һәм оныкчыклары чонки. Һәм алар, бар көчен куеп, сугыш белән тыл батырларының тарихларын сезнең өчен кабат яңартты.

СЕЗНЕҢ ВАТАНПӘРВӘР РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **930 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



«Батыр», Илдар Зарипов, 1985 ел.

МАЙ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

06. Мәңгелек ут.
Ул яңартылган
Дан аллеясендә кабынды

12. Яраткан һөнәрләр.
Эшче һөнәрләре
уңышының сере нидә

16. Татар теле.
Халыкара олимпиада
нәтиҗәләре нәрсә
турында сөйли

Тулырак
мәгълүмат
түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

20. Кардәшләребез кухнясы.
Үзбәкстан консулыннан
Сәмәрканд пылавы

**26. Үзебезнең укучыларыбыз
өчен генә!**
«Татарстан» ничек туа

32. Журналист язмалары.
Кәгазьгә төшми
калган мизгелләр

36. Мирасханә.
Беренче татар газеталары

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

40. Татар тарихы сәхифәләре.
Кол Шәриф

44. Онытыла барган исемнәр.
Кем ул Ишми ишан

56. Яфраклар ни турында серләшә.
Киләчәк паркында агачларны
кем утырткан

**60. Галәм: «шарашка»дан
күренгән манзара.**
Ни өчен Сергей Королёв атна саен
«Черек күл»гә йөргән

64. Җиңү елында туган балет.
«Шүрәле» театр сәхнәләрен
ничек яулаган

**68. «Үлемсез полк»ның
үлемсез тарихлары.**
Алар Ватан өчен көрәштеләр

74. Идеологик фронттагы хәлләр.
Алтын Урданы ни өчен тарихтан
төшереп калдырырга теләгәннәр

84. Татар авыллары.
Кзыл Яланда кунакта

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

13.05

Владимир Путин, РФ Президенты, – Татарстанда, С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы хезмәткәрләре белән сөйләшкәндә:

– Бу авыр еллар, ягъни 1990 нчы еллар уртасы, аеруча фаҗигалесе 1995 ел, безнең тарихта һәм предприятие язмышында бүтән беркайчан да кабатланмас, дип өметләнәм. Сүз уңаеннан, күренекле директор һәм авиатөзүче, элеккеге генераль директор Копыловның истәлеген мәңгеләштерү дөрес булыр иде.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

14.05

Илсур Метшин, Казан мэры, – каты коммуналь калдыкларны аерым җыюны гамәлгә кертү мәсьәләләре буенча шәһәр штабы утырышында:

– Калдыкларны аерым җыю – бу бөтен ил күләмендәге глобаль тема... Җәй дәвамында без инфраструктура әзерләүне төгәлләргә тиеш. Һәм иң мөһиме – халыкны мотивацияләү. Велосипед уйлап чыгарырга кирәкми, аны безгә кадәр уйлап тапканнар инде. Бу юлны уртача 10 елда үткән төбәкләр, илләр бар. Әмма без вакытны кыса төшәргә һәм, чүпне аерым җыю культурасы буенча бөтенләй башка дәрәҗәдә булыр өчен, бу юлны 3–4 елда үтәргә тиеш.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

12.05

Владимир Яковлев, Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының сәнгать җитәкчесе, – Рудольф Нуриев исемендәге XXXII Халыкара классик балет фестивале ачылышы алдыннан:

– Фестиваль хәрәкәтен әле башлаган гына чакта, безне әле чит илләргә чакырмаганда, Казанга Зур театрдан биюче китерү – хәтта ул солист булмаса да – бөтен кеше өчен чын могҗизага тиң иде. Хәтеремдә, ул әле сәхнәгә чыга гына (Мәскәү, Зур театр!), ә анда барысы да инде алкышлый. Хәзер – юк. Хәзер – син башта күрсәт әле үзеңне, бәлки безнекеләрдән начаррак биисеңдер.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Дан аллеяләре **КАЙДА** барлыкка килә

Эшче профессияләренең сере **НӘРСӘДӘ**

Татар теле олимпиадасында **КЕМНӘР** җиңә

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2019 елның
II яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 930 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 930 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7076 **татар телендә**

П 7077 **рус телендә**

Реклама 16+



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә… Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

ЮДИНО.
ХӘТЕР ҺӘМ ДАН АЛЛЕЯСЕ

НӘРСӘ:

Яңартылган Дан аллеясен ачу

КАЙДА:

Юдино бистәсе

КАЙЧАН:

8 май

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Татарстан фронтка 600 төрдән артык хәрби продукция җибәреп тора. Һәр алтынчы самолёт бездә җыела. Дары заводы фронтка 200 мең тоннадан артык дары озата. Авылларыбыз фронтны азык-төлек белән тәэмин итеп тора. Монда ике мәктәп базасында госпиталь оештырыла. Һәркем сугыш кырында яисә җитештерүдә үз хезмәте белән Җиңүне якынайта.

Фото: Татарстан Президентының рәсми сайты

ТУЛЫРАК:

Тантаналы ачылыш буласы көн алдыннан тимер юлчылар Казанга Мәңгелек утны Кремль стенасы янындагы Билгесез солдат кабереннән кабызып алып кайттылар. Юдинода Гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар истәлегенә багышланган мемориалдагы Мәңгелек утны кабызу тантанасы узды. Мәңгелек утны хезмәт ветераны, мактаулы тимер юлчы Николай Ковалев һәм Россия Герое Марат Әхмәтшинның улы, Казан Суворов училищесында тәрбияләнүче Әмир Әхмәтшин кабыздылар.

Тантанада катнашучыларга сәламләү сүзе белән Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов мөрәҗәгать итте: «Хөрмәтле Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, Юдино бистәсе кешеләре! Бүген без иң зур һәм күркәм бәйрәмебез Җиңү көне алдыннан яңартылган Дан аллеясен ачабыз. Бу – Җиңү өчен гомерләрен дә кызганмаганнарга, көн-төн тырышып хезмәт иткәннәргә безнең олы ихтирамыбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов. Ул шулай ук Бөек Ватан сугышы башланганнан бирле 700 меңләп татарстанлының фронтка киткәнлеген, шуларның яртысының гына әйләнеп кайтканлыгын искәртеп үтте: «Без үз каһарманнарыбызны онытмаска тиеш. Яңартылган аллея алар истәлегенә».

Бүген Юдино бистәсе актив рәвештә яңара бара. Моңа Юдиноның узган ел билгеләп үтелгән 100 еллыгы да этәргеч бирде, дип билгеләп үтте Президент. «Хәзер спорт үзәген яңарту эшләре алып барыла, Мәдәният сарае торгызылачак, Боз сарае эшли, – дип искә төшерде Президент. – Яңартылган аллея шәһәрлеләр ял итәргә йөри торган урынга әйләнергә тиеш, бу бик мөһим. Юдино бистәсендә тормыш сыйфатын яхшырту, реконструкцияләү буенча планнарыбыз зурдан».

Аннары ветераннарга һәм тантанада катнашучыларга сәламләү сүзләре белән Горький тимер юлы башлыгы Анатолий Лесун, Казан мэры Илсур Метшин мөрәҗәгать иттеләр.

«1941 елда нәкъ менә Юдино аша Казан Бөек Ватан сугышының башлануы турында белде, – дип искә төшерде Казан мэры Илсур Метшин. – Нәкъ менә бирегә беренче хәбәр килде – тимер юлчылар вагоннарны Көнбатыш чикләр юнәлешендә җибәрмәскә тиеш иде».

Тантаналы чарада катнашучылар мемориалга чәчәкләр салдылар. Почетлы каравыл ротасы өч мәртәбә залп бирде.

Анатолий Лесун, Горький тимер юлы башлыгы:
– Бөек Ватан сугышы елларында Юдино тимер юлчылары өлешенә авыр хезмәт туры килә. Инде 1941 елның ноябрендә үк Көнчыгыштан, Себердән, Уралдан килгән эшелоннарны кабул итү буенча төп йөкләнеш нәкъ менә Казан магистраленә туры килә.

КАЗАН.
ҖИҢҮ ПАРАДЫ

НӘРСӘ:

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 74 еллыгына багышланган бәйрәм парады

КАЙДА:

Казан, Меңьеллык мәйданы

КАЙЧАН:

9 май

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Хөрмәтле ветераннар! Без сезнең белән горурланабыз һәм батырлыгыгызга сокланабыз. Сезнең тормышыгыз, язмышыгыз – безнең өчен һәм киләчәк буыннар өчен үрнәк. Без сезнең васыятегезне һәрвакыт үтәрбез, халкыбыз традицияләрен дәвам итәрбез, тынычлык, яхшылык һәм гаделлек идеалларына тугрылыгыбызны сакларбыз, күпмилләтле Ватаныбызның куркынычсызлыгын һәм иминлеген саклауны тәэмин итәрбез.

Фото ТР Президентының рәсми сайтыннан (Рөстәм Кадыйров)

ТУЛЫРАК:

Татарстан Президенты бәйрәмгә җыелучылар каршында чыгыш ясады. «Хөрмәтле парадта катнашучылар! Сугыш ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре! Казан гарнизоны хәрбиләре! Татарстан халкы һәм кунаклар! Сезне чын күңелдән Бөек Җиңү көне белән котлыйм! 74 ел элек фашизм совет халкының батырлыгы һәм бердәмлеге, аның бөек сугышчан һәм хезмәт батырлыгы каршында берсүзсез җиңелүен таныды. Ул чакта барлык илләр, барлык халыклар нәкъ менә Советлар Союзының, безнең Кызыл Армиянең һәм күпмилләтле совет халкының Икенче бөтендөнья сугышының нәтиҗәләрен билгеләвен аңлады», – диде ТР Президенты. Ул совет халкының дәүләтләргә һәм халыкларга каршы түгел, бәлки нацизмның варварлыгына, аның кешелексезлегенә каршы көрәшүенә басым ясады. Бөек Җиңү гаять авыр, кайтарып булмаслык зыян, ачы югалтулар бәрабәренә яуланды. «Без сугыш кырыннан кайтмый калучыларның якты истәлеге каршында башыбызны иябез, бүген янәшәбездә булмаганнар турында кайгырабыз. Сугыш геройлары һәрвакыт безнең күңелләрдә яши, алар – «Үлемсез полк» сафларында, һәйкәлләрдә һәм мемориалларда», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент Татарстан Республикасында Җиңүче сугышчыга һәйкәл ясау буенча иң яхшы проектка конкурс игълан ителүен җиткерде. Һәйкәл совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенең 75 еллыгына багышлана һәм Казан шәһәрендәге Җиңү паркында урнаштырылачак.

«Хөрмәтле ветераннар! Без сезнең белән горурланабыз һәм батырлыгыгызга сокланабыз. Сезнең тормышыгыз, язмышыгыз – безнең өчен һәм киләчәк буыннар өчен үрнәк. Без сезнең васыятегезне һәрвакыт үтәрбез, халкыбыз традицияләрен дәвам итәрбез, тынычлык, яхшылык һәм гаделлек идеалларына тугрылыгыбызны саклрбыз, күпмилләтле Ватаныбызның куркынычсызлыгын һәм иминлеген саклауны тәэмин итәрбез», – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов.

«Яшәсен безнең Җиңү! Җиңүче халыкка дан! Бөек Җиңү көне белән! Ура!» – дип тәмамлады үзенең чыгышын Рөстәм Миңнеханов. Аннан соң Татарстан Республикасының Дәүләт гимны яңгырады.

Аннан соң Казан гарнизоны башлыгы, генерал-майор Кирилл Кулаков парад исәбе гаскәрләрен карап узды һәм Татарстан Президентына парадка әзерлек турында хәбәр итте. Меңьеллык мәйданы буйлап Казан гарнизоны гаскәрләре, ЭЭМ һәм ГТХМ хезмәткәрләре, Казан хәрби училищелары, республика иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре, студентлар узды. Аларга хәрби техника, ретро-автомобиль колонналары кушылды.

Шул ук көнне Рөстәм Миңнеханов «Үлемсез полк» сафларында атлады. Ул үзенең туганы – фронтка 19 яшьлек егет булып китеп, 1941 елның 15 декабрендә һәлак булган Галимҗан Миңнехан улы Миңнеханов портретын алып чыкты.

БЕЛЕШМӘ:

Быел «Үлемсез полк» хәрәкәтенә 170 мең казанлы һәм башкала кунагы кушылды. «Үлемсез полк» шулай ук республиканың барлык шәһәрләрендә һәм районнарында үтте.

Фото: Александр Ефремов

ҖИҢҮ ПАРКЫ. МӘҢГЕЛЕК УТКА ЧӘЧӘКЛӘР САЛУ

НӘРСӘ:

Җиңү паркындагы Мәңгелек утка чәчәкләр салу

КАЙДА:

Казан

КАЙЧАН:

Җиңү көне, 9 май

Фотолар ТР Президентының рәсми сайтыннан (Марсель Бадыйкшин)

ТУЛЫРАК:

Казандагы Җиңү паркында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ветераннарны Бөек Җиңүнең 74 еллыгы белән котлады һәм Дан мемориалы коллоннадасындагы Мәңгелек утка чәчәкләр салды. Тантаналы чарада шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Алексей Песошин, Бөек Ватан сугышы ветераны, Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов һәм башкалар катнашты. Тантанада катнашучылар сугыш кырларында һәлак булганнарны бер минут тынлык белән искә алдылар. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт гимннары яңгырады. Казан горнизонының мактаулы караул ротасы марш белән узды. Аннан соң рәсми затлар һәм катнашучылар һәлак булган солдатларның Аналары һәм тол хатыннары һәйкәленә чәчәкләр салды.

Рөстәм Миңнеханов Җиңү паркында урнаштырылган яңа һәйкәл – тыл хезмәтчәннәре һәйкәлен карады. Һәйкәл курган формасында, анда кылыч салынган сандал һәм бодай башаклары сурәтләнгән. Татарстан Президенты мемориалны эшләп бетерергә һәм анда уртак Җиңүгә зур өлеш керткән предприятиеләрнең исемнәрен дә мәңгеләштерергә тәкъдим итте.

Тагын бер мемориал, «Казан» К-403 су асты көймәсе рубкасы, янындагы чарада катнашучыларны Хәрби-диңгез флоты ветераннары һәм кадетлар көтә иде. Кыска гына әңгәмә, һәм тантаналы чара бергәләп фотога төшү белән тәмамланды.

БЕЛЕШМӘ:

Җиңү паркында Рөстәм Миңнеханов «СОЮЗ-2019 – Җиңү варислары» дип аталган XVI Бөтенроссия хәрби-спорт оешмаларының һәм кадет корпусларының яшьләр белем бирү җыенында катнашучылар белән аралашты. Әлеге форум Татарстанда ТР Президенты химаясендә узды. Чарага 600дән артык катнашучыны туплаган 40 команда җыелды. Алар Россиянең төрле төбәкләреннән: Чукоткадан, Якутиядән, Сахалиннан, Башкортостаннан, Чувашиядән, Удмуртиядән, Әстерхан, Мәскәү, Ростов, Свердловск, Псков, Самара өлкәләреннән, Владивостоктан, Мурманскидан һ.б. шәһәрләрдән килгәннәр иде. Җыен Бөек Ватан сугышы турындагы хатирәләрне саклауга һәм совет гаскәрләренең Әфганстаннан чыгарылуының 30 еллыгына багышланды. Асылы белән ул интернациональ, социаль һәм берләштерүче патриотик проект булып тора. Максаты – тарихи үткәннәр нигезендә тынычлык хөкем сөргән, дустанә пространство тудыру. Ул үзара хөрмәтне, Россиянең бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән уртак кыйммәтләр тупланмасын чагылдырган пространство булырга тиеш.

«СОЮЗ-2019 – Җиңү варислары» җыенында катнашучылар тамашачыларга үзләренең концерт программаларын – Россия халыкларының үзенчәлекле җырларын һәм биюләрен тәкъдим иттеләр.



Фото: Ната Смирнова

ЭЛЕМТӘ
ОСТАСЫ

Владимир Якимов, «Россия телевидение һәм радиотапшырулар челтәре» Федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы – «Татарстан Республикасы радиотелевизион тапшырулар үзәге» директоры

1. Мин Югары Осланда тудым. Армиядә хезмәт итеп кайткач, Казан элемтә электротехникумына «Телевизион техника һәм радиорелеле элемтә» белгечлегенә укырга кердем. Радиотехника өлкәсе бик кызыктыра иде мине. 1973 елда аны кызыл диплом белән тәмамладым һәм шунда эшкә калдым. Параллель рәвештә Куйбышев шәһәрендәге (элек Самара шулай атала иде) электротехник элемтә институтында белем туплауны дәвам иттердем.

2. Техникумда алган белемнәр ярдәме белән шунда ук карьера үсеше дә башланды: әүвәл – лаборант, аннары студентлар профкомы рәисе, соңрак техникумның радио бүлеге мөдире һәм директор урынбасары булып эшләдем. Радиоэлемтә һәм радиотапшырулар инженеры һөнәре мине Татарстан Республикасы Элемтә министрлыгына алып килде. 1998 елда Татарстан Элемтә министрының радио һәм телевидение буенча урынбасары булдым, ә 2005 елда Татарстан Республикасы Элемтә министрлыгының Радиотелевизион тапшыру үзәген җитәкләдем. Һәм бүген, «Россия телевидение һәм радиотапшырулар челтәре» Федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы – «Татарстан Республикасы радиотелевизион тапшыру үзәге» директоры булып эшләгәндә, предприятиебезнең минем дә өлешем кергән уңышларын һәм яулаган үрләрен профессиональ горурлык белән исәпләп чыга алам. Алар барысы да – киң колачлы һәм республика өчен гаять әһәмиятле эшләр. Мәсәлән, 2004 елда без, Россия Федерациясендә беренчеләрдән булып, «Татарстан – Яңа гасыр» республика программасы өчен ясалма иярчен элемтәсенә тоташу мөмкинлеге белән телерадиотапшырулар челтәре төзегән идек. Ә 2018 елда Татарстанда заманча цифрлы телевизион эфир тапшырулар челтәре төзелеше тәмамланды, бу исә Татарстан Республикасының бөтен халкына цифрлы форматта 20 телевидение программасын иркен кабул итү мөмкинлеге бирде.

3. Сезгә, әле бар тормышы алда торган егет-кызларга, нәрсә телим икән? Сез беренче мөһим адымны ясагансыз – үз һөнәрегезне сайлагансыз. Аңа хыянәт итмәгез, ул сезне гомер буена озата килсен. Аны яратыгыз, чөнки күңел ятмаган һөнәр белән яшәү күңелсез һәм кызыксыз булачак. Каторгага барган кебек эшкә йөрүне дошманыма да теләмәс идем. Әгәр һөнәрегез ошый икән, сез, һичшиксез, уңышка ирешерсез, үз өлкәгездә иң яхшысы булырсыз, эшкә бик теләп йөрерсез, сездә һәрвакыт яңа һәм кызыклы идеяләр туып торыр. Мин сезгә бу чемпионатта җиңү телим, чөнки профессиональ җиңү – һөнәри үсешкә беренче ачкыч ул. Уңышлар сезгә!

«РТРЧ» филиалы –
«Татарстан Республикасы РТҮ»
420029, Россия, Казан шәһәре,
Троицкий лес ур., 29 нчы йорт.
Тел.: +7 (843) 239-20-49,
факс: +7 (843) 273-45-32.
tatarstan@rtrn.ru www.tatariya.rtrs.ru

Реклама

Фотолар Вера Кузьминаның шәхси архивыннан алынды

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ЯРДӘМ ПСИХОЛОГИЯСЕ

Вера Кузьмина, 175 нче балалар бакчасы психологы, клиник психолог. Россия профессиональ психотерапевтлар лигасы әгъзасы.

1. Һөнәри белемне Краснодарда алдым – 1997 елда «Шәфкать туташы» белгечлеге буенча медицина училищесын, аннары «Психология укытучысы һәм гамәли психолог» белгечлеге буенча педагогика институтын тәмамладым. Ул вакытта миңа кеше аңының ни яшерүе һәм баш миебезнең без белмәгән нинди функцияләр башкаруы кызык иде. Краснодар краенда мин әлеге төбәкнең Социаль яклау департаментындагы гаиләгә, балаларга һәм өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге баш белгече булып эшләдем. Эш миңа рәхәтлек бирә иде, чөнки мин кешеләргә, бигрәк тә халыкның яклауга мохтаҗ өлешенә, балаларга һәм өлкәннәргә, чын мәгънәсендә ярдәм итү теләгемне тормышка ашырдым.

2. Казанга күчкәч, психолог буларак эшемне яңадан дәвам итү кирәклеген бар күңелем белән тойдым. Казан дәүләт медицина университетында «Клиник психолог» белгечлеге буенча икенче югары белем алдым. «Психологик психотерапия фәне һәм практикасы карашыннан чор таләпләре», «Гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән затларга, шул исәптән турыдан-туры һәлакәт вакытында мохтаҗлык кичергән кешеләргә психологик ярдәм күрсәтү формалары һәм ысуллары», «Рәхимсез мөгамәлә, гаиләдә көчләү кебек очракларда балаларга һәм аларның ата-аналарына ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү», «Инклюзив белем бирүдә буыннар бәйләнеше системасы», «Мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирүнең актуаль проблемалары» кебек фәнни-гамәли конференцияләрдә һәм семинарларда даими катнашып килдем. «Мәктәпкәчә белем бирүнең актуаль проблемалары» җыентыгында мәкаләләр бастырып чыгардым. Шулай ук сәламәтлегендә төрле тайпылышлар булган, авырулардан җәфа күргән балалар белән дә эшләргә туры килде. Һөнәри казанышларым дип кешеләргә күрсәтелгән ярдәмне саныйм: күп еллар гаиләләргә һәм балаларга ярдәм итү бүлегендә эшләдем, гадәттән тыш хәлләргә тарыган кешеләргә ашыгыч психологик ярдәм күрсәттем, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән хезмәттәшлек иттем. Ә иң зур шәхси казанышым исә – балаларым – алар миндә өчәү!



3. WorldSkills-2019 чемпионатының һәр катнашучысы үз планнарын тормышка ашырыр дип өметләнәм. Бер акыл иясе: «Нәрсәне дә булса бик телисез икән, ике арага тартылу законы керә», – дигән. Киләчәгегезне, тирә-юнегезне һәм чынбарлыкны сез үзегез булдыра аласыз. Үз-үзегезгә дә, тирә-юньдәгеләргә дә колак салыгыз. Тормыш юлында күп төрле кешеләр очратырсыз. Шуны истә тотыгыз, тәнкыйть һәм киңәшләрне тыныч кына кабул итә белергә кирәк, нинди генә очрак булса да, алардан тәҗрибә алачаксыз. Чөнки тормышыгызда очраган һәр кеше – укытучыгыз ул.



LADY VERA PSY

Клиник психолог:
+79600494402
verkyz25@yandex.ru

Реклама

«ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНЕРГӘ БЕРКАЙЧАН ДА СОҢ ТҮГЕЛ!»

«Юк, эшләр без уйлаганчы ук мөшкел түгел, туган телебезне яхшы белүче, өйрәнергә теләүчеләр күп икән бит!» Татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиаданың ябылу тантанасыннан шулай дип кайттым. Анда барысы да татарча гына аралашты. (Чит төбәкләрдән, чит илләрдән килгән яшьләр дә күп иде). Шунда ишеткән иң кызыклы фикерләрне журналыбыз укучыларына да тәкъдим итәбез.

Автор:
Руфия Фазылова

«РУСЛАРНЫҢ КҮБЕСЕ ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕННӘН БАШ ТАРТМАДЫ»

Алена Фәхретдинова, Казан. Авиатөзелеш районының 37нче гимназия укытучысы:
– Безнең мәктәптә 1040 укучы белем ала. Шуларның 496сы туган тел дәресе итеп татар телен сайлады. Иң кызыгы: ул укучыларның күбесе милләте буенча руслар. Ә татарлар рус телен укый.

Сәгатьләр саны кимегәнче, безнең мәктәптә 11 татар теле укытучысы бар иде. Бүген без бишәү генә калдык. Алты укытучының икесе башка мәктәпкә китте, калганнары бүтән фәннәр укыта.

Бу чарага мин 8 нче сыйныфта укучым Катя Потапованы алып килдем. Ул икенче ел инде рус мәктәпләрендәге рус төркемнәренең татар теле буенча республика олимпиадасында җиңүчеләр рәтендә. Катя бик талантлы бала. Барлык фәннәрне дә яхшы белә, шул исәптән татар телен дә. Аннары аның гаиләсе турында да әйтәсем килә. Кызның әти-әнисе татарларны бик нык хөрмәт итә, аеруча – әтисе. Ун ел бергә татарлар белән бер бригадада эшләгән. Мәктәпкә гариза язарга килгәч: «Без балабызның татарча укуын бик телибез, иң беренче булып безне языгыз», – диде. Ата кешенең якын дусты да татар икән, гаиләләре белән бик дуслар. Республика олимпиадасында Катя «Күршеләр дуслыгы» дигән проект яклады. Ул анда ялкынланып: «Руслар, татарлар – бу ике милләт инде гасырлар буе бергә яшәп, туганлашып бетте. Шуңа бер-беребезнең гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә, ә телне белергә тиешбез», – диде. Бу вакытта аңа бөтен кеше кул чапты. Үсмер кыз ул җөмләләрне матур сүз өчен генә сөйләми, ә чынлап та шулай уйлый. Һәм эш-гамәлләре белән моны раслый.

«ИКЕ УЛЫМ ДА БЕР ДИГӘН ИТЕП ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘ»

Зөлфия Каадер, Финляндия. Ильяс белән Касыймның әнисе, 18 ел элек Финляндия татарына кияүгә чыккан:
– Татарстаннан читтә яшәсәк тә, ике улым – Ильяс белән Касыймны – татарча укырга, сөйләшергә өйрәттем. Юк, мин моны батырлыкка санамыйм, дөрес аңлагыз. Бары сөенечем белән генә уртаклашам. Балалар тагын фин, швед, инглиз, немец, француз телләрен яхшы белә.

Ирем – фин татары. Аның да татарчасы әйбәт. Гаиләдә гел татар-

ча сөйләшәбез, улларыбызның ана телләрен белүләре – шуның нәтиҗәседер. Олы улыбыз Ильяс узган елгы Татар теле һәм әдәбияты халыкара олимпиадасында Гран-прига ия булган иде. Касыйм әле алай ук булдыра алмады. Хәер, без монда җиңү артыннан килмәдек. Янә бер кат туганнар белән очраштык, Касыйм яңа дуслар тапты. Иң кыйммәтлесе шул.

Без Тампере шәһәрендә яшибез. Ул зурлыгы буенча Хельсинкидан соң икенче урында тора. Хельсинкада татарларның рәсми җәмгыятьләре бар. Алар еш кына очрашалар, төрле кичәләр үткәрәләр. Тампереда да татарлар җыела торган үзәк бар. Мин анда элек төрле кичәләр оештыра идем. Хәзер бездән башка гына эшлиләр.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә зур рәхмәтемне җиткерәм. Татар теленнән халыкара олимпиада үткәрү төрле илләрдә яшәүче татар балаларын берләштерә. Тагын әле белемнәрен дә арттыра. Мисал өчен, без олимпиадага ай буе әзерләндек. Шул рәвешле Касыймның татар теле тагын да ныгыды...

«ТАТАРЛАР – ИҢ КУНАКЧЫЛ ХАЛЫК!»

Чихиро Тагучи, Бөекбритания, (Татар теле һәм әдәбияты буенча VII халыкара олимпиаданың Гран-при иясе)

– Мине күргәч, күпләр Япония вәкиле дип уйлый. Ни өчен дигәндә, узган елгы олимпиадада туган ягым – Япония студенты буларак катнаштым. Ә быел мин Лондон университетының лингвистика бүлегендә укыйм. Токиодагы Кэйо университетын тәмамлагач, шунда киттем. Бер еллык курс ул. Июль аенда яңадан туган ягыма кайтачакмын. Япон теленнән тыш, инглизчә, немецча, французча һәм әрмәнчә, азрак русча беләм. Аеруча төрки телләр белән кызыксынам. Татар теле дә – төрки телләрнең берсе, шуңа татарча өйрәнергә теләк туды. Бер дә авыр булмады.

Токиода татар теле курслары бар. Анда бүген егермеләп кеше йөри. Аның җитәкчесе Гөлнара Карасова, минем белән аерым да шөгыльләнде. Тагын татар телен «Ана теле» онлайн-мәктәбе аша өйрәндем.

Бөекбританиядә меңнән артык татар бар дип беләм. Иң күбе Лондонда яши. Атна саен татар теле дәресләре үткәрәләр. Шулай ук татар клубы эшли. Клубта бары татарча гына сөйләшергә әйтәләр. Берәрсе русча яки инглизчә сөйләшсә: «Монда татарча гына сөйләшәләр»,– дип кисәтү ясыйлар. Мин анда атна саен барырга тырышам. Татар җырларын тыңлыйм, аралашам. Шул рәвешле телем шомара. Лондон татарлары гореф-гадәтләрне бик тырышып саклый, хәтта Япониядә яшәүче татарларга караганда да яхшырак итеп. Алар бөтен милли бәйрәмнәрне үткәрәләр, бер-берсе белән тату яшиләр.

Дөресен генә әйткәндә, татар теле минем өчен хәзер туган телем кебек якын. Моңа бәлки узган ел Казанга килеп, күп татар яшьләре белән аралашу да йогынты ясагандыр. Сез – иң кунакчыл, гади халык!

Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин:

– Мин 45 яшемә кадәр татар телен белмәдем. Әти-әнием татар, мин дә татар бит, дип, туган телемне өйрәнергә булдым. Рус авылында бердәнбер татар гаиләсе идек без. Үсмер чакта мине «татарин» дип үртәделәр. Шулвакыт бик гарьләнә идем...

Туган телемне соңрак максатчан рәвештә өйрәндем. Эштән кайткач, көзге янына басып, татарча газеталар укыдым. Аңламаган сүзләрнең мәгънәсен хезмәттәшләремнән сорадым. Бу эштә миңа Туфан Миңнуллин һәм Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев һәм башка шәхесләр булышты. Әйе, туган телеңдә, әби-бабайлар телендә сөйләшсәң, үзеңне бөтенләй икенче төрле хис итәсең. Монысы – бәхәссез.

Мин бүген сезнең белән горурланып утырдым. Телне саклап калган, кызыксынучан татар балаларын җиденче тапкыр җыеп, дуслашырып, сезгә күрсәтә алдык – шуңа сөенәм. Шөкер, Татарстанда татарча сөйләшүче милләттәшләребез арта бара. Сәхнәдә, театрда, парламентта, район-шәһәр советларында ике дәүләт телендә сөйләшергә мөмкинлек тудырылган. Дөньяда татар телендә сөйләшүчеләр тагын да артыр дип ышанам...».

САННАР

Татар теленнән халыкара олимпиаданың йомгаклау өлешендә Татарстан мәктәпләреннән – 232, чит илләрдән – 37, Россия төбәкләре һәм якшәмбе мәктәпләреннән 191 кеше катнашты. Республика һәм илнең төрле төбәкләреннән 40 студент көч сынашты.

УҢЫШКА АЧКЫЧ – ТОТРЫКЛЫ СЫЙФАТ

«KUKMARA» бренды нәрсәне аңлата соң? Әлеге бренд бүген бөтен дөнья хуҗабикәләренә дә таныш дип әйтергә була. Кукмара металл савыт-саба заводы савыт-саба – ризык әзерләү өчен каралган гади предмет дигән стереотипны зур уңыш белән җимерде. Вакыт белән сыналган сыйфат һәм ышанычлылык бердә эшләнә торган көйдерми торган өслекле савыт-сабаның, туризм һәм ял өчен билгеләнгән товарлар, ипи формаларының һичшиксез өстенлекләре санала.

Фото Кукмара тимер савыт-саба заводыннан алынды

Реклама

Кукмара металл савыт-саба заводының дус-тату коллективы хезмәткәрләре Садриев Ринат Билаловичны чын күңелдән «Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирелүе белән тәбрик итә, аңа оптимизм һәм күтәренке кәеф, эшендә уңышлар тели!

Соңгы чиратта продукция кулланучының сәламәтлегенә бәйле шундый җитди җитештерү нигезләрен салу өчен, әлбәттә, предприятие җитәкчеләренең компетенциясе мөһим. Әйтик, аларның кешеләр белән эшләү тәҗрибәсе һәм перспективаларны күрә белү сәләте.

Шундыйларның берсе – заводның техник директоры Ринат Садриев. Предприятиегә ул катлаулы 90нчы елларда килә. Күп яктан аның тырышлыгы бәрабәренә предприятие икътисадый кризис елларын исән-имин үтеп, үзенең иң яхшы эшчеләрен һәм белгечләрен саклап кала алды. Еллар үтә барган саен завод республиканың иң танылган брендларының берсенә әверелде. Әлеге уңышның сере – дөрес стратегия һәм тактиканы кора белүдә. Бу яктан Ринат Билалович һәрвакыт аерылып торды. Предприятиедә шактый зур реконструкция үткәрелде, цехлар модернизация кичерде, әзер продукцияне транспортлауның автоматлаштырылган системасы эшли башлады, көйдерми торган өслекне кою һәм савыт-сабага ягу технологиясе камилләштерелде...

Бүген техник директор предприятиене киңәйтү буенча яңа зур проектны гамәлгә ашыра – «Кукмара» сәнәгать паркы территориясендә 500 эш урынына исәпләнгән яңа, заманча завод төзү планлаштырыла. Бу продукцияне озату географиясен тагын да киңәйтергә, сату буенча яңа каналлар ачарга, сакчыл җитештерү ысулларын һәм методларын гамәлгә кертергә мөмкинлек бирәчәк. Шул ук вакытта төп стратегик линия – кулланучылар мәнфәгатьләрен кайгыртуга максималь юнәлеш алу – үзгәрешсез кала.

Бүген «Кукмара металл савыт-саба заводы» ААҖ – кою ысулы белән ясалган алюминий савыт-саба җитештерү буенча Россиядә әйдәп баручы предприятие.

Предприятие продукциясен озату географиясе – Россиянең 85 төбәге, тугыз якын чит ил, алты ерак чит ил: Израиль, АКШ, Канада, Германия, Венгрия, Кытай. Кукмара савыт-сабасын кайда гына кулланмасыннар, ул һәрвакыт бик яхшы бәя генә ала!

Kukmara®
Сделано в России

«Кукмара металл савыт-саба заводы» ААҖ

ВКонтактеда: vk.com/kukmara
Инстаграмда: kukmara_posuda
Одноклассникиларда: ok.ru/kukmara

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Үзбәкстан **НИЧЕК** Татарстанда пәйда булды

Журналист тормышында **НИНДИ** кызык хәлләр була

«Татарстан» журналы **НИЧЕК** басыла

Беренче татар газетасы **КАЙДА** басылган

Фото: Ната Смирнова

ҮЗБӘКСТАН КОНСУЛЫ ПЕШЕРГӘН *Үзбәк пылавы*

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

«Татарстан» журналының редакция кухнясына кунакка бүген кояшлы Үзбәкстан ватандашы килде. Фәриддин Насрыев – Үзбәкстан Республикасының Казандагы Генераль консулы. Һәм ул пылау пешерә. Без күнеккән гади генә пылау белән түгел, ә бәлки чын Сәмәрканд пылавы белән сыйларга ниятли!

Автор:
Татьяна Вафина

ИҢ ЯХШЫ ЙӨЗ ЫСУЛ АРАСЫНДА ИҢ ШӘБЕ

– Наманган, Әндиҗан, Фиргانә, Маргилан, Кокандта, шулай ук алар янәшәсендәге Сырдәрья, Зәрәфшан, Амударья җирләрендә урнашкан кышлакларда, борынгы Бохара һәм Сәмәрканд шәһәрләрендә пылау әзерләүнең йөзләрчә ысулы мәгълүм. Мин үзем борынгы Сәмәрканд шәһәреннән, шунлыктан нәкъ үзебезчә әзерләнгәнен яратам, – ди безнең ашчыбыз. – Без өйдә аны еш пешерәбез. Бүген дә мин сезне Сәмәрканд пылавы белән сыйлаячакмын.

– Ул Үзбәкстанда әзерләнә торган башка йөзләрчә төрле пылаудан нәрсәсе белән аерыла соң?

– Бөтен нәрсәсе белән! Дөге сортыннан алып, табынга ничек бирелүенә кадәр. Сәмәрканд пылавы табынга менә болай тәкъдим ителә: башта ләгәнгә өеп дөге салына, аннары кишер, иң өскә исә вак кисәкләргә туралган ит өелә. Болгатылмый! Бик матур һәм искиткеч тәмле килеп чыга.

– Сез ашарга пешерергә яратасыз ахрысы...

– Дөресен генә әйткәндә, бик яратып бетермим. Чөнки ризык әзерләү – иҗади процесс ул, бер дә ашыгырга ярамый. Минем исә вакытым тыгыз. Вакыт булганда нигә пешермәскә, ди?! Мин тәмле аш пешерә беләм – балаларыма бик ошый. Кайвакыт аларга өреле шурпа әзерлим, ул җиренә җитеп пешсен өчен, 3–4 сәгать вакыт кирәк. Тиз генә ашарга әзерләргә кирәк булса, флотча макарон пешерәм, аныСына ярты сәгать вакыт та җитә!

– Ә флотча макаронны үзбәкчә пешерәсезме?

– Безнең макарон сезнекеннән бернәрсәсе белән дә аерылмый диярлек. Безнекенең ите генә тәмлерәк һәм тәмләткечләре күбрәк.

– Ә ите ни өчен тәмлерәк?

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ



ҮЗБӘКСТАННЫҢ КАЗАНДАГЫ ГЕНЕРАЛЬ КОНСУЛЫННАН КУЛИНАРИЯ КИҢӘШЕ:

Чистартылган һәм юылган дөгене тозлы суда бераз гына бүрттерегез. Бу аны таралып тора торган итәчәк.

Безгә кирәк булачак:

- «Девзира» дөгесе – 1 кг;
- Сыер ите – 1200 г;
- Кишер – 800 г;
- Суган – 400 г;
- Май – 300 г;
- Сарымсак – 4 баш;
- Тоз, зира, бөртекле кара борыч – тәменчә.

– Безнең терлекләр көтүлекләрдә йөри, комбиазык түгел, үлән ашый. Үзбәкстанда кояшлы көннәр күбрәк, кар юк диярлек. Елына 2–3 тапкыр ява да, тиздән эреп тә бетә. Яңгырлы кыш... Шундый уңайлырак һава шартлары булганга, ит тәмлерәктер дә, мөгаен.

– Сез бирегә карны сагынганга килдегезме? Җылы илдән салкынга күчәсегез килдемени?

– Дипломатлар илне сайламый. Без, илебезнең ватанпәрвәрләре буларак, кушкан җиргә барабыз.

– Дипломатлар үзләре эшләгән илдәге халык ашларына нинди мөнәсәбәттә соң?

– Татар халык ризыклары миңа инде күптәннән ошый. Мин Казанга килгәнче дә татар ашларыннан күп тапкырлар авыз иттем. Үзбәкстанда 300 меңнән артыграк татар яши. Минем татар дусларым бик күп, аларда еш кына кунакта булганым да, сыйланганым да бар. Биредә әлеге ризыклар тагын да тәмлерәк. Мин өчпочмак яратам, бездә дә шундый өч почмаклы самса пешерәләр, тик аның эчлеге ит һәм суганнан, татар ризыгында исә ит белән бәрәңгедән ясала. Камыры да башкарак, тик бик тәмле.

ТАРИХИ ВИЗИТ

Казанда кыза торган итнең искиткеч хуш исеннән исереп, Татарстанны Үзбәкстан белән нинди мөнәсәбәтләр бәйләвен искә төшерәбез.

– 2018 елның октябрендә Владимир Путин Үзбәкстанга дәүләт сәфәре кылды. Моны тарихи сәфәр дип әйтеп була. 27 миллиард АКШ долларыннан артыграк суммага килешүләр имзаланды. Һәм шул сәфәр кысаларында Россия Федерациясе белән Үзбәкстан Республикасының беренче төбәкара форумы оештырылды. Үзбәкстанда үткән шул тәүге форумда актив катнашулары өчен без Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановка, Татарстан Хөкүмәтенә рәхмәтлебез. Узган ел нәтиҗәләреннән күренгәнчә, безнең товар әйләнеше арткан һәм 146 миллион долларга җиткән. Без төрле өлкәләрдә хезмәттәшлек итәбез, шул исәптән нефть-газ сферасында да, нефть химиясе тармагында да, фармацевтика һәм туку сәнәгатендә дә...

– Татарстанга нәрсә китерәсез?

– Татарстанга Үзбәкстан Республикасыннан шактый төрдәге товарлар экспортлана. Шулар арасында иң киң таралган һәм барыбызга да таныш халык куллану товарлары – җиләк-җимеш-яшелчә һәм киптерелгән җиләк-җимеш. Сыйфаты буенча аларга тиңнәр булмавы сезгә мәгълүм инде.

– Сез үзегезнең дипломатик миссиягез нәрсәдә дип саныйсыз?

– Сәүдә-икътисадый хезмәттәшлекне үстерү, безнең республикалар арасында дуслыкны ныгыту.

– Сез рус телен шундый яхшы итеп кайда өйрәндегез?

– Безнең Үзбәкстанда бөтен кеше рус телендә сөйләшә. Ул безнең өчен чит телгә саналмый, Советлар Союзы заманыннан бирле якын. Татар теле исә үзбәк теленә охшаш. Мин аны бик яхшы аңлыйм. Инде әз генә сөйләшә дә алам.

ЧЫН ИРЛӘР РИЗЫГЫ

– Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен Татарстанда үзбәк кафе һәм рестораннары грузин, азәрбайҗан яки башка милләтләрнекенә караганда күбрәк?

– Бәлки, Үзбәкстанда бик күп татар, Татарстанда бик күп үзбәк яшәгәнгәдер. Әлбәттә инде, үзбәк ашларының бик тәмле булуыннан да. Һәр милли ризык үзенчәлекле, татар һәм үзбәк ашлары исә бер-берсенә аеруча якын. Пылауны да, мантый белән лагманны да бөтен кеше ярата. Чын ирләр ризыгы болар!

Гомумән, үзбәк ризыклары күптән инде бөтен дөньяда данлыклы, һәм бүген үзбәк кафе-рестораннар читтәре Антарктидадан кала барлык кыйтгаларда да бар. Чөнки үзбәк ризыклары тәмле һәм күптөрле. Калорияле һәм сихәтле. Затлы һәм матур. Һәм өч мең елга якынлык тарихка ия. Димәк, кызыклы. Болар барысы бергә милли кулинария сәнгатен тәшкил итә дә инде.

Мәсәлән, язын халык медицинасы нигездә яшел төстәге ризык һәм яшелчә салатлары ашарга киңәш бирә. Әгәр бу чорда Үзбәкстанга килсәгез яки Казандагы үзбәк кафесына керсәгез, сез витаминга бай язгы ризыклардан авыз итәчәксез: сумалак, халим, яшел самса, яшел мантый һәм пилмән, бөтнекле машхурда, суганлы кабартма. Калорияле булса да, пылау да файдалы булган кишергә, шулай ук айва, йөзем, көрәгә, сарымсакка бай. Андагы тәмләткечләр – зира, барбарис, чи, киптерелгән һәм төелгән кызыл кузаклы борыч, кара борыч, кориандр һәм яшел үләннәр составында хуш исле матдәләр, витаминнар, минераль тозлар, эфир майлары күп, барысы да аппетитны ача, ризыкның



– Үзбәкстанда 7000 тарихи ядкәр бар. Аларның күбесе ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объекты санала.

физиологик кыйммәтен арттыра һәм аны аксым, углеводларга баета.

Гомумән үзбәк ризыкларын һәм бигрәк тә пылауны мактавымны Европа кулинария тарихы һәм культурасы институты президенты Филипп Вендрикс сүзләре белән төгәллисем килә: «...Без үзбәк пылавын әзерләүне югары уку йортыбызның уку программасына кертүне һәм тәҗрибә уртаклашу өчен сезнең осталарны чакыруны планлаштырабыз».

ТУРИСТЛАР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ УРЫННАР АЛМАШУ

– Үзбәкстанда татар диаспорасы бармы?

– Әлбәттә! Үзбәкстанда алты татар мәдәни үзәге бар. Бездә татар халкының милли бәйрәме – Сабантуйны да бик яраталар. Былтыр аны сигез шәһәребездә уздырдылар. Ул бик күп туристларны җәлеп итә. Биредә исә, Халыклар дуслыгы йортында үзбәк милли ассамблеясы бар. Татарстан җирендә һәрвакыт Нәүрүзне билгеләп үтәләр. Бу бәйрәмдә катнашу төрле милләт вәкилләренә кызыклыдыр, дип уйлыйм.

– Үзбәкстан ватандашлары турист сыйфатында Татарстанга еш киләме?

– Хәзер Татарстан – безнең туристларны бик кызыктыра торган җир. Казанга килү, аның истәлекле урыннарын күрү, Болгарга бару турында хыялланучылар саны көннән-көн арта бара... Минем үземне Казан Кремле архитектурасы бик сокландыра. Килгән кунакларымны мин, һичшиксез, Кремль яр буена алып барыр, аларга Казан Мәчесе турында риваять сөйләр идем. Безнең Үзбәкстанда да риваятьләр бихисап, шулай ук 7 меңнән артыграк тарихи ядкәр исәпләнә. Аларның күбесе ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объекты булып тора. Алар борынгы Сәмәрканд, Бохара, Хива шәһәрләрендә урнашкан. Ташкентта да мәдәни ядкәрләр бар, бүген ул заманчарак шәһәргә әйләнде, анда бертуктаусыз нәрсәдер төзиләр. Яңа комплекслар, яңа биналар, кунакханәләр. Ташкент-сити төзелеп килә.

– Әгәр без Сәмәркандка кунакка килсәк, иң беренче эш итеп безне кая алып барыр идегез?

– Әлбәттә инде, иң әүвәл Регистанга юл тотачакбыз. Бу – Сәмәрканд үзәгендәге борынгы ныгытма. Сезгә XV–XVII гасырлар архитектурасы үрнәкләрен – Олугбәк, Шердор, Тиллә-Карый мәдрәсәләрен күрсәтәсем килә. Өч мәдрәсәдән торган бу ансамбль – ислам архитектурасының иң гүзәл үрнәкләреннән берсе, ул шулай ук ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы Исемлегенә кертелгән.

– Сәмәрканд тагын нәрсә белән җәлеп итә ала?

– Үзбәкстанда иң шәп климат Сәмәркандта. Урта гасырлар тарихында билгеле шәхес – Тимерланның үзенә башкала сайлавы турындагы риваять бар. Ул бөтен шәһәрләрдә ит түшкәләрен элеп куярга боерган. Бөтен калада диярлек ит бозылган, Сәмәркандта гына бар җирдәгедән озаграк сакланган. Шунлыктан ул Сәмәркандны

башкала итеп сайлаган һәм анда яши башлаган. Тагын әле Сәмәрканд кабартмасы белән данлыклы, андыйны башка беркайда да пешереп булмый. Бохарада да, Ташкентта да пешереп караганнар… Тандырларны, онны, пешекчеләрне, хәтта суны да Сәмәркандтан китергәннәр, әмма барыбер андагы кебек кабартма килеп чыкмаган. Моның сәбәбен беркем дә белми. Бу бер үк вакытта риваять тә кебек, чынбарлык та. Чөнки атаклы Сәмәрканд кабартмасын әлегә кадәр беркайда да пешерә алганнары юк.

ЭССЕ ҮЗБӘКСТАННАН – КОЯШЛЫ ТАТАРСТАНГА

– Биредә яшәп калучы ватандашларыгызны нәрсә кызыктыра дип уйлыйсыз? Кардан башка, әлбәттә?

– Гореф-гадәтләр, тел, мәдәният… Гәрчә Татарстанда һава торышы Үзбәкстандагыдан салкынрак булса да, биредә җанга рәхәт, чөнки мондагы халык җылы, кунакчыл, кояшлы.

Мин әлегә биредә берүзем яшим. Тиздән гаиләм – хатыным, улым Фарзод (аның исеме «искиткеч» дип тәрҗемә ителә), кызым Фарангиз («матурлык» мәгънәсендә) киләчәк. Бездә бөтен исемнең мәгънәсе бар. Хатынымның исеме «асылташ», минеке «бердәнбер» дип тәрҗемә ителә.

Аларның Казанны күргәне бар инде, Яңа елга килгәннәр иде. Биредә гаиләмә бик ошады. Әлбәттә, аларның мондагы кадәр карны моңарчы беркайчан да күргәне юк иде. Ул күрешү бик күңелле, сөенечле һәм бәйрәмчә булды.

БҮЛӘК КИТАПЛАР ҺӘМ ЧӘЙ ПЕШЕРҮ ТРАДИЦИЯСЕ

– Гаиләгезне көткән арада нәрсә белән шөгыльләнәсез?

– Мин укырга бик яратам. Казанга килгәч, китапханәмә тагын китаплар өстәлде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановтан бүләккә китап алдым, Минтимер Шәрип улы Шәймиев тә «Жизнь замечательных людей» китабын бүләк итте, аны укып та чыктым инде. Шулай ук бүләк ителгән «Культура Татарстана» китабын башыннан ахырына кадәр укыдым… Өйдә, эш кабинетымда, өстәлемдә рус һәм үзбәк телендәге китаплар өелеп ята, мин укымыйча тора алмыйм.

Пылау пешеп чыканчы Фәриддин Бәдретдин улы чәй пешерә.

– Безнең Үзбәкстанда чәйне ашаганчы да, ашагач та эчәләр – гадәт шундый. Һәм өч тапкыр пешерәләр. Һәркайсының үз аңлатмасы бар, чәйне аларны әйтә-әйтә пешерергә кирәк. Беренче тапкыр пешергәндә, «лой» диләр, бу тәрҗемәдә «болганчык» сүзен аңлата. Икенче тапкы-

1. Кыздырабыз!

2. Турыйбыз!

3. Өстибез!

4. Турыйбыз!

5. Салабыз!

6. Тезәбез!

7. Салабыз!

8. Агызабыз!

рында «май» диләр (бу юлы чәйнең хуш исе һәм тәме пәйда була). Өченче тапкырында «чәй» диләр һәм чын чәй белән дусларны сыйлыйлар.

Чәй касәнең өчтән бер өлешенә генә салына һәм сул кул белән бирелә – бу ихтирам билгесе. Уң кулны шул ук вакытта йөрәк турысына куялар, бу ихлас күңелдән, чын йөрәктән, дигәнне аңлата. Табында чәйне яше буенча иң кече кеше ясый.

– Касәгә чәй ясаганда, аны ешрак өстәр өчен шулкадәр аз агызалармы?

– Юк, бу эчкәндә кеше пешмәсен һәм чәе суынып өлгермәсен өчен шулай эшләнә. Касәне тутырып ясыйлар икән, димәк, ихтирамсыз дигән сүз. Шунлыктан, тулы касә кирәккәндә: «Миңа ихтирамсыз яса», – дип шаярталар.

ТАШКЕНТ – ИКМӘКЛЕ ШӘҺӘР

Үзбәкстанда чәй пешерүдә дә, никахлашуда да традицияләр бик көчле. Ярәшүнең үз тәртибе бар: башта кәләш буласы кыз янына кияүнең туганнары бара. Кияүнең нәрсәсе бар, киленнең нәрсәсе бар – барысын да уртага салып сөйләшәләр. Традицияләр бик көчле. Шунлыктан гаиләләр дә нык. Бездә демографиягә кагылышлы проблемалар юк, Үзбәкстанда икенче бала тапкан өчен Россиядәге кебек акча түләмиләр, чөнки болай да сабыйлар күп туа. Әгәр акча да түләсәләр – ай-һай! Халык саны буенча Кытайдан да уздырырлар иде.

Бездә балаларны бик яраталар. Ерак сугыш елларыннан бер мисал китерәм. Үзбәкстанга эвакуацияләнеп балалар төялгән эшелон килгәч, бер генә сабый да балалар йортына эләкмәгән, аларның барысын да гаиләләргә алганнар. Бөек Ватан сугышы вакытында һәр үзбәк гаиләсендә алтышар-җидешәр бала булган, шулай да алар тагын берәр, икешәр сабыйны сыендырган, баласының букчасын биреп, үзләренеке мәктәпкә букчасыз йөргән. Уллыкка алынган бала караватта, үзләренеке исә идәндә йоклаган. Менә бу үзбәк кунакчыллыгы дип атала да инде. Балаларның тамагы туйган, алар җылынган. Гомер-гомергә бит «Ташкент – икмәкле шәһәр» диләр. Климат шартлары уңайлы, яз иртә килә... Биредә кешеләр беркайчан да ачлыктан интекмәгән. Монда кипкән җиләк-җимеш тә күп, арпа, ашлык бар. Балаларны әллә кайлардан китергәннәр, Ташкентта исә аларның барысын да гаиләләргә урнаштыра барганнар. Сугыш чорында 15 баланы уллыкка алган үзбәк гаиләсе – Шомәхмүдовларга һәйкәл куелган. Алар сабыйларны тәрбияләп үстергәннәр. Йорт, гаилә, традицияләр – безнең халыкның төп кыйммәтләре әнә шулар.

ПЫЛАУ ҺӘМ МӘХӘББӘТ

Сәмәрканд пылавы әзер. Остабыз аны табынга сәмәркандча бизәп бирә: башта өеп дөге һәм кишерне, өстенә итне сала. Дөгесе дә, кишере дә, ите дә мул. Бик байларча, матур, затлы һәм телне йотарлык тәмле! Шунысы гына кызганыч, хөрмәтле укучыларыбыз, әлеге гаҗәеп сый белән ләззәтләнгән чакта янәшәбездә сез юк идегез!

– Пылау – үзбәк кулинария сәнгатенең иң югары ноктасы, – дип шәрехли үзенең нигъмәт җәүһәрен Фәриддин Насрыев. – Ул барлык технологик процессларны – кыздыру, пешерү, томалап пешерүне үз эченә ала. Димәк, пылау пешерергә өйрәнгән кеше рәхәтләнеп уннарча төрле башка ризыкны да әзерли белә.

Сезгә пылау һәм...мәхәббәт турында риваять сөйлим хәзер. Ашый-ашый тыңлагыз.

Борын-борын заманда бер шаһзадә ярлы гаиләдә үскән чибәр кызга гашыйк булган. Итекче кызына өйләнә алмавына бик кайгырган. Көннән-көн сулган, беркем белән аралашмаган, ашаудан баш тарткан. Патша Әбүгалисинаны чакырткан һәм шаһзадәне ничек тә дәвалавын үтенгән. Әбүгалисина шаһзадәнең ач тору сәбәбен ачыклаган һәм сихәтләнүнең ике юлын тәкъдим иткән. Беренчесе – гашыйк җаннарны кавыштыру, икенчесе исә – хәлсезләнгән егеткә җиде төрле ашамлыктан әзерләнгән калорияле «пылау аш» ашату.

Шул вакыттан бирле туй табынында пылау мәҗбүри ризык санала. Һәм, гомумән, үзбәк гаиләсендә исем кушудан алып туй юбилейларына кадәр бер генә гаилә тантанасы да пылаудан башка үтми. Аны кунак хөрмәтенә дә пешерәләр. Ул һәрвакыт әзерләнә! Һәм мәңге шулай булсын!

9. Бүләбез!

10. Кисәбез!

11. Бирәбез!

12. Телибез!



PRESSA

Фото: Александр Ефремов



ТАТАР 100 ЛЕТ ЕЛ

ТАТАРСТАН МАТБУГАТЫ КӨНЕ

1905 елның 19 маенда, әле ул чакта пионерия булмаса да, ул туачак көн хөрмәтенә 70 елдан озаграк аның исемен йөртәчәк көндә, дөньяга татар телендәге «Нур» газетасының беренче саны чыккан. Бу хәл Санкт-Петербург шәһәрендә булган. Шулай итеп, 1905 елның 19 мае татар профессиональ журналистикасының юл башы булып та тора. 1998 елда исә бу көн рәсми рәвештә Татарстан Матбугаты көненә әверелде.

Бу бәйрәмне «Татарстан» редакциясе инде күп еллар типография цехларында билгеләп үтә – нәкъ менә шунда, типография буяулары исе, газета-журналлар басу машиналарының туктаусыз гүләве һәм ап-ак кәгазьләрнең күңелле кыштырдавы арасында, чын офсет басма барлыкка килә. «Татарстан»ның өр-яңа саны да шунда туа, ә ул үзенең 100 ел дәвамында басылу тарихында «Татарстан большевигы» да, «Татарстан коммунисты» да, «Ильич юлы» да, «Причал» да, «Спутник партийного активиста» да булып йөргән... Хәрефләр, тыныш билгеләре һәм буш урыннар, тезелеп, цехларда Татарстан Республикасының басма тарихын язган. Ул әле дә языла. Әйе, һәрвакыт типографиядә дә булмасын, күбесенчә Интернетта – мәгълүмати сайтларда һәм социаль челтәрләрдә дә булсын, әйдә. Ләкин принцип шул ук бит – сүзләргә һәм җөмләләргә әверелеп, чиста ак кәгазь битендә яки вордның чиста ак файлында басма эзләр калдырып, хәрефләр җыела.

Каләм осталары, каләмнәре турында онытып, камил рәвештә басу осталыгына ирештеләр һәм виртуоз рәвештә баса беләләр – уң кулының имән бармагы беләнме, сул кулының чәнчә бармагы белән булсынмы, компьютер клавиатурасындамы, телефон экранындамы – тавыш тизлегендә һәм хаталарсыз диярлек. Профессиональ журналистларның хезмәт нәтиҗәсе булып мәгълүмат тора (хәбәр, мәкалә, репортаж, эссе...) – басылган билгеләрнең һәр меңенә исәплән гонорар түләнә.

– Ә буш урыннар өчен гонорар бирeләме? – дип сорар, әлбәттә, баса белгән һәм акча эшләргә теләгән кеше.

– Ничек кенә әле! – дип җавап кайтарыр тәҗрибәле журналист. – #әгәриндесезнеңжанрыгызхэштегдипаталмаса.





Фото: Александр Ефремов

ТАТАРСТАН
РАЗУМНОЕ:
Бол-гёрлз: тайное оружие ФИФА
ДОБРОЕ:
Сборная мира. Татарстанский вариант
ВЕЧНОЕ:
Книжная полка Александра Нордена
КАК НАКОРМИТЬ ФУТБОЛЬНУЮ КОМАНДУ
Заказ: E-1493_Татарстан_#6(рус_обложка) Лист Лицо 2018/06/18 17:07:03

Фото: Александр Ефремов, Луиза Шарова



Каләм осталары язмалары:

ТАМЧЫ ТАШ ТИШӘ

«Татарстан» журналының шеф-редакторы Әскәр Сабиров матбугатта басылмый торган нәрсәләр турында.

Журналистика һөнәрләрнең иң демократик рухлысыдыр, мөгаен. Югары даирә кабинетларының һәм яшерен лабораторияләрнең ишекләрен ача, эпик вакыйгаларда катнашырга һәм көндәлек ыгы-зыгыда бөек нәрсәләр күрә белергә мөмкинлек бирә. Ә журналист эше – һәрвакыт күз алдында. Мәкаләләр, репортажлар, яңалыклар тасмасындагы күзәтүләр... – барысы да укучылар өчен, бернинди сер юк. Журналистның «эчке кухня»сы гына, гадәттә, кадр артында кала, гәрчә анда кызык нәрсәләр шулкадәр күп ки, рестораннарга бирелә торган Мишлен йолдызлары тел шартлатып читтән генә карап торырлык...

ХӨСНИ МӨБАРӘК КӘНӘФИЕ

Халыкара гауга китереп чыгаручы булырмын дип һичкайчан уйламадым. Ләкин шулай килеп чыкты. Моңа тиң башка бик күп очраклар кебек үк, минеке дә вак-төяк нәрсәдән кабынып китте.

Туксанынчы еллар ахырында – «Аргументы и факты» газетасының төбәк чыгарылышында мөхәррирлек эшен башкарган чагым – Казанга башкаладан хезмәттәшем килде:

– «АиФ»ка материал эшләрлек берәр нәрсә киңәш итмәссеңме? Тема түгел, ә бомба булсын!

Бераз баш катырып алганнан соң, шундый фикергә килдек: Казанда төрле ил президентлары өчен эшләнә торган ВИП-вертолетлар турында язма «бомба» булырга мөмкин. Тулысынча диярлек ябык тема. Шулай да КВЗ генераль директоры Александр Лаврентьев тәкъдимгә аек акыл белән карады: өч миллион тиражлык газетада мәкалә чыгу – яңа заказчы дигән сүз бит...

Бер тәүлектән соң ул инде безгә очкычтагы бүлмәләрне зиннәткә төрүче югары даирә вәкилләренең көйсезлекләре, кирелекләре турында матурлап-чуарлап сөйләп тә бирде. Тиздән «АиФ»та репортаж чыкты. Лаврентьев исә шул ук көнне шалтыратты.

– Сез анда нәрсә эшләп ташладыгыз? Сез безне, юк, илебезне, миллионнарча доллардан мәхрүм иттегез! – трубкадан генераль директорның ачулы тавышын тыңлаган арада, илгә китергән зыянны капларга туры килә калса, катгый режимлы урында ничә ел чиләнергә кирәк булачагын күңелдән саный идем инде.

Бераз суынгач, шул ачыкланды: «ВИП-вертолетлар» турындагы мәкалә басылган газета киоскларга чыгуга, җәнҗал купкан. Лаврентьевка Мисыр илчелеге вәкилләре ябырылган: «Безнең президент Хөсни Мөбарәк вертолетында бер кәнәфинең генә дә 25 мең доллар торуы хакында хәбәр таратырга кем хокук бирде сезгә?! Безнең ил ярлы бит, язмагыз халыкның ачуын чыгарырлык язмаларны...»

– Әгәр мәгълүмат кире кагылмаса, вертолет сатып алу килешүеннән баш тартачакбыз, дип белдерде мисырлылар, – әнә шулай, югалып калгандайрак тәмамлады сүзен Лаврентьев.

Югалып та калырсың. Текстта бер хата да юк, «Мөбарәкнең кыйммәтле кәнәфие» турындагы мәгълүматны да без заводта җитәкченең үз авызыннан ишеттек. Ә «АиФ»та баш мөхәррир – безнең өчен патша һәм Алла үзе булган Владислав Старковның «кире кагу» дигән сүзне ишетүгә ничек кабыначагын хәтта вахтерлар да белә. Хәзер үк гариза язуың җиңелрәк...

Әмма 90 нчы еллар азагында без әле бик начар тормышта яшиидек. Газетада бер юллык

Фото «Вертолёты России» сайтыннан

мәгълүмат аркасында, илнең миллионлаган долларны югалтырга мөмкинлеге турында курку барыбызны да кагыйдәләргә каршы барырга мәҗбүр итте. Миңа хәлне Мәскәүдә аңлатырга туры килде. Анда исә корыч куллы Владислав Андреевич, бик озак уйлаганнан соң, теш арасыннан гына: ил өчен бик кирәк икән, каршы килмәбез, «кире кагу» язмасын басыгыз, дип әйтеп салды...

Халыкара дәрәҗәдәге җәнҗал ничек тәмамланды соң, диярсез. Тип-тигез урында барлыкка килгән башка күп кенә гаугалар кебек үк. Тыныч кына онытылды да бетте. Мисырлылар Казан вертолетларыннан яхшыракны таба алмаган, күрәсең. Килешү-сөйләшү өчен җаваплы кешеләребез дә кул кушырып утырмады. Хәтта инде әзерләп куйган «кире кагу» текстын бастыру да кирәк булмады.

Аның каравы, шуннан соң мин газетада басылган мәкаләләрнең күпме тора алганын төгәл белә башладым.

ПРЕЗИДЕНТ ЯНЫНА ЧӘЙГӘ...

СССР таркалып, чикләр ачылгач һәм цензура чигенгәч, без, журналистлар, күмер чабучылар белән генә түгел, корольләр белән дә бертигез аралаша алуыбызны тойдык. Ирек хисе көч-куәт өстәде һәм иң өметсез хәлләрдә дә эксклюзив материал табарга ярдәм итте – тәҗрибә шуны раслый.

1993 елның җәендә Татарстан журналистлары төркеме Төркия Президенты Сөләйман Дәмирәл белән очрашуга Әнкарага чакырылгач, аның белән әңгәмә кору мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә иде. Беркетмә хезмәте вәкиле безгә бу хакта ачыктан-ачык хәбәр итте:

– Сезнең нибары биш минут вакытыгыз булачак. Елмаю, күрешү, истәлеккә фото – менә шуларга гына исәп тота аласыз. Биш минуттан, график буенча, президент Казахстанның Оборона министрлыгы вәкилләре белән очрашырга тиеш.

Һәм менә без атаклы Җанкая сараенда президент белән танышабыз. Дежур елмаюлар, әдәпле сүзләр, тыйнак сораулар – боларга хуҗа кешенең мыегы да селкенми кебек тоела. Күмәк фоторәсемгә төшү вакыты якынлашып бара.

– Ә ялыгызны кайда үткәрергә яратасыз? – көтмәгәндә без көндәлек проблемалардан читкә китәбез һәм Дәмирәлнең йөзенә җан керә. Ул үз иле, аның матурлыгы турында сөйли башлый, өстәл артында әңгәмә үзеннән-үзе ялганып китә...

Истәлеккә күмәк фото ясадык анысы – президент белән чәй эчеп, безне кызыксындырган барлык сорауларга җаваплар алгач, ярты сәгатьтән соң. Бу вакытта исә дустанә илнең Оборона министрлыгы вәкилләре үзләренә чират җиткәнен көтеп торды.

Икенче көнне Төркия президенты Сөләйман Дәмирәл белән әңгәмә «Татарстан хәбәрләре»ндә («Известия Татарстана») басылып чыкты (ул вакытта ТР Дәүләт Советы һәм Министрлар Кабинетының рәсми газетасы – ред. иск.).

ДҮРТЛӘТӘ ПЛАН
ҺӘМ БУЛМАГАН ҖИР ТУРЫНДА

Бервакыт мин илебез өчен чын геройны беренче булып «ачуым» белән ел буе горурланып йөрдем. Һәм әллә кайдан читтән табып та түгел, ә үзебезнең Татарстанның бер районыннан.

1982 елда республика рекордлы уңыш җыйды. Ул чакта «Советская Татария» газетасының барлык хезмәткәрләрен дә диярлек икмәк өчен көрәш турында репортажлар язарга җибәрделәр бугай. Мине, сәнәгать бүлеге хәбәрчесен, Актанышка юлладылар. Аннары таушалган «уазик» белән бөтен сөякләрне санап йөрү, тәмам арган-талган колхозчылар белән әңгәмәләр, кыр станнарында кыска ял мизгелләре... Эш сәфәрем ахырына якынлашканда, партия райкомында кызыксынып сорап куйдылар:

– Ә сез «Таулар» колхозында булдыгызмы? Юк? Ничек инде? Алар бит быел дәүләткә дүртләтә план тапшырды!

Әле күптән түгел генә хезмәт юлын башлаган журналист моңа ничек җавап бирә ала соң? Әлбәттә, могҗизалы уңыш җыйган рәис белән танышканда, мин аңа, Алла Пугачева иҗатына мөкиббән затларның җырчыга карап каткан халәтен кабатлаган кебек, күз дә йоммый текәлгән идем.

Сүз уңаеннан, Инсаф Камалетдинов атлы ул рәис әңгәмәдән баш тартты. Үзенең «уазик» кабинасына гына дәште, янәсе, телисең икән, барысын да үз күзләрең белән күрерсең. Әлеге «хәрби башлыкның үз сугышчылары» белән никадәр акыллы идарә иткәнен унике сәгать күзәттем. Яңгырларга кадәр уңышны җыеп бетерер өчен, комбайннарны бер басудан икенчесенә ничек күчергәннәрен, бер участокта уңыш фронтына өстәмә көчләрне ничек кертеп җибәргәннәрен, һәм киресенчә, ашлыкны югалту мөмкинлеге булган урыннарда «һөҗүм»нең бераз туктатылганын күрдем.

Эш көне ахырына дүрт планны җиңгән рәис Камалетдинов турында материалымның нинди булачагы башымда язылган иде инде. Репортаж түгел, чын поэма! Редакциянең иртәнге җыелышында материалны мактап телгә алып киттеләр. Ә бер айдан соң Инсаф Заһретдин улы Камалетдиновны Ленин ордены белән бүләкләделәр.

Мин шундый хис кичердем ки, әйтерсең, ул түгел, ә мин үзем орден алганмын. Ниндидер беркатлылык белән, каһарманның батырлыгын чын-чынлап бәяләргә минем мәкаләм булышты, дип уйлап та йөрдем әле...

Бер елдан соң мин янә Актаныш районына барып чыктым. Инде башка рәис белән сөйләшкәндә, «Таулар» колхозының дүртләтә планы турында искә төшердем.

– Әйе, алар, әлбәттә, булдыра, – дип, ни өчендер уйчанрак итеп әйтеп куйды ул. – Кәгазьдә гамәлдән чыгарылган җирләрне бирәү дә алар кебек шәп файдаланмый...

– Ничек инде ул, гамәлдән чыгарылган?

– Үзең уйлап кара, чынлыкта уңышлылыкны дүрт тапкыр арттырып буламы соң? Ә аларда Түбән Кама гидроэлектростанциясенең су басу зонасына эләккән җирләр бар. Ул җирләр әле су астында түгел, ләкин документта алар инде юк санала...

Шул вакыттан бирле мин «тиз» материаллар язмаска тырышам.

Казан, 1996 ел.
Борис Ельцинга Колшәриф мәчете нинди булачагы турында сөйлиләр.

Фото ТР Президенты матбугат хезмәтеннән

Хәер, еллар дәвамында шуны аңладым: ул чакта мин ачкан шәхес чын герой иде. Әйе, совет системасы ничек кенә булса да планны үтәргә мәҗбүр итә һәм отчетларда матур саннарны бик ярата, бәяли иде. Әмма әнә шул кимчелекле системада да фронтовик Камалетдинов бик зирәк фикер йөртеп, кәгазьдә сызып ташланган җирләрне файдага эшләтә алган. Бөтенесе дә шулай эшләсен иде әле!

БОРИС НИКОЛАЕВИЧ КОРТЕЖЫНДА

Илбашының сәфәрен яктыртучы теләсә кайсы журналист өчен иң зур хыял – төп герой белән янәшә туры килү, аны озата йөрүчеләр белән бергә булу. Эш барышында шундый күренешләргә, әңгәмәләргә шаһит буласың ки, хезмәттәшләреңне көнчелек утларына саласың. Тик теләк белән мөмкинлек арасында тирән упкын ята, бигрәк тә син федераль дәрәҗәдәге Кремль журналистлары исемлегендә булмаганда. Дөрес, Татарстанның беренче Президентының матбугат сәркатибе Әнәс Хәсәнов бер-ике тапкыр мондый стереотипны җимергәләде.

...1996 елның мае. Менә-менә Казанга сайлау алды сәфәре белән Борис Ельцин килергә тиеш. Миңа, «Татар-информ» агентлыгы генераль директоры урынбасарына, республика матбугаты өчен репортаж әзерләү йөкләнде. Әнәс Хәсән улының сүзе катгый: кортежда барасың! Ләкин Мәскәү ягыннан сәфәрне оештыручылар тыңларга да теләми!

– Ярар, – дип, Әнәс әфәнде бераз тын алырга булды. – Иртәгәгә кадәр сабыр ит, аннары карарбыз.

Иртән, сәфәргә бер көн кала, Әнәс Хәсәнов бүлмәсендә Россия Президенты ярдәмчесе һаман үз сүзен тукый:

– Әйттем бит инде, бернинди журналист та булмаячак...

Әнәс әфәнде, бераз тын калып, игътибар белән, хәтта артык текәлеп диярлек, Мәскәү кунагының йөзен күзәтә башлый. Бик кызарынганлыгы шик уята, әлбәттә. Дулкынлану аркасындадыр мондый галәмәт...

– Ни булды йөзегезгә, кырынганда киселдегезме? – дип, хәлгә кергәндәй, кинәт сорап куя Әнәс Хәсәнов, ә кунакның битендәге ике яра исә күз алдында кызарып чыга. Аның иртәннән үк калтыранган кулларын Хәсәнов, әдәп саклап, күрмәмешкә салыша, хәер, бу хакта сүз кузгату кирәк тә түгел: башкала мин-минлеге ансыз да томандай эреп юкка чыга.

– Ярар, барсын, – дип, Мәскәү түрәсе ризалыгын бирә.

Миңа шунда ук аккредитация карточкасын тоттыралар. «Визит Б.Н. Ельцина» дигән язу астында «0» саны күзгә бәрелеп тора. Ә бу бик кыйммәт нәрсә – бөтен җиргә чикләүләрсез үтү хокукы ул.

Борис Николаевичның сәфәре турында репортаж, хезмәттәшләрем фикеренчә, әйбәт кенә килеп чыккан иде. Дөрес, анда «аргы якта» күргәннәрнең барысы да дөньяга чыкмады. Мәсәлән, Кол Шәриф мәчете урынындагы истәлек ташы янында булган хәл. Архитектор Фәридә Зәбирова Президентка проект


Ту-144 озак еллар койма артында ятты

турында сөйләгәндә, манараларның биеклеген телгә алгач, Ельцин кинәт җанланып китте, якындагы чиркәүнең гөмбәзенә ишарәләп:

– Моннан биегрәк булмастыр дип өметләнәм? – дип сорау бирде.

– Юк, юк, сез нәрсә! Нәкъ бер метрга... Сөембикә манарасыннан кыскарак, – дип котылды Зәбирова.

Борис Николаевич, канәгать калып, баш селкеде, һәм түрәләр төркеме алга таба юлын дәвам итте.

ӨМЕТ ЯШИ

Бик усал язмага карата һичнинди җавап булмавыннан, аның тавыш-тынсыз узуыннан да начаррак нәрсәне журналист күз алдына да китерә алмый, гадәттә. Син фактлар тупладың, фикерләрне чагыштырдың, нәтиҗәләр ясадың, һәм болар барысы да... комга сеңгән су кебек юкка чыга. Бу хакта зар-интизарларымны ишеткәч, «Аргументы и факты» колумнисты Дмитрий Макаров аталарча тынычландырып куйды: «Бөтенесе дә заяга булган дип уйлау дөрес түгел. Һәр язма – алга таба бер кечкенә адым ул. Кайчандыр барыбер нәтиҗәсе булачак, хәзер түгел икән, бер елдан соң, ел узгач булмаса, биш елдан соң... Тамчы таш тишә ул...»

Казанда биек койма артында гомеренең соңгы көннәрен көтеп яткан Ту-144 лайнеры турында тәүге тапкыр мин егерме ел элек яздым. Шул чакта ук илебез авиациясе горурлыгын һәркем карарлык күргәзмә итеп кую турында тәкъдим белән чыктым. Ләкин мәкаләгә бердәнбер рәсми кайтаваз КАИ проректорының җавабы булды. Самолетта бернинди музей да кирәк түгел, ул аннан башка да тулысынча – ягъни уку аудиториясе сыйфатында файдаланыла икән. Хәтта сүзләрен саннар белән дә раслаган иде: Ту-144 очкычына бер елда 350 кеше керер чыккан. Көнгә бер кеше дә туры килми, айһай шәп икән?!

Соңыннан башка басмаларда, башка журналистларның да язмалары дөнья күрде, фәкать нәтиҗә генә шул ук – совет инженериясенең могҗизасы әүвәлгечә мескен хәлдә җирдә тутыгып ята бирә иде. Өметне югалтып барганда, ике ел элек кыюлыгымны җыйдым да «Татарстан» журналында Казанның тиңе булмаган очкычы – Ту-144 музееннан репортаж бастырып чыгарырга җөрьәт иттем. Бу самолетның кабинасында кунаклар үзләрен чын очыш вакытында кебек тоя алыр иде. Чынлыкта бернинди музей да юк иде, ләкин онытылган очкыч туристларны җәлеп итәргә сәләтле нинди көчле магнит була алганын күрсәтү теләге җиңде....

Шулай туры килде ки, мәкалә басылып берничә ай узганнан соң, легендар лайнерны завод читеннән ниһаять алып китеп, Казанның Әмирхан проспектында һәркем күрә алырлык урынга куйдылар. Аннары, хәтерләсәгез, КМТТУ-КАИ җитәкчелеге Ту-144 интерактив музееның иң яхшы концепциясенә конкурс та игълан итте. Ниһаять, яңарак хәбәр: Россия Президенты Владимир Путин WorldSkills дөнья чемпионатына А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университетындагы (КМТТУ-КАИ) Ту-144 тавыштан тиз оча торган пассажир самолеты базасында интерактив Техника музееен ачуны тәэмин итү турында Россиянең Фән һәм югары белем бирү министрлыгына күрсәтмә бирде. Тиздән, Казанның «Туполев» очкычы штурвалына утырып, музей кунаклары үзләрен тавыштан җитез самолетта чын-чынлап очкан кебек тоя алачак, дип сөйлиләр...

Шул ук вакытта Казан тарих музее запасникларында башка бер тиңдәшсез очкыч – легендар У-2 самолеты тыныч кына таушалып-черер ята. Сугыш чорында яшүсмерләр һәм хатын-кызлар салкын цехларда җыйган атаклы төнге бомбардировщик ул. Ашыгыч рәвештә реставрация өчен акча тапмасак, бәһасез машинаны югалтырга мөмкинлегебез хакында ике тапкыр яздым. Ләкин бу сүзләрем әлегә һавада эленеп калды...

Шулай да өметне югалтмыйм. Тамчы таш тишә ул.

Фото: Ната Смирнова

Ту-144 һәркем өчен ачык урында

МАКСАТЛАР ҮЗГӘРМИ...

Ел саен шулай – майның икенче яртысында Матбугат көнен билгеләп үтәбез. Табигатьнең иң матур мәле – агачларның шау чәчәк аткан чорына туры килә күркәм ул бәйрәм. Юк, журналистлар бәйрәме генә түгел, ә укучыларыбызныкы да, чөнки сез булганда гына без бар...

Автор:
Руфия Фазылова

Татар матбугатының йөз еллар элек үк үз йөзе булган. Ул чорда беренче булып аңа нигез салучылар, һичшиксез, бүгенге газета-журналларга да нигез салучы, юл күрсәтүче булып исәпләнә ала. Моның чынлап та шулай икәнлегенә Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының (ТӘһСИ) Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә баргач тагын бер кат инандым.

КАЛЕНДАРЬДАН БАШЛАНГАН МИРАС

Башта йомырка барлыкка килгәнме, тавыкмы? Менә шушы сорауны бер генә тапкыр булса да ишетмәгән, аңа җавап эзләмәгән кеше бармы икән? Календарь белән газетаның үзара бәйләнеше турында ишеткәч, шушы сорау искә төште. Ягъни: башта татарча газета барлыкка килгәнме, әллә календарьмы? Дөрес җавап – календарь. Һәм аның сәбәбе дә бик гади – татар телендә ул чорда газета чыгарырга рөхсәт ителмәгән. Ә менә календарьга карата тыю булмаган. Шуңа да татар зыялылары календарьлар эшләп, халыкка таратырга тырышкан. Аңлашыла ки, башта алар кулъязма форматында булган.

Беренче календарьлар турында күбрәк мәгълүмат алыр өчен әдәбият галиме Марсель Әхмәтҗанов белән очрашып сөйләштек. Галим озак еллар дәвамында Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә хезмәт итә. Археограф, текстолог, филология фәннәре докторы Марсель ага узган гасырның 60 нчы елларыннан бирле иске татар язуларын өйрәнә, 500ләп авылга гына сәяхәт кылган ул. Башта төп максаты борынгы кабер ташларын эзләү һәм өйрәнү булса, соңрак, кулъязмалар, йөз ел элек чыгарылган календарьларны, вакытлы матбугатны да өйрәнергә керешкән.

– Экспедицияләргә баргач, җирле халык гаилә архивларында булган кулъязмаларны, йөз ел элек басылган календарь, газеталарны үзләре китереп бирә иде, – дип сөйләде Марсель ага Әхмәтҗанов. – Еш кына: «Әбием аларны бик кадерле ядкарь итеп, Коръәне белән бергә саклаган. Зинһар, укып бирегез әле», – дип тә мөрәҗәгать итләр. Мондый хәлләр Советлар Союзы таркалгач аеруча күбәйде. Аңа кадәр халыкның күбесе ачыктан-ачык гаиләләрендә шундый иске язмалар барлыгын әйтергә курка иде. Хәтта аларны җиргә күмеп саклаганнарын да беләбез. Әйе, язма мирасның кадерен белгән милләттәшләребез күп булган. Никадәр авырлыклар кичеп тә, аларның югалмавы – моңа ачык мисал...

Марсель ага күптән түгел 80 яшен тутырган. Хәзер инде экспедицияләргә чыгып йөрми икән, сәламәтлеге мөмкинлек бирми. Бүген ул үзе туплаган борынгы кулъязмалар, иске татар телендә язылган милли басмаларны өйрәнү, аларны тәрҗемә итү белән мәшгуль.

– Англия, Франция кебек алдынгы мәдәнияткә ия илләрнең китапханәләрендә саклана торган борынгы һәм иске кулъязмаларны инде өченче, дүртенче тапкыр бастырып чыгардылар, – диде галим. – Ни өчен дигәндә, фән өзлексез үсә-үзгәрә тора, галимнәр алдына көтелмәгән сораулар куя. Шуңа күрә безнең мирасханәләрдә тупланган истәлекләрнең дә яңадан каралып, басылып чыгу ихтималы юк түгел. Әйе, аларны өйрәнү бик кирәк, чөнки ул борынгы бабаларыбызның бай рухи тормыш белән яшәүләрен күрсәтә. Бу җирлектә яшәүче татарларның, төрки дөнья белән генә

Фото: Лилиана Вәлитова

түгел, Кытай, Һиндстан, башка илләрдә яшәүче мөселманнар белән дә тыгыз бәйләнештә яшәгәнлеген күрсәтә...

Марсель ага эш өстәле тартмасыннан шактый яхшы сакланган китапчык алды. Бактың исә, 1887 елда Казанда басылган календарь икән. 130 елдан артык вакыт узуга карамастан, һич тә таушалган дип әйтеп булмый. Марсель ага аны укып күрсәтте. Алдагы битләрдә патша хөкүмәтендәге аерым кешеләрнең фотолары урнаштырылган. Ләкин алар белән бәйле язма юк, бары кемнең кем булуы гына искәртелгән. (Бәлки, календарьның бу саны нәкъ шуңа саклангандыр да.) Калган өлеше бүгенге реклама газета-журналларын хәтерләтә: пароход расписаниеләре, кояш ничәдә чыга, ничәдә бата. Һәм сату-алу турында бик күп мәгълүмат бирелгән...

– Беренче татар календаре 1841 елда мәгърифәтче Рәхмәтулла Әмирханов тарафыннан төзелеп бастырыла, – диде Марсель Әхмәтҗанов. – Соңрак, 1854 елда – Рәхимҗан Яхин, 1856 елда – Мәхмүд Максудов, 1871 елдан Каюм Насыйри кебек татар зыялылары бу эшне башкара. Тагын башка дистәләгән исемнәрне дә атарга була. Күргәнебезчә, 1841 елдан башлап татар календарьларын бастырып чыгару интенсив рәвештә арта барган. Әгәр электән калган бай традиция булмаса, татарлар бу кадәр күптөрле календарьлар чыгара алмаслар иде. Мисал өчен, Каюм Насыйри 1871–1899 еллар аралыгында 24 календарь чыгара. Шәрәфетдин Шәһидуллин 1900–1917 еллар эчендә 20ләп календарь бастыра. Минһаҗ Кадермәти тарафыннан 1911–1917 еллар арасында биш календарь нәшер ителә.



– Экспедицияләргә баргач, җирле халык гаилә архивларында булган кульязмаларны, йөз ел элек басылган календарь, газеталарны үзләре китереп бирә иде, – дип сөйләде Марсель ага Әхмәтҗанов.

«НУР» ҺӘМ БАШКАЛАР

Шулай күнегелгән, татар матбугатының башын 1905 ел белән бәйлиләр. Ни өчен дигәндә, Санкт-Петербург шәһәрендә татар телендә беренче «Нур» газетасы нәкъ шул елны чыга башлый. Бу эшкә Петербургның имамы – галим Габдулла Баязитов алына. Цензура бетерелгәч, Беренче шәһәр Думасы депутаты, җәмәгать эшлеклесе Сәетгәрәй Алкин башлангычы белән Казанда да 1905 елның октябрендә татар телендә беренче газета дөнья күрә – «Казан мөхбире». Анда, яңалыклардан кала, халыкара хәлләр, икътисад һәм фән, мәдәният турында да мәгълүматлар бирелә. Шуннан соң төрле юнәлештәге иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм сатирик басмалар барлыкка килә – «Йолдыз», «Вакыт», «әл-Ислах» газеталары, «Карчыга» журналы һ.б. Нигездә анда танылган шагыйрьләр, язучыларның шигырьләре, мәкаләләре басыла. Мисал өчен, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Ф. Кәрими, Г. Коләхмәтев, Г. Исхакый кебек үз заманының олпат каләм ияләре басмаларны чыгаруда катнаша.

Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә шул чорга караган басмаларның аерым номерлары бар.

– Ни кызганыч, «Нур», «Казан мөхбире» газеталарының беренче саннары бездә сакланмаган, – диде Үзәк җитәкчесе Илһам Гомәров. – Беренче чиратта «Тәрҗеман» газетасы турында әйтәсем килә. 1883 елда Бакчасарайда нәшер ителгән әлеге беренче төрки-татар басмасы күпләргә үрнәк булган. Аны бастыручы – Исмәгыйль Гаспралы. Мин бу кешене төрки халыкларның мәгариф системасын яңартучы, аң-белемен үстерүче дип саныйм. «Тәрҗеман»да Казан һәм башка төбәк татарлары да үзләренең язмаларын бастырган. Шул рәвешле ул аларга тәҗрибә мәктәбе булган. Соңрак дөнья күргән «Нур», «Казан мөхбире» газеталары нәкъ менә «Тәрҗеман» газетасы үрнәгендә чыккан.

Мирасханәдә «Йолдыз» газетасының тулы архивы бар. 1906 елның 15 гыйнварында дөнья күргән бу газета үз вакытында иң популяр басмаларның берсе булган. Беренче елларда – атналык, аннары атнага ике тапкыр, тора-бара көндәлек булып чыккан. Һәм тиражы да шактый зур – 8 меңгә кадәр җиткән.

– Белгәнебезчә, татар зыялылары 1890 елларда ук газета-журналлар чыгарырга омтылып карый, – диде Илһам

Гомәров. – Әйтик, Әхмәтһади Максуди 1905 елга кадәр дүртбиш тапкыр «Йолдыз», «Көндез», «Казан» дип аталган газеталар чыгару өчен Матбугат эшләре буенча баш идарәгә үтенеч хатлары яза, әмма рөхсәт ала алмый. Бары 1905 елгы революция генә аңа һәм башка татар зыялыларына күптәнге изге ниятләрен тормышка ашырырга ярдәм итә. Әхмәтһади Максуди шулай итеп «Йолдыз» газетасын чыгара башлый. Яхшы кәгазьдә басыла ул, теле дә җиңел укыла торган була. Шунысын әйтергә кирәк, «Йолдыз»ның географиясе гаҗәеп киң: Казан, Оренбург, Уфа, Самара, Саратов, Пермь, Томск, Тамбов, Смоленск, Иркутск губерналары, Екатеринослав (хәзерге Днепропетровск), Санкт-Петербург, Әстерхан, Ташкент, Тубыл, Петропавловск һ.б. калалар.

1907 елдан башлап газетада дәрәҗәле авторлар – Г. Камал, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, З. Камали, Г.Баттал, С. Рәмиев, К.Бәкер, Һ.Атласи язмалары күренә башлый. Шул рәвешле ул кыю фикерле, шул ук вакытта зыялы газетага әйләнә.

1918 елда, хакимияткә большевиклар килгәч, «Йолдыз» чыгудан туктый.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендәге белгечләр, шул газета-журналларны тәрҗемә итеп, үзләренең miras.info сайтларына урнаштыра баралар. Теләгән һәркем анда кереп, алар белән таныша ала.

1905–1930 елларда басылган газета-журналларда нинди темалар яктыртылган соң?

– Төрле темалар, –диде Илһам Гомәров. – Шул ук «Йолдыз» газетасы сәяси басма булган. Татар вакытлы матбугаты әдәби, дини, сатирик төрләргә бүленгән. Нәкъ бүгенге кебек. Дөресен генә әйткәндә, йөз елдан артык вакыт эчендә газета-журналлар әллә ни үзгәрмәде, дияргә була. Көн кадагына суга торган язмалардан башлап, сату-алу игъланнары, төрле афишаларга кадәр булган. Чорлар алышынуга карамастан, вакытлы матбугат кеше мәнфәгатен кайгырта, дәүләт белән гади халык арасында элемтә ролен үти. Бары замана җиле белән аерым үзенчәлекләр генә килеп керә...



«Йолдыз», 1906 ел, № 14.

«Йолдыз», 1906 ел, № 11.

«Аң», 1913 ел, № 8.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Киләчәк паркында агачларны **КЕМНӘР** утыртканы

Сергей Королёв **НИ ӨЧЕН** атна саен «Черек күл»гә йөргән

Җиңүгә ике ай кала «Шүрәле»не **КЕМ** биегән

«Үлемсез полк»ның үлемсез тарихлары **НИЧЕК** яңара

Алтын Урданы **НИ ӨЧЕН** тарихтан төшереп калдырырга теләгәннәр

Колшәриф мәчете янында соңгы сугыш

КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ ОЛУГ СӘЕТЕ

«ТАТАРСТАН» журналы өчен МАХСУС

Колшәриф – сирәк талантка ия шагыйрьләребезнең берсе, Казан ханлыгының баш имамы, күренекле дин галиме һәм илче-дипломат. Үзенең бөтен гомерен, талантын, иҗатын халык бәхете өчен фида кылган олы шәхес. Аның исеме татар халкының милли-азатлык көрәше тарихында алтын хәрефләр белән уеп язылган. Бу исемне бүген татарлар гына түгел, руслар да белә. Чит илләрдә дә яхшы таныш ул. Һәрхәлдә, Казанга килеп киткән чит ил туристлары Колшәриф исемен бик тиз отып алалар – әйтергә уңайлы, матур яңгырашлы. Бөтен Рәсәйдәге иң матур мәчет тә шушы атаклы шәхес исемен йөртә. Колшәриф исемен көн саен йөзләр, меңнәр кабатлый.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Әйе, Колшәриф – халык телендә. Әмма, аның турында без нәрсә беләбез соң? Кызганыч, мәгълүматларыбыз бик аз. Шулай да аның тормыш юлын, иҗатын һәм эшчәнлеген бераз күзалларга мөмкин.

ТОРМЫШ ЮЛЫ

Аның кайчан һәм кайда туганлыгы төгәл генә билгеле түгел. Чын исеме, әдәбият галимнәре раславынча, Мөхәммәд Шәриф булырга тиеш, «Кол» атамасы («Аллаһ колы» мәгънәсендә) аның XII гасыр төрки шагыйре һәм фәлсәфәчесе Әхмәт Ясәви тәрикатен тотучы суфилардан икәнлеген күрсәтә. Кырымда яки Хаҗи Тарханда (Әстерханда) туган булырга тиеш, дип фаразлыйлар. Һәрхәлдә Колшәрифнең Казанга күчеп килгәнче Хаҗи Тарханда яшәгәне мәгълүм (тәхәллүсе дә очраклы түгел – Хаҗитархани). Аның атасы Мансур (кайбер мәгълүматлар буенча – Хөсәен) исемле булган. Сәетләр нәселеннән. «Сәет» дип ул вакытларда нәсел җепплә-

Фиринат Халиков рәсеме

ре Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташкан дин әһелләрен атаганнар. Алар дәүләт идарәсендә зур урын биләп торганнар. Алтын Урдадан соң барлыкка килгән ханлыкларда берничә сәет булып, аларның берсен, акылына һәм белемен карап, әлбәттә, бөек сәет итеп сайлаганнар. Безнең көннәргә кадәр сакланган бер шәҗәрәдә, Колшәрифнең атасы Мансур Әстерханда сәет булып торган, дип күрсәтелә. Колшәриф үзе дә Казан ханлыгы чорына караган документларда, 1546 елдан башлап, сәет дип язылган. 1551 елның октябреннан башлап рәсми рәвештә олуг сәет вазыйфасын башкарган. Бу инде дәрәҗәсе ягыннан ханнан кала икенче урында торучы бик зур дәүләт эшлеклесе дигән сүз.

Колшәрифнең олы абруе турында документлар болай сөйли: ул, гадәттә, ак атына атланып Казан урамнарында йөрергә яраткан. Гади шәһәр халкы хөрмәт йөзеннән аны бил бөгеп сәламләгән. Хәтта Сафа Гәрәй хан үзе дә, Колшәриф белән очрашканда, атыннан төшеп, аның чапан итәген үбеп, хәл-әхвәл сорашып, сәламәтлек теләп киткән. Рус кенәзләре исә аңа махсус хатлар юллаганнар, илчеләре аша бүләкләр биреп җибәрә торган булганнар.

Колшәрифнең дәүләт эшлеклесе буларак кылган гамәлләре турында бик аз беләбез. Шунысы гына төгәл мәгълүм: аңа татар дәүләтенең, башкалабызның язмышы кыл өстендә торган иң авыр һәм катлаулы заманда эш итәргә туры килә. Уйлап карагыз: рус гаскәрләре Казанга кадәр килеп җиткән. Зөя тамагында бер ай эчендә, казанлылар сизмәгәндә генә, көчле крепость – хәрби ныгытма калкып чыга. Тау ягының халкы Иван Грозныйга тугрылыкта ант бирә, димәк, аңа буйсындырыла, җирләре Казаннан тартып алына. Башкаланың үзендә исә Сөембикә хөкүмәте соңгы сулышын алырга җыена. Шундый шартларда, 1551 елның июнендә, хөкүмәткә Ходайкол углан белән Нурали Ширин җитәкчелегендәге төркем килә. Һәм, чарасызлыктан, Зөя каласында урнашкан руслар алар арасында йөрүче сатлыкҗан Шаһгали белән сөйләшүләр башлый.

«КАЗАННЫ СУГЫШМЫЙЧА БИРЕГЕЗ!»

Илчелекнең җитәкчеләре итеп Колшәриф сәет һәм кенәз Бибарс Растов билгеләнә. Ике арада шартнамә төзелә. Казанлылар бик авыр хәлдә кала. Шартнамә нигезендә Казан хөкүмәте тәхеткә Шаһгалине утыртырга, Сөембикә белән аның улын – ике яшен яңа тутырган Үтәмеш Гәрәй ханны кулга алып Мәскәүгә озатырга, Казандагы рус әсирләрен азат итәргә тиеш була. 1551 елның 11 августында Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәйне тоткынлыкка озаталар. 14 августта җыелган корылтайда элегрәк төзелгән шартнамәне яңадан бер мәртәбә раслыйлар. 16 августта Казан тәхетенә Шаһгали менеп утыра. 17 августта рус әсирләрен ирекка чыгара башлыйлар.

Шаһгали хан булып озак утыра алмый. 1552 ел башында Иван Грозный аны хан дәрәҗәсеннән мәхрүм итә, Казанга үзенең урынбасары рәвешендә кенәз Семен Микулинскийны җибәрә. Барысы да аңа тугрылыкта ант бирергә мәҗбүр ителәләр. 9 мартта ул тантаналы рәвештә Казанга килеп керергә тиеш була. Әмма аңа шәһәр капкасын ачучы булмый. Кенәз кире Зөя крепостена кайтып китә. Димәк, Казанны Иван патша уйлаганча, тыныч юл белән, сугышсыз гына кулга төшереп булмаячак!

Казанлылар исә хөкүмәт башына Чапкын Отучевны билгеләр. Хөкүмәт составына олуг сәет Колшәрифне дә кертәләр. Үзенең төп максаты итеп Чапкын Отучев ханлыкның мөстәкыйльлеген саклап калуны куя. Хан итеп Әстерханнан Ядегәр исемле угланны чакыралар.

Казанны сугышып алу өчен Мәскәүдән 150 меңлек яхшы коралланган гаскәр чыга. Август аенда алар Зөя каласына килеп җитәләр. Бирелән Шаһгали – Ядегәр ханга, ә Иван Грозный үзе Колшәрифкә хат белән мөрәҗәгать итәләр. Казанны сугышмыйча гына бирегез, дигән таләп куялар. Әлбәттә, әлеге таләп бертавыштан кире кагыла.

Фото: Александр Эшкинин

Август ахырларында руслар Казанны бар яктан да камап алалар. Аталык һәм Түбән капкалары арасына, җирне казып, дары тутырылган мичкәләр куела. Кремль стеналары артына сыенган Казан халкына тагын бер тапкыр мөрәҗәгать итеп карыйлар: исән каласыгыз килсә, каршылык күрсәтмәгез, безнең белән солых төзергә риза булыгыз! Казанлылар солых турында ишетергә дә теләмиләр.

«ИЗГЕ ҖИР БУ!»

4 сентябрьдә беренче шартлау яңгырый. Күпләгән кеше һәлак була, ләкин шәһәрне саклаучылар бирелми. Ай буена диярлек өзлексез сугыш бара.

«...Колшәриф йокламый, йоклый алмый. Дөньяны борчулы уйлар басты. Алар тынгылык бирми, көнен дә, төнен дә миен бораулый, ике чигәсен авырттырып кыса, диван әһелләреннән, бөтен ханлыкның акыл ияләреннән ала алмаган җавапны каян табарга кирәклеген эзләп бәргәләнергә мәҗбүр итә. Бабаларыбызның сыеныр, туеныр урыны – газиз җиребезне, ил-көнебезне, Аллаһы Тәгалә рәхмәте илә Мөхәммәд Галәйһиссәламгә сыенган илдәшләребезне ни көтә?! Йа Алла! Сабырлык, түземлек бир! Белгәнеңне, сизенгәнеңне теш арасына кысып чыдарлык көч бир!»

(Флүс Латыйфиның «Хыянәт» романыннан).

Колшәриф Казан халкы өстенә килгән афәтнең коточкыч зур булуын күңеле белән сизә. Аны нишләргә дигән сорау борчымый. Әлбәттә, халкы белән бергә булырга, ватандашларын изге сугышка рухландырырга! Кирәк икән, үзе дә соңгы сулышына кадәр көрәшәчәк, әмма кол булмаячак!

Фаҗига ахырына якынлаша. 1 октябрьдә рус гаскәрләренә соңгы штурмга әзерләнергә әмер килә. Шәһәрне саклаучыларга һичнинди каршылыксыз бирелергә ультиматум – кискен таләп куела. Казанлылар горур рәвештә: «Буйсынмыйбыз, диварларда һәм башняларда Русь тора. Ләкин без икенче дивар салырбыз, барыбыз да һәлак булырбыз яисә крепостьта сакланып калырбыз!» – дип җавап бирәләр.

2 октябрьдә Аталык капкасы янында колак тондыргыч көчле шартлау нығытмаларның бер өлешен юкка чыгара. Ташлар, кешеләр, бүрәнәләр, җир кантарлары – барысы да күккә оча. Шәһәрне саклаучылар аңга килергә өлгергәнче, тагын да катырак икенче шартлау яңгырый.

Яуды аска уклар...
Атылды таш...
Акты су һәм кайнар сумала...
Изге җир бу!
Анда ансат кына
Бил бирер зат әле тумаган!

(Әхмәт Рәшит).

Рус гаскәрләре, кара болыт булып, Кремльгә ябырыла. Урам сугышлары башлана. Туплар гөрелди, уклар сызгырып оча. Казанлылыр нык торалар, әмма көчләр тигез булмый, әкренләп артка чигенәләр.

Соңгы бәрелеш крепость үзәгендә, Колшәриф мәчете янында бара. Кулларына ни туры килсә, шуның белән коралланган бер төркем мәдрәсә шәкертләре, муллалар, абызлар басып алучыларга каршы һөҗүмгә күтәрелә. Араларында, куркып, дошман каршында тез чүгәргә маташучылар юк. Сугыш мәйданына кулына кылыч-калкан тоткан Колшәриф үзе дә чыга. Моны күреп, шәкертләре тагын да кыюланып китәләр, тешләре-тырнаклары белән дошман өстенә ыргылалар. Күпләре һәлак була. Исән калганнары, Колшәриф сәеткә ияреп, сугыша-сугыша, мәчет ягына чигенәләр. Көрәшнең соңгы минутлары, халык арасында сакланып калган риваятьләрдә әйтелгәнчә, мәчет түбәсендә бара...

Казан җиңелә. Әмма Колшәрифнең һәм ул тәрбияләп үстергән яшь шәкертләрнең искиткеч батырлыгы безнең күңелләрдә бүген дә соклану уята.

КИЛӘЧӘККӘ ӨНДӘҮЧЕ ИҖАТ

Халкыбыз күңелендә Колшәриф үзенең илһамлы шигърияте, рухи бөеклеккә өндәүче әсәрләре белән дә урын алган. Кызганыч, аның бүгенгә кадәр сакланып калган әсәрләре бик аз: безгә аның бары дүрт-биш шигыре, шул исәптән «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» исемле зур күләмле поэмасы һәм дә «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» («Казан иленең җиңүе») дигән чәчмә әсәре генә билгеле. Аның иҗади мирасы болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Барланмаган әле ул, тулысынча өйрәнелмәгән.

Колшәрифне әдәбият белгечләре суфый шагыйрьләр рәтенә кертәләр. Остазлары итеп Колшәриф XII гасырда Урта Азия якларында яшәп иҗат иткән бөек шәхес, әүлия Хуҗа Әхмәт Ясәвине һәм аның шәкерте Сөләйман Бакырганине саный. Аларның әсәрләре Казан ханлыгы чорында безнең якларда да бик киң таралган була.

Шигырьләрендә Колшәриф Аллаһы Тәгаләгә дан җырлый, аны олыларга, һәрчак күңелдә тотарга өнди, фани дөньяда намус белән, нәфескә бирелмичә яшәп, Аллаһ каршына гөнаһсыз барырга чакыра.

Шагыйрьнең «И күңел...» дип башланган газәленә игътибар итик. Ул бирелә тормышның фанилыгын, әҗәлнең рәхимсезлеген, дөньяның башы да ахыры да юклыгын бик матур итеп, гыйбрәтле сурәтләр аша оста итеп ачып сала.

И күңел, биеңне бума (дөнья дип),
Күпне кичергән дөнья бу,
Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дөнья бу.
Син уйлама, дөньяда мин мәңгегә калырмын дип, –
Күп янар вакытта утлар очырган дөнья бу.
Угылны аталан аерып, кызын да анадан шулай ук,
Елатып бер-бер ишектә, зар иттергнән дөнья бу.
Әүвәлен беркем белмәс, ахырын да шулай ук,
Әүвәле юк, ахыры юк, бер сәләмә дөнья бу.
Колшәриф, атаң-анаң синнән никадәр борынгылар иде, –
Барчаны куйнына алып, әшнә иткән дөнья бу.

Колшәриф безгә яңадан кайтты. Казан Кремлендә башкалабызның 1000 еллык юбилеена хәзерлек көннәрендә ачылган мәһабәт мәчет олуг шәхесебезнең исемен мәңгеләштерде, аны бүгенге яшәешебезнең аерылмас өлешенә әверелдерде. Аның исеме белән киләчәктә башкалабызның берәр урамын да атарлар, дигән өмет тә бар әле. Шагыйрь һәм көрәшче образын гәүдәләндергән һәйкәл куярга да вакыт җитте кебек. Колшәриф безне бүген дә киләчәккә өнди, милләтебезне, дәүләтчелегебезне сакларга чакыра.

ИШМИ ИШАН: ИКЕ ДӘВЕР ЧИГЕНДӘ

Аның исеме татар тарихының аерым бер феномены сыман яңгырый, гамәлләре аң-акылга сыймый, кат-кат кайтып уйланырга мәҗбүр итә, ә язмышы тетрәндерә. 100 ел элек Малмыжда атып үтерелгән Ишми ишанның (1842–1919 еллар) шәхесе турында без ниләр беләбез?

Автор:
Айдар Шәйхин

ДӨНЬЯ ИКЕГӘ БҮЛЕНГӘЧ...

Ишми ишанның чын исеме – Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов. «Ишми» дигән авылча, гади кыскартылма рәвештә кулланыла башлаган атамасы исә тора-бара үзенә күрә бер кимсетү чарасына әверелгән. «Ишан» титулы халыкның аңа карата булган хөрмәтен чагылдырган, ләкин чынлыкта Ишмөхәммәт хәзрәт үзе ишанлык дәрәҗәсенә ия булмаган. Димәк, аның исеме дә тарихның ялган һәм уйдырмадан арындыруга мохтаҗ чираттагы бер мифы яки стереотибы.

Ишмөхәммәт хәзрәтнең исеме XIX гасыр ахыры–XX гасыр башында татар дөньясында җәелгән драматик каршылык белән бәйле. Башта мәктәпләрне һәм укыту алымнарын үзгәртеп кору һәм заманчалаштыру хәрәкәте буларак формалашкан җәдидчелек татар җәмгыятенең төрле өлкәләренә үтеп кергән көчле идеологиягә әверелә. Дөньяга консерватизм күзлегеннән караган, «искелек тарафдарлары» дигән яманат алган кадимчеләр хәрәкәте дә зәгыйфь каршылык кына булмый, аның да вәкилләре, бар көчләрен куеп, үзләре дөрес дип санаган яшәү принциплары өчен көрәшә. Ике якның да төп максат-хыялы бер: катлаулана барган заманда милләтне һәм динне саклап калу. Ләкин максатка ирешү юллары халыкның асыл улларын ике лагерьга бүлә.

«Ишми ишан» кадимчеләр хәрәкәтенең иң атаклы вәкиле буларак еш искә алына. Ул хәзерге Мамадыш районының Югары Сөн авылында туган. Әмма гыйлем юлы аны бик яшь чагында ук Малмыж өязенең данлыклы Түнтәр авылына (хәзерге Балтач районы) китерә. Нәкъ менә Түнтәрдә ул үзе дә инде атаклы хәзрәткә әйләнә. Нәкъ биредә кискен консерватизм белән сугарылган хезмәтләрен яза, мәдрәсәсендә дөньяга кадими күзлектән караучы шәкертләрен тәрбияли. Шуңа да, аны яхшырак аңлар өчен, без шушы авылга юл тоттык.



ТҮНТӘР ФЕНОМЕНЫ

Түнтәр авылы халкы бәхетледер, мөгаен. Аның тарихын бөртекләп җыючы һәм кадерләп саклаучы кешеләре бар. Без мәктәптә озак еллар укытучы булып эшләгән **Рәфхәт Зарипов** (ул 1941 елгы) белән очраштык. Ул авылның үткәннәренә багышлап берничә китап язган, аларны Интернетта урнаштырган. Рәфхәт абыйның тәмләп һәм башка беркем дә игътибар итми торган үзенчәлекле детальләргә тукталып сөйләвеннән Түнтәр феноменын берникадәр дәрәҗәдә аңладык.

Бу авыл XVII гасыр ахырында нигезләнгән булса кирәк. 1730 елда монда Габдеразак хәзрәт күчеп килә. Түнтәрнең гыйльми тарихы әнә шул чорда башлана, 1740 елда беренче мәдрәсә ачыла. Авыл халкы Габдеразак хәзрәтне беренче имам буларак истә калдырган. Хәзергесе көндә аның кабере булырга тиеш урында зур кабер ташы куелган.

Гаяз Исхакый үз заманында Идел-Урал төбәгендәге иң абруй-

Фото: Александр Ефремов

лы суфи ишаннар турында язганда, өч шәхескә туктала: Троицкидагы Зәйнулла ишан Рәсүлевка, Чистайдагы Закир ишан Камаловка һәм Балтачтагы Мөхәммәтгали ишан Түнтәригә (1788–1874). Түнтәр мәдрәсәсенең тирә-яктагы иң көчле уку йорты буларак танылуы Мөхәммәтгали ишан белән бәйле дә инде.

Мөхәммәтгали ишан башта шушы төбәктә белем ала: Сасна авылында, Мәчкәрә мәдрәсәсендә укый. Шуннан соң Бохарага китә, Әфганстан һәм Һиндстанда сәяхәт итә. Түнтәргә кайткач, имамлык вазыйфасын башкара башлый һәм тарихка кереп калган Түнтәр мәдрәсәсен ача. Мөхәммәтгали ишанның абруе һәм белеме нәтиҗәсендә мәдрәсә бик тиз арада илнең төрле почмакларыннан килгән шәкертләрне имамлыкка әзерләүче көчле уку йорты булып өлгерә.

Ишмөхәммәт Динмөхәммәт улы да шушы мәдрәсәдә укый. Мөхәммәтгали ишан игътибарлы һәм сәләтле шәкертне тиз күреп ала. Аның киңәше белән Ишмөхәммәт Бохарага китә, анда белем алганнан соң, кабат Түнтәргә кайта. Бу вакытта Мөхәммәтгали ишанның дәвамчысы булып аның кияве Шәмсетдин хәзрәт хезмәт итә. Ул да вафат булгач, авыл халкы Ишмөхәммәтне имам итеп сайлый. 1877 елда ул Түнтәр мәхәлләсенең имам-хатибы булырга указ ала.

Шулай итеп, Ишми ишан Түнтәр авылының инде тарихы һәм исеме булган мәдрәсәсен дә җитәкли башлый. Рәфхәт абый Зарипов аны тирән белемле, көчле ихтыярлы, үз сүзендә нык торучан кеше булган дип тасвирлый. Аның чорында мәдрәсәнең чәчәк атуы дәвам итә. 1887 елда сәүдәгәр Габделлатыйф Хәкимов акчасына мәдрәсә өчен ике катлы яңа бина төзелә. Димәк, шәкертләр саны арткан була. Бу исә аның педагог һәм җитәкче буларак уңышы турында сөйли, дип фаразлый алабыз.

«Ишмөхәммәд хәзрәт гаять мәһабәтле, сөйләү остасы, калын яңгыравык тавышлы, югары дәрәҗәдә эшчән, аралашканда яхшы ук кырыс кеше иде, дип сөйләгәннәре бар. Әмма аңа әңгәмәдә җор сүз, образлы үткен фикер дә ят булмаган.

Тирә-юньдә дә, Түнтәр әйләнәсендә генә түгел, ераграк төбәкләрдә дә, хәзрәтне тирән ихтирам итүче, аңа иярүче мөселман халкы аз булмаган булса кирәк. Нократка якын туганнарына, никах мәҗлесенәме, бер чакырулы тантанага барганнарын сөйләгәне бар әтинең. Поезд килеп туктауга (Слободская станциясе дип хәтердә калган) якын-тирә авылларыннан хәзрәтне каршы алырга дип җыелган мөселманнар вагон баскычыннан ук палас юл җәеп җибәрәләр. Күрше илнең патшасы килгәнмени. Кунакны утыртып китәргә тиешле пар ат чанага кадәр бабай шушы келәмнән атларга тиеш була. Көтелмәгән хәлдән югалып калган хөрмәтле кунакны җитәкләп, этеп-төртеп диярлек чана янына алып килеләр. Тик бераз аңына килгәч кенә, бу эшне болай оештыручыларга бабай үзенең шелтәсен белдерә».

(Оныгы Фәрук Нәкыйпов язмасыннан. Р.Зарипов. Аллаһка якынаю юлында. Түнтәр, 2017)



Центральное Духовное Управление Мусульман России.

Свидетельство.

Ишми ишанның улы Мөхәммәтнәкыйп хәзрәткә бирелгән имамлык указы. 1925 ел

Югарыгы мәчет бинасы. 1831–1834 елларда төзелгән

ИШМӨХӘММӘТ ХӘЗРӘТНЕҢ КӨРӘШЕ

Җәдидчелек хәрәкәте киң таралгач, Ишмөхәммәт хәзрәтнең аяусыз көрәше башлана. Бу мәсьәләдә ул аз гына компромисска да риза булмый. Аның фикеренчә, динне һәм милләтне саклау хакына моңарчы гасырлар буена яшәп килгән һәм бик куркыныч заманнарда халыкны иманлы итеп саклый алган юлдан тайпылмаска кирәк. Җәдидчеләр тәкъдим иткән яңа белем бирү ысуллары аның өчен исламның котылгысыз һәлак булуының бер билгесе булып күренә. «Исән калганнар мөселман диненең ничек корытылачагын күрерләр», – дип яза ул.

Хәзрәт консерватизм, булганны саклау һәм изоляция тарафдары була. Мөселман җәмгыяте дәүләттән аерым яшәргә һәм үз эченә йомылырга тиеш. Шуңа да мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәүләт акчасын да сарыф итәргә ярамый. 1911 елда ул патшага хат яза һәм мөселман мәктәпләрендә кадими ысул буенча укыту программасын мәҗбүри итеп кертергә тәкъдим итә. Әмма бу хатта шунысы кызык: программаның нигезен схоластик фәннәр тәшкил итсә дә, хәзрәт дини гыйлемнән соң дөньяви белем дә бирелсен, дип ассызыклый.

Ул үзенең хаклы булуына, сайлаган юлының дөреслегенә һичбер шикләнүләрсез ышана. Җәдидчелек вәкилләре белән төрле ысуллар кулланып көрәшүенең, шикаятьләр язуының һәм матбугатта даими бәхәсләренең сәбәбе дә принципларына тугры булуында.

> *«Бу мөҗәддитчелек хәрәкәте Рәсәй мөселманнарын гафләт һәм наданлык йокысыннан уяту, «аң-белем тарату» фикереннән башланып китте. Моны мөршитләр башлап җибәрде: Курсави, Мәрҗани, Баруди, Риза казый, Хәйрулла, Рәшит әфәнделәр. Бу әфәнделәр, политикага һәм тәэсирле сүзгә бик маһир булып, шәригатькә хилафлы булган күп нәрсәне яклап, зиннәтләп, нәфескә ошый торган сурәткә кертеп күрсәткәч, боларны ана теле белән саташкан надан халык һәм белемсез муллалар гына әлеге әфәнделәрне ислахчы һәм мөҗәддит итеп күрделәр».*
>
> ***(И. Динмөхәммәтов «Шәригатьне торгызу шартлары»).***

ИКЕ МӘДРӘСӘ, ИКЕ ХӘЗРӘТ

Мөхәммәтгали ишанның оныгы Мөхәммәтнәҗип хәзрәт (1862–1930) Ишми ишан чорында авылда икенче имам була. Җәдидчелек-кадимчелек каршылыгының бер эпизоды аларның мөнәсәбәтләрендә чагыла. Нәҗип хәзрәт авылда үз мәктәбен – мәдрәсәсен ача һәм анда яңа ысул буенча укыта башлый. Мәдрәсәнең дәресләр җәдвәлендә география, математика, милләт һәм Россия тарихы, татар теле дәресләре була.

Ишмөхәммәт хәзрәт белән конфликт аркасында Мөхәммәтнәҗип авылдан китәргә мәҗбүр була, сөргенгә җибәрелә, ахыр чиктә Казанга Галимҗан Баруди янына барып урнаша.

Түнтәр авылында Ишмөхәммәт хәзрәт белән Мөхәммәтнәҗип хәзрәт мәдрәсәләренең биналары арасы 100 метрга да тулмый. Әмма идеяләр шуның белән дә көчле инде: алар күзгә күренмәс биек диварлар корырга һәм күрше белән күрше арасында упкын булдырырга сәләтле.

Без сурәтләгән очракта исә идеяләр каршылыгының нәкъ уртасында кадими һәм җәдиди мәдрәсәдә укыган шәкертләр калган. Күрше биналарда белем алган егетләр вакыт-вакыт дин һәм илаһият мәсьәләләренә кагылышлы бәхәсләрдә катнашырга мәҗбүр булган. Полемика бу каршылыкның төп коралына әверелгән.

Ишмөхәммәт хәзрәт мәдрәсәсе, башка консерватив уку йортлары кебек үк, төгәл һәм кырыс дисциплинасы белән данлыклы булган. Катгый кагыйдәләргә түзә алмаган яки чикләргә сыешырга теләмәгән шәкертләрнең кай-

Мөхәммәтнәҗип хәзрәт кулындагы җәдиди мәдрәсәнең уку бинасы. 1905–1907 елларда төзелгән

Ишми ишанның кадими мәдрәсә биналарының берсе. 1912–1914 елларда сәүдәгәр Хәкимов акчасына төзелгән

берләре, Түнтәрдән качып, Бубилар мәдрәсәсенә дә киткәләгән. Бәлки, Ишмөхәммәт хәзрәтнең Иж-Бубидагы белем учагына кискен каршы булуын әлеге факт та көчәйткәндер.

ГАИЛӘ ДРАМАСЫ

Җәдидчелек белән кадимчелек каршылыгы, асылда, Ишмөхәммәт хәзрәтнең гаиләсен дә икегә бүлә. Аның балаларын ниндидер надан мулла тәрбиясендә үскән караңгы кешеләр дип әйтеп булмый. Алар рус телен дә өйрәнгәннәр, улы Нурлыгаян исә хәтта бухгалтерлар мәктәбен тәмамлый, инкыйлабтан соң кызыл командир була. Икенче улы Габделхәй мәгърифәтче һәм язучы буларак билгеле. Нурислам гомерен укытучылыкка багышлый. Кызы Латыйфа мөселман дин эшлеклесе, «Хөсәения» мәдрәсәсендә гарәп теле укытучысы Кәрамәтулла Айдаровка кияүгә чыга, аларның улы – дирижер Җәүдәт Айдаров. Хәзрәтнең төпчек улы Мөхәммәтнәкыйп исә, аның чын дәвамчысы булып, 1926–1932 елларда авылда имамлык итә. Ишми ишанның исемен аклауга зур өлеш кертүче Фарук Нәкыйпов Мөхәммәтнәкыйпның улы.

Катгый инанулар белән яшәгән хәзрәтнең балалары, шулай итеп, нигездә җәдидчелек юлына басалар. Бу чорда җәмгыятьтә хөкем сөргән идеяләр каршылыгын ошбу факт тагын да ачыграк тасвирлый сыман.

СОКРАТЧА АДЫМ

1918 елның көзендә Түнтәр мәдрәсәсе ябыла, аның биналары дәүләт карамагына күчерелә. Шушы көннәрдә үк Ишми ишанга авылдан качу ягын карарга тәкъдим итәләр. Бу мизгелдә Ишмөхәммәт хәзрәт Сократныкы сыман адымга бара: үзен ни көткәнен чамалаган хәлдә дә ул язмышына карышудан баш тарта.

Ярты елдан соң, Малмыж өязендә тагын 20ләп мулла һәм поплар белән бергә, кулга алына. Большевикларның мантыйгы бик гади: абруйлы имамнар һәм руханилар, халыкны өндәргә керешеп, акларны якларга күндермәсен. Кулга алынган дин әһелләрен Малмыжда, пристань янында атып үтерәләр. Шулай итеп, Ишмөхәммәт хәзрәтнең гомере 1919 елның 8 маенда өзелә.

Хәзрәтне рәсми рәвештә җирләргә рөхсәт бирелми. Аның мәетен хезмәтчесе Хөсәен Мөхәммәтҗанов белән Әмин Йосыпов ат белән урлап алып кайталар. Түнтәрдә яшереп җирләү турында сүз дә булмый: барыбер авылга килеп, каберлекне тузгытырлар иде. 42 ел имам һәм мөдәррис булган, халык Дамелла дип хөрмәтләгән Ишмөхәммәт хәзрәтне кара мунчада юып, кәфенләп, Борнак авылы зиратында җирлиләр. Каберенең төгәл урыны бүгенгесе көнгә кадәр билгеле түгел. Әмма Әмин Йосыповның дәвамчысы Тәлгать әфәнде әйтүенчә, хәзрәтнең кабере аңа билгеле.

Бәлки, якын арада зиратта истәлек билгесе дә куелыр?

ТАССР 100 лет / ел

БУЫННАР

«Татарстан» журналының махсус проекты

Фото: Александр Эшкинин

Татарстан Республикасына 100 яшь тулырга бер елдан да кимрәк вакыт калып бара. Түгәрәк һәм мөһим юбилей – гасыр гына түгел, тарихның аерым бер чоры! Республиканың адашы һәм аның игезәк туганы – «Татарстан» журналы уртак юбилей датасына «Буыннар» дип аталган проект әзерләде. Һәм әлеге проект кысаларында Татарстаныбызның зур тарихын төзүче кешеләр турында сөйли. «Буыннар»ның беренче чыгарылышында без узган йөзьеллыкның 20 нче елларында Татарстан тарихын башлап җибәргән кешеләр һәм вакыйгалар турында сөйләдек*.

30 нчы еллар буынына бөек парадокслар заманында – моңарчы булмаган энтузиазм һәм кырыс репрессияләр чорында яшәргә туры килә**.

Бүген без 40 нчы еллар буыны – язмышларына сугыш белән сыналу язылган кешеләр турында сөйләрбез. Бөек Җиңүдән соң узган 74 ел эчендә инде барысы да сөйләнелгән кебек: татарстанлылар кайларда сугышкан, кемнәр фронттан кайта алмаган, җиңү өчен тылда ничек көрәшкәннәр… Шуңа да карамастан, һәрвакыт ниндидер архивларда, әбиләребезнең хәтер сандыгында, эзләнү эшләре алып барылган сугыш урыннарында Бөек Ватан сугышының яңа вакыйгалары ачыла, дөньяга чыга, һәм алар безгә батыр якташларыбыз турында әлегә белмәгәннәребезне кайтара.

ҖИҢҮЧЕЛӘР БУЫНЫ

Сугыш елларында Татарстан ничек яшәгән? Фронтка күпме доброволец киткән? Һәлак булучылар исемлеген кемнәр тутырган? Тыл хезмәтчәннәре үтә ярлы паёкка ничек яши алган?

1 НЧЕ ВАКЫЙГА

Ә ИРТӘГӘ СУГЫШ ИДЕ...

90 нчы урта мәктәпнең чыгарылыш альбомы

2 НЧЕ ВАКЫЙГА

АГАЧЛАР – ҖИҢҮ ШАҺИТЛАРЫ.

Ни өчен үлеп баручы авиатөзүчеләр парк утырткан

3 НЧЕ ВАКЫЙГА

КАЗАННАН КОСМОСКА КАДӘР.

Ни өчен гамәли космонавтикага нигез салучы Сергей Королёв атна саен «Черек күл»гә йөргән

4 НЧЕ ВАКЫЙГА

БЕРЕНЧЕ ТАТАР БАЛЕТЫ – «ШҮРӘЛЕ».

Композитор ничек укчы взводы командирына әверелгән

5 НЧЕ ВАКЫЙГА

МИН РЖЕВ ЯНЫНДА ҮТЕРЕЛДЕМ...

Ни өчен политрук Мөхлис Хәеров фронтка китәр алдыннан гаиләсенә бәйрәм ясаган

6 НЧЫ ВАКЫЙГА

ИДЕОЛОГИК ФРОНТ СУГЫШЧЫЛАРЫ.

Халык тарихыннан Алтын Урда кая югалган

*«Татарстан», № 07, 2018 ел.
** «Татарстан», № 3, 2019 ел.

Фото: Александр Ефремов

«БУЫННАР» ПРОЕКТЫ

Ә ИРТӘГӘ СУГЫШ ИДЕ... БЕР МӘКТӘП АЛЬБОМЫНЫҢ ТАРИХЫ

Фотоальбомны ТР Милли музее тәкъдим итте

Без Казандагы 90 нчы кызлар мәктәбе укучыларының Бөек Ватан сугышы еллары чорындагы альбомын ачабыз. Аны рәссам Ф.Купцов бөтенләй бушка төзегән – фотоларны ябыштырган, каләм белән тип-тигез итеп хәрефләрне, хәзергечә әйтсәк, инфографиканы ясаган. Бик матур һәм самими, кай ягы беләндер дембель альбомына охшаш булып чыккан ул.

Бу мәктәп 1936 елда ачылган. 1942 елда 10 сыйныфны тәмамлаган беренче укучыларын чыгарган. Малайларны шунда ук фронтка озатканнар. Аннан соңгы битләрдә алар инде – «Бөек Ватан сугышында катнашучылар» буларак – мәктәпнең һәм сыйныфташ кызларының горурлыгы. Чыгарылышның беренче партиясен сугышка озатканнан соң, 1943 елдан мәктәп кызларныкына әверелә, ә герой-чыгарылышны фронттан көтәр кешеләр була. Ә альбомда шундый юллар барлыкка килә: «Безнең мәктәп укучылары фронтка доброволец булып киттеләр: алар 10 нчы сыйныф укучылары Нәзиров Р., Карпов Н., Моратов Р., Галимов И...» Карпов һәм Галимов, сүз уңаеннан, сыйныфташ кызлары янына әйләнеп кайтмаган. Аннары фронтка кызларны да ала башлаганнар: «Кызыл армия сафларына чакырылган кызлар да сугыша: Сергина А., Булатова С., Туктарова И., Бикмуллина...» Чакырылыш яшенә җитмәгән башка кызлар фронтка булыша, тимурчылар булып эшли, госпитальгә шефлык итә...

Сугыш тарихының нәни генә бер кисәген үзенә сыйдырган бер мәктәп альбомы тарихы бу нибары. Әлеге тарих бүгенге көндә мәктәпне тәмамлаучыларның барысына да багышлана – бервакыт, зур кешеләр булгач, тормышыгызны азга гына булса да яңадан күздән кичерәсегез килгәч, мәктәп альбомыгызга күз салыгыз... Һәм тормышыгыз яңадан кабатлансын, ә сугыш – кабатланмасын.

Участники Отечественной войны

Вероломное нападение немцев в 1941 году всколыхнуло все население нашей страны. Юноши и девушки вступили добровольцами в ряды Красной Армии.

Ученики нашей школы не прошли мимо этого благородного поступка и в первый же год войны ушли на фронт добровольцами. Это были ученики 10го класса: Назиров Р., Карпов Н., Муратов Р., Галимов И.

ученик Ситников Иг. (ранен)

В рядах Красной Армии честно боролись и призванные ученики: Михайлов А., Ахмадуллин Р., Галимов Я., Кутуев Ис. Бахтеев Ш., Гаврилов Н., Лёнин Ал., Бурмистров Н., Рубцов Г. Вилков И., Ситников Иг., Осипов В., Сайфуллина А., Краснов Ю., Сергина А., Булатова С., Туктарова И., Бикмуллина.

Из преподавательского состава участвовали в Отечественной войне директор школы Тюрин В.Ф. и преподавательница русского языка и литературы Ревина Л.К.

Директор школы Тюрин В.Ф.

Участники Отечественной войны.

Школа готовит убежденных, стойких, непобедимых борцов за Родину!

Ученик Галимов И.

Преподавательница Ревина и учащиеся Назиров, Михайлов, Бикмуллина, Туктарова-зенитчица имеют правительственные награды „За отвагу" и др. отличительные знаки.

Преподават. Ревина Л.К.

Участники Отечественной войны.

За весь период войны наши ученики и коллеги вели переписку со школой. В своих письмах они рассказывают о военных походах и о своем участии в них. В письмахс восхищением вспоминают всех своих преподавателей, которые воспитали их такими патриотами

„Я много думаю о школе и вспоминаю прошкольную жизнь. Она оказывается самая интересная. Она научила бороться. Все думаешь, как бы лучше расправиться с фрицами, чтобы другие могли спокойно учиться и работать по старому..." (из письма Галимова.)

„....Передайте привет Ольге Андреевне, я перед ней, оказывается, был неправ заявляя, что немецкий язык мне знать не к чему, дипломатом я не буду. Привет Марии Гавриловне и скажите ей, что теперь-то я знаю, что значит лесисто-болотистая местность, а то в школе я никак не запоминал." (из письма Назирова)

уч-к Муратов Р.

ученик Ахмадуллин Р.

Участники Отечественной войны.

Честно борясь на фронтах Отечественной войны, многие из учащихся вернулись с тяжелыми ранениями. Они не пали духом, а как только окрепли физически, пошли учиться, чтобы и в дальнейшем быть полезными своей родине. Память о погибших смертью героев Карпове Н. и Галимове Я. никогда не умрет в наших сердцах.

9 мая 1945 г. был день Победы! День, когда весь наш народ мог свободно и легко вздохнуть. Тяжелый путь пройден, впереди ожидает светлое будущее мирного строительства.

Да здравствует тов. Сталин, приведший нас к этой славной победе над вероломным и коварным врагом!

ученик Назиров

ученик Михайлов А.

ученик Карпов (погиб)

Из сочинений учащихся

„Теперь можно сказать, мы стоим на пороге жизни. Мы все должны видеть жизнь в действительности. Говоря о жизни хочется повторить слова А.П. Чехова: „Жизнь дается только раз, и хочется прожить ее бодро, осмысленно, красиво". (уч-ца Муратова - X класс).

„Мы будем стойкими борцами за счастье своей Родины, за независимость советского народа" (уч-ца Калинина - X класс).

„Я преклоняюсь перед красивым. Жизнь без красоты для меня не имеет смысла. Самое красивое для меня - это книги, музыка, природа. Читая книгу, я вижу ее героев, обстановку, их глаза, жесты, мимику, слышу их голоса. Но когда я вижу на экране, я еще полнее и сильнее чувствую их жизнь, стремления и характеры. Кинокартины производят на меня сильное впечатление. Они учат жить, воспитывают. Моя мечта — стать кинорежиссером" (уч-ца Мишина - X класс)

VI-е классы писали сочинения по открыткам. Описание открытки с употреблением наречий, для закрепления темы „Наречие". Писали сочинение „День победы". Шестиклассницы заканчивают сочинения патриотическими восклицаниями: „Да здравствует народ-победитель!(Озолина). „Да разве есть на свете такая Армия, которая превосходила бы русскую!" - (Нигматзянова). „Великий день - самый радостный из радостных дней!" - (Абдуллина Роза). Вот сбылись слова великого Вождя: „Будет и на нашей улице праздник!" (Бухараева).

Помощь фронту

Пионерская дружина в помощь фронту Отечественной Войны посылала к каждому празднику подарки, за что получили от воинов десятки благодарностей.

Школой с начала войны отправлено на фронт и госпиталя:

Кисеты - 2890 штук.
Платки - 1600
Одеколон - 900
Мыло - 1950
Зубн. порош. - 8595
Папиросы - 670
Спички - 12325
Карандаши - 1595
Конверты - 20360
Открытки - 11840
Мундштуки - 370
Зубные щетки - 535
Зажигалки - 124
Носки - 42 пары
Варежки - 61 пара
Бумага, табак и т.д.

Работали тимуровцы

За время войны при каждом пионерском отряде были организованы тимуровские команды, которые оказывали помощь семьям и детям фронтовиков. Работа их заключалась в распиловке, колке и подноске дров, уборке квартир, уходе за детьми и т.д.

Отличилась тимуровская команда отряда им. „Олега Кошевого" 7а класса. Капитан этой тимуровской команды Кутышева Фая на слете тимуровцев получила грамоту Горкома ВЛКСМ. Всего школа за годы Отечественной войны посетила 346 семей фронтовиков.

Пионеры принимали участие в благоустройстве города: озеленение сада при кинотеатре „Чаткы" и бульвара по озеру Кабан.
Работали на пришкольном участке по посадке и сбору овощей в совхозе.
Работали на уборке школы и школьного участка.

Тимуровская команда.

Связь с фронтом

За время войны пионерская дружина поддерживала крепкую связь с фронтовиками.
Эта связь выражалась в переписке с фронтовиками. С начала войны получено 400 писем фронтовиков, а послано более 1000 писем.
Связь выражалась и в беседах с фронтовиками, которые проводились на сборах, посвящённых встрече с фронтовиками.

Шефство

Пионерская дружина шефировала над госпиталем №1311. и батальон. выздоравливающих №28. Проведено 67 концертов художественной самодеятельности в госпитале и 48 концертов в батальоне выздоравливающих.

Починили 9800 пар белья, за что получили благодарность от командования воинской части п/п 73443.
Сшили 345 пар варежек из шинельного сукна, за что также получили благодарность.

«БУЫННАР» ПРОЕКТЫ

АГАЧЛАР – ҖИҢҮ ШАҺИТЛАРЫ

Казанның Авиатөзелеш районында урнашкан гаҗәеп «Крылья Советов» паркы буйлап йөргәндә, аның Бөек Ватан сугышы белән бәйле булуын башыңа да китерә алмыйсың.

Автор:
Наталья Урейская

Паркта бик тыныч – анда сугыш елларында авиатөзүчеләр тарафыннан җитештерелгән легендар Пе-2, По-2, Пе-8 бомбардировщикларына бер генә ишарә дә юк. Аллеяләр буйлап бала арбаларын этеп яшь әниләр йөри, эскәмияләрдә әбиләр ял итеп утыра, яшьләр Ленин һәйкәле янында селфи ясый, балалар мәйданчыгында – авиатөзүчеләр бүләге: кечкенә «Ансат» вертолёты һәм күпфункцияле Ту-214, соңгысы нәниләр өчен спорт тренажёры ролен үти.

1942 ЕЛНЫҢ ЯЗЫ

Парктагы агачларның Бөек Җиңүнең шаһитлары булуы турында бик сирәкләр генә беләдер. Алар арасында 1942 елның язында утыртылганнары да бар, сугышның гаять авыр чорында самолётлар җитештерүгә бәйле драматик вакыйгаларда катнашканнар алар. Коточкыч авыр хезмәттән, салкыннан һәм ачлыктан кешеләр станок янында ук үлеп китә торган авыр чор. Завод ашханәләрендә азык-төлек җитми. Булган ризык фронтка озатыла, шуннан калганы гына хастаханәләргә, госпитальләргә, балалар бакчаларына, предприятиеләргә бүлеп бирелә. Авиация заводында бик күп яшүсмерләр эшли. Ашау, витамин җитмәү сәбәпле, авырулар, ачлыктан аңнарын җуеп егылулар – адым саен.

БЕР КӨНГӘ СОҢРАК ҮЛҮ

Завод директоры Василий Окулов завод эшчеләрен ашатуга зур игътибар бирә. Эшчеләр авитаминоздан интекмәсен өчен, кычыткан һәм кузгалак әзерләнә. Ашханә хезмәткәрләре завод аэродромы тирәсендәге үләннәрне чабып, алардан төнәтмә ясыйлар. Аеруча хәлсезләнгәннәргә көчәйтелгән өстәмә паёк – «усиленный дополнительный паёк, ягъни УДП бирелә. Бу паёкка сыра чүпрәсе, тагын бер телем ипи, шикәр керә. Ач эшчеләр әлеге кыскартылма сүзне, таркатып, үзара шаяртырга да көч табалар: «умрёшь днём позже».

ИҢ ХӘЛСЕЗЛӘРНЕ – ПАРККА, АГАЧ УТЫРТЫРГА!

1942 елның язында заводның күп кенә эшчеләре чын мәгънәсендә яшәү белән үлем арасында кала. Дымлы салкын цехларда авыр физик хезмәт кешеләрне тулысынча йончыта-хәлсезләндерә. Шул чакта директор иң хәлсезләрне паркка – агач утыртырга җибәрергә тәкъдим итә. Җылы, язгы саф һавага. Монда килеп, эшнең ничек баруы белән кызыксынгач, директор ярсулы җавап ишетә: «Син безне немецлар өчен агач утыртырга җибәрдең, алар Казанга килеп, шушы паркта йөриячәкләр!» Бу сүзләр Василий Андреевичның йөрәгенә уктай кадала, ул бит кешеләрнең гомерен саклап калу өчен бөтен көчен куя. Җавап тирән яра булып кала – Окулов сугыш чорында иң истә калган нәрсәнең әлеге сүзләр булуын еш кабатлый. Үзенең бөтен көчен туплап җавап биргәнен дә хәтерендә саклый: «Шушы агачлар күләгәсендә сез үзегез, балаларыгыз һәм оныкларыгыз ял итәчәк. Бу җиргә немецлар килмәячәк. Мин моңа юл куй-

Фото: Александр Эшкинин

маячакмын, без беребез дә моңа юл куймаячакбыз!»

НЕМЕЦЛАР СОЦГОРОДТА

Шулай да Василий Андреевич бер нәрсәдә ялгыша – немецлар килә бу җиргә. Тик хәрби әсирләр сыйфатында. Сугыштан соң алар Соцгородта Воронеждагы һәм Мәскәүдәге туган йортларыннан үзләре куып чыгарган кешеләр өчен торак йортлар төзи.

Воронеждагы 16 нчы авиамоторлар төзү заводы 1941 елның 7 октябрендә эвакуация турында әмер ала. Ике ай дәвамында Казанга 931 вагон килеп җитә. Җиһазлар, станоклар, кешеләр белән. Станоклар һәм җиһазларны Казан моторлар заводына куялар, кешеләрне исә кайда урын бар, шунда урнаштыралар. Шул исәптән – землянкаларга да. Казан һәм Воронежның берләштерелгән заводлары директоры итеп Макар Лукинны билгелиләр (Авиатөзелеш районындагы бер урам аның исемен йөртә – авт.), ул да Василий Окулов кебек үк зур ихтирамга ия һәм абруйлы кеше була. Василий Окулов исә шулай ук берләштерелгән ике заводның – Казанның һәм 1941 елның көзендә Мәскәүдән эвакуацияләнгән авиация заводының – директоры. Яңа килгән авиация һәм моторлар заводлары эшчеләрен, шул исәптән Соцгород микрорайонында яшәүчеләрнең фатирларына да тараталар. Эркерлы, имән паркетлы һәм колонналы зур заллары булган мәһабәт «сталинка»ларга берьюлы берничә гаилә яшәргә керә. Сугышка кадәр мондый шартларда инженерлар, авиаконструкторлар, авиация җитештерүе җитәкчеләре һәм хезмәт алдынгылары яши. Әлеге йортларны заманы өчен иң алдынгы Мәскәү һәм Ленинград архитектура остаханәләре проектлаштырган була. Проектларда иркен ишегаллары, скверлар, стадион һәм әлеге дә баягы парк күздә тотыла...

Фатирлар тиз арада коммуналкаларга әверелә. Колонналы зур бүлмәләрдә берничә гаилә яши, кайсы гаилә – ванна бүлмәсенә, кайсыдыр аш бүлмәсенә урнаша. Мөмкин булганча тыгызланалар.

Сугыш ахырында Соцгородта бараклар пәйда була, анда немец әсирләрен урнаштыралар. Һәм алар үзләрен җиңгән халык өчен яңа торак йортлар төзергә керешә.

ҖИҢҮ ӨЧЕН «ПОБЕДА»

Өр-яңа фатирларга Воронеж һәм Мәскәү кешеләре күчә. Казан авиация заводы ветераны Леонид Ополинский әнә шундый эвакуацияләнгән Мәскәү кешесенең улы була. Леонид шул йортларның берсендә (Белинский ур., 8) Советлар Союзы Герое, сынаучы-очучы Александр Васильченко фатиры астында яши. Һәм ул бөтен ишегалды малайларының «дядя Саша»ның «Победа»сына кереп тулуларын һәм бергә аэропортның тәүлек әйләнәсе эшләүче ресторанына сыйланырга баруларын бик яхшы хәтерли. Александр Васильевич Васильченко «Победа»га Җиңүгә керткән өлеше өчен лаек була. Нәкъ менә ул Сергей Павлович Королёв белән бергә ракеталы тизләткечләр белән җиһазландырылган «Пе-2» бомбардировщикларын сыный.

Леонид Владимирович үз йортларының фасады янында кирпеч тезүче немецларга балконнан бауга бәйләп ипи төшерүен дә искә ала. Изге күңелле малайга әсирләр рәхмәт әйтә. Ә менә күршесе Динә Евсеевна Потехинаның әсирләргә ризык бирергә кулы күтәрелми, гәрчә элекке дошманнарын кызганса да. Сугышның беренче көннәреннән ахырына кадәр госпитальдә эшләп, кайгы-хәсрәтне күп күргән табиб буларак, ул әлеге әсирләрнең кешеләргә һәм аның үзенә дә күпме югалтулар китергәнен яхшы белә. Ханымның өч туганы фронттан әйләнеп кайтмый.

АВИАТӨЗҮЧЕЛӘРНЕҢ ОНЫКЛАРЫНЫҢ БАЛАЛАРЫ

Әйе, немецлар, чыннан да, Соцгородка килгән. Һәм җирле халык аларга ачтан үләргә ирек бирмәгән. Һәм хәлсезләнгән завод эшчесенең усал сүзләренә җавап кайтарган генерал-лейтенант Василий Окулов хаклы булган – үлем чигенә җиткән авиатөзүчеләр утырткан парк буйлап бүген аларның балалары, оныклары, оныкчыклары йөри. Әти-әниләре белән дә, яшьтәшләре белән дә, экскурсовод белән дә – авиация һәм моторлар төзү заводлары ул чор кешеләренең хезмәт һәм хәрби батырлыклары турындагы хатирәләрне саклый, әлеге истәлекләрне яңа буыннарга җиткерергә тырыша.

Леонид Владимирович үз йортларының фасады янында кирпеч тезүче немецларга балконнан бауга бәйләп ипи төшерүен искә ала.

«Хөрмәтле Динә Евсеевнага (беренче рәттә, сулдан беренче – авт.) истәлеккә 7 нче палата командирларыннан. 1943 елның 20 августы» дип язылган әлеге фотога.

Әлеге агачлар 1942 елның язында утыртылган.

Экскурсовод кулында авиация заводы директоры Виталий Копылов исеме белән аталган Ту-160 стратегик бомбардировщигы фотосы. «Крылья Советов» паркы янындагы урам да аның хөрмәтенә аталган.

«БУЫННАР» ПРОЕКТЫ

КАЗАННАН КОСМОСКА КАДӘР

1940 нчы еллар. Илебездәге гамәли космонавтикага нигез салучы Сергей Королёв та, башка галимнәр белән бергә, Казан «шарашкасында» эшли. Нинди хисләр кичерә, нәрсә турында хыяллана икән ул? Дистәләрчә елдан соң Королёв йөргән эзләрдән үтеп, шуны аңларга тырышып карыйк әле.



Лядов урамы, 5нче йорт, 100нче фатир – бирεдә Королёв яшәгән!

Бүген Лядов урамы, 5нче йортта ниндидер атаклы шәхесләр яшәвен хәтерләткән бернәрсә дә юк диярлек – кайчандыр активистлар кадаклап куйган «Бирεдә Королёв яшәде» пластик табличкасы гына боегып тора.

«БИРЕДӘ КОРОЛЁВ ЯШӘДЕ»

Автор:
Ольга Туманская

Зур, бик якты бүлмә. Кояш нурларына чумган! Җиһазлардан – карават, ашъяулык урынына җәймә ябылган аш өстәле, язу өстәле, бер-ике утыргыч, тумбочка. Кирәк-ярактан – өч пыяла банка, ике шешә, кружка һәм чәй кашыгы. Менә, бөтен байлык шул! Көлкеме? «Минем үземә дә көлке шул. Тик мин бер дә кайгырмыйм... Бу бит тормышта мөһим түгел, һәм гомумән, болар барысы да вак-төяк кенә», – дип язган Королёв туганнарына үзенең – ниһаять! – ирекле тормышы хакында.

Әйе, ул Казанда ирекккә тиенгән – 1944 елның 27 июлендә «шарашкадагы» башка галимнәр белән бергә аны да вакытыннан алданрак азат иткәннәр. Хәер, бу ирек шартлы булган: паспорт урынына – азат ителү турындагы белешмә, тик ул күп хокуклардан мәхрүм итә – кеше сайлауда катнаша, демонстрациягә чыга алмый, атна саен «Черек күлдә» теркәлү мәҗбүри... Әмма Королёв барыбер шат. «Мин элегрәк (сугышка кадәр) тормышның гүзәл мизгелләренең кадерен белмәгәнмен икән, хәзер исә кояш нурының да, бер йотым саф һаваның да, каткан икмәк кыерчыгының да никадәр кадерле икәнен аңладым», – дип язган ул алдарак искә алынган хатында.

Ул гомере буена шундый талымсыз булып калачак. Беркайчан да тормыш авырлыгыннан зарланмаячак. Бернәрсә дә тупламаячак, әйберләрен кадерләмәячәк. Әмма Колымадан алып кайткан алюминий кружкасын гомере буе саклый. Казаннан нәрсә алып кайтты икән соң ул? Үзе өчен һәм бөтен бу дөнья өчен бәһасез нәрсәләрне – континентара баллистик ракета төзү буенча тәүге сызым һәм исәпләүләрен, диләр.

Лядов урамы, 5нче йорт, 100нче фатир – Королёвның Казан адресы менә шундый. Алтынчы подъездга керү ишеге бүген магнитлы йозакта. Әмма без шулай да түр ишектән кереп йөрүен күз алдына китерик: шул ук баскыч басмалары, шул ук култыксалар... Бишенче кат, мәйданчыкта дүрт фатир – безгә сулга. Йөзенче номерлы ике бүлмәле фатирга аяк басабыз – менә ул тәрәзәләр! Һаман шулай ук кояш нурларына чумып утыралар. Тәрәзәдән күренеп торган балалар бакчалары да, каршыдагы арка да шул ук, чын, барысы да сакланган, тәрәзә төбендәге биек каенны гына кисканнәр...

Королёв бу фатирның бер бүлмәсендә яшәгән. Икенчесендә кем соң? Мәгълүматлар төрле. Үзенең гаиләсенә ул «тагын бер иптәшем белән яшим», дип яза. Соңрак аның кызы Наталья үзенең китабында инженер Шнякин исемен атаячак. Әмма йортта яшәүчеләр конструкторның күршесе НКВД хезмәткәре булуын хәтерли, дөрес, ул конвой булудан бигрәк сакчы ролен үти. Күрше фатирда Глушко яшәгән. Бөтен подъезд «шарашканың» элекке тоткыннарына бирелгән булган! Хәер, бүген бирεдә ниндидер атаклы шәхесләр яшәвен хәтерләткән бернәрсә дә юк диярлек – кайчандыр активистлар кадаклап куйган «Бирεдә Королёв яшәде» пластик табличкасы гына боегып тора. 100 нче фатир да хәзер буш, дип сөйлиләр. Бәлки, аны кем-

Фото: Александр Ефремов

дер инде, киләчәктә бәһасезгә әйләнәсен аңлап, күптән сатып алгандыр?



Һәр иртәне КМҖБнең 4 мең эшчесен Сергей Королёв горельефы каршы ала. Ул беренче совет реактив ракета двигателенең нәкъ менә бирелә җыелуын һәм шул рәвешле безнең илебезнең ерак космоска таугә адым ясавын искә төшереп тора.

ЙОЛДЫЗЛАР ИРЕКТӘН КАДЕРЛЕРӘК

Безнең көннәр. Моторлар җитештерү заводы ишегалды. Капка төбендә үк – КМҖБ эшчеләре куйган Королёв горельефы. Совет гамәли космонавтикасына нигез салучы галим сугыш елларында бирелә эшләгән. Ул монда килергә бик омтылган, хәтта үзенең төрмәдә утыру вакытын аңлы рәвештә озынайткан!

Колыма алтын приискларындагы каторгадан соң Королёв Туполев «шарагасында» – Омскида НКВДның ябык конструкторлык бюросында хезмәт куя. Башка тоткын конструкторлар белән бергә Ту-2 бомбардировщигын чыгаруны җайга сала һәм үзенең вакытыннан алдан азат ителүен көтә. Кинәт ул икенче бер «шарашка» җитәкчесе Валентин Глушконың аны Казанга күчерү артыннан йөрүен белеп ала. Анда реактив ракета двигателен төзү буенча эш алып барыла! Королёв гомере буе шуның турында хыялланмаганмыни? Ирекккә чыгу өмете кабынуга карамастан, ул үзе дә Глушко «шарашкасына» күчерүләрен юллый башлый. Королёв Казанга килгәндә, яшерен РД-1 инде әзер диярлек була. Королёвның бурычы – аны самолетка яраклаштыру һәм сынаулар үткәрү. Бер ай эчендә генә дә аның җитәкчелегендә 900 сызым сызыла! Һәм алар барысы да кирәкле булып чыга...

Менә ул – тимерчыбык сеңерле «хәшәрәт». КМҖБ музеендагы легендар РД-1 установкасы.

КМҖБ музеенда мин әлеге легендар установканы күрдем: тимерчыбык сеңерле хәшәрәт ул. Артында – аны дөньяга тудыручыларның фотосурәтләре. СССР НКВДсының төрмә тибындагы махсус конструкторлык бюросы тоткыннары. Кайсы исемне генә атасаң да, йолдызлы шәхес – Глушко, Королёв, Жирицкий, Севрук, Лист, Чаромский, Стечкин... Музей директоры Гүзәл Габдуллина алар турында сәгатьләр буе сөйли ала.

Сүз уңаеннан, РД-1 двигателе ПЕ-2 очкычында гына түгел, Лавочкин, Сухой, Яковлевның винтлы самолетларында да сыналган. «Мин капчыктагы мәчене алам дип уйлаган идем, ә капчыкта юлбарыс булып чыкты», – дигән аның турында Лавочкин.

Ул заман кешеләре галим-конструкторлар өчен НКВД махсус төрмәсенең яки «шарашканың» Казан авиация заводы идарәсе бинасында урнашуын хәтерли әле. Дүртенче катта – конструкторлык бюросы. Өченчесендә – төрмә тулай торагы.

Фото Казан авиация заводыннан алынды

«БУ ТОТКЫННАР ЯШИ...»

Казан авиация заводы. Завод идарәсе бинасы. Әйдәгез, мәрмәр баскычтан дүртенче катка менүебезне һәм сулга борылуыбызны күз алдына китерик. Шаһитләр әйтүенчә, сугыш елларында «шарашка» нәкъ менә шунда урнашкан була.

Яңа тоткын Королёв биергә 1942 елның 19 ноябрендә килә. «Киң җилкәле, уртача буйлы кеше, зур түгәрәк башы кыска муенга утыртылганга, гәүдәсе бераз бөкрәрәк тоела. Зур кара күзләреннән акыл сирпелә», – үзенең язмаларында ракетачы инженер Эдельман Королёвны шулай сурәтли. Бу вакытта инде Королёв каторга кичерешләреннән бераз айныган, Туполев «шарагасында» тамагын туйдырган, ә иң мөһиме – үзенең яраткан эшенә әйләнеп кайткан һәм шунлыктан «мөлаем, аралашучан һәм хатын-кызларга ихтирамлы» кеше кебек тоелган. Коллегалары аның ягымлы энергиясен,

кешеләрне бурычны хәл итүгә юнәлтә белүен, оештыру осталыгын, ярдәмчел һәм игътибарлы булуын искә төшерә. «Соңрак аңарда пәйда булачак хакимлек итәргә яратучанлык сыйфатлары Казанда бер дә сизелмәде».

Тоткыннар бер кат астарак яши. Королёв бүлмәсендә тагын 23 кеше була. Үзләренә генә йөрергә ярамый, аларны һәр җирдә НКВДның кораллы хезмәткәрләре озата йөри. Бу «шәм» хезмәткәрләр саны тоткыннарныкыннан азрак була, шунлыктан кайвакыт, кирәкле җиргә барыр өчен, сакчының бушавын көтәргә туры килә.

Әмма, махсус төрмәнең эчке тәртибенә карамастан, Глушко тәҗрибә-конструкторлык бюросында мөмкинлекләр дә күп була. Двигательләр конструкторы Алексей Исаев 1942 елда мондагы шартларны күрә һәм икенче бер галим-конструктор Борис Чертокка: «Бу тоткыннар бездән яхшырак яши. Без хыяллана да алмаган стендлары, лабораторияләре, җитештерүләре бар. Аларны саклыйлар, шунлыктан ихластан сөйләшеп булмаячак. Әмма безгә, иректәгеләргә, караганда ашатуын да яхшырак ашаталар. Иң мөһиме – аларның двигательләре күпкә ышанычлырак эшли», – дип сөйли.

Тоткынлыкта интексәләр дә, Казан «шарашкасындагылар» , хыялда гына булса да, үзләре күнеккән тормышта яшәргә тырыша. 1943 елда Королёв һәм Севрукны командирлар ашханәсендә туклануга күчерәләр, анда исә тәүлегенә 800 грамм икмәк бирелә! Аны Севрук каһвә бөртекләренә алмаштыра, кичләрен исә үз «ресторанына» якын дусларын җыя. «Әйдә, «Риога» барабызмы?» – дип сөйләшәләр торган булалар. Каһвәне отбойга кадәр эчеп утыралар кайвакыт. Тәнәфесләрдә шаян спорт ярышлары оештыралар – кем кемне карават астына төртеп кертә? Аннары китап укыйлар. Китапларны да, каһвәне дә ялланып эшләүчеләр аша табалар, алар тоткыннарга, бөтен кагыйдәләрне бозып, булыша. «Шарашкага» «халык дошманнары» түгел, фидакарь галимнәр ябылуын гади кешеләр яхшы аңлый. Исаев әйтүенчә, Казан «шарашкасында» яшәүчеләр белән ике көн аралашкан арада ул сыеклыклы реактив двигательләр турында күбрәк әйбер белә – һәрхәлдә, Ракета фәнни-тикшеренү институты белән озак вакыт бер хезмәттәшлек итү чорыннан күпкә күбрәк мәгълүмат туплый.

Фото Казан авиация заводыннан алынды



Цех капкасы ачылыр да, урамга легендар Пе-2 бомбардировщигы тәгәрәп чыгар кебек! Сугыш вакытында нәкъ менә бираедә, Казан авиация заводында, яңа РД-1 тизләткеч установкасы сыналган. Сынауда Королёв катнашкан.

«ПЕШКА» ФЕРЗЬГӘ ӘЙЛӘНӘ

Казан авиация заводының җыю цехы каршында басып торганда, әлеге зур капканың ничек ачылуын һәм урамга... самолет төртеп чыгаруларын күз алдына китерү бер дә кыен түгел. Менә ул Пе-2 бомбардировщигы! Самолет артыннан исә цехтан эшчеләр йөгереп чыга – барысының да үз «Пешкаларының» ферзьгә әйләнүен күрәсе килә.

Серияләп җитештерелә торган машинаның койрыгына РД-1 реактив двигательле яңа тизләткеч установка куелган. Шуның нәтиҗәсендә самолет тизрәк һәм биектәрәк оча, моның өчен махсус төймәгә генә басарга кирәк! Пилот кабинасында яшь сынаучы – Александр Васильченко. Бу егет – булачак Советлар Союзы Герое. Аның янәшәсендә сынаучы инженер, тоткын Сергеев. Завод эшчеләре әлеге фамилия артына кем яшерелүен 1966 елдан соң гына беләчәк – «Сергеевны» телевизордан күргәч! Әлбәттә, язмада гына – ул чакта Королёв үзе инде вафат...

Эксперименталь очышлар сериясе 1943 елның 1 октябрендә башлана. Бервакыт 7 мең метр биеклектә самолетның двигателе шартлый. Койрык ягына ут каба, һәм ялкын тиз арада кабинага якынлаша. «Сикер!» – дип кычкыра пилот инженерга, биеклекне киметә төшеп, әмма ул баш тарта – аварияләнең сәбәбен ачыкларга кирәк була. Васильченко яна торган машинаны җиргә утырта ала. Үзе бик каты пешә. Королёвның муены, кулы, йөзе һәм күзе пешә – конструктор сукырая. Берничә көн буе тоташ караңгылыкта яши, әмма, бәхеткә, күзләре ачыла. Реактив двигатель һәм ракета тизләткече төзү эшләрен шәхсән контрольдә тоткан Лаврентий Берия нәкъ менә шул очрактан соң Королёвны очудан тыйган, диләр.

КОНСТРУКТОРГА КАНАТ БИРЕГЕЗ!

Каторгадан һәм махсус төрмәдә яшәүдән соң ирекккә чыккан Королёв Лядов урамындагы фатирында ялгызлыгыннан ләззәтләнә. «Кайтам, кичке ашка тиз генә берәр нәрсә пешереп ашыйм да караватка ятам, бераздан йокыга да талам. Рәхәт!» – дип яза ул әнисенә. Әмма ул махсус конструкторлык бюросында эшләвен дәвам итә – көненә 15–18әр сәгать баш ватарга туры килә.

Эшкә Королёв 9 нчы трамвай белән бара алган – ул йорты каршысында ук туктаган. Әмма трамвай бик начар йөргән, сәгать саен диярлек ватылган. Шәһәргә чыгасы булса, Соцгородтан Казанга сәяхәт ике сәгатькә сузылган. Тик Королёв шәһәрдә сирәк булган, эшкә исә трамвайсыз, җәяү дә барып җитеп була – нибары 15 минут вакыт кирәк!

Кайсы юлдан барган икән ул? Әйдәгез, күз алдына китерик әле. Подъездан чыккач, каршыдагы йортның аркасы аша үтеп, «Крылья Советов» паркына керәсең. Үзәк аллеядән бераз баргач, сулга борыласың. Елның бөтен фасылында да матур, ышык, кошлар сайравына күмелгән парк илһамландыра. Бүген Королёвны мондагы агачлар гына «хәтерлидер» инде. Берьялгызы гына аллеяләр буйлап йөргән конструктор нәрсә турында уйлаган икән? Иптәшләре белән бергәләшеп өйгә кайтканда, нәрсә турында сөйләшкәннәр?

Кайчандыр, 1929 елда, ул Циолковскийның «Исследование мировых пространств реактивными приборами» китабын укыган һәм планер белән самолетларда гына түгел, атмосферадан узып та очып булуны аңлаган. Әлеге идея – кешелекне яңа биеклеккә алып чыгу – Королёвны озак еллар буе илһамландырган. Ә менә биредә, Казанда, ниһаять, ул бу идеяне тормышка ашырып булуга ышанган. ■

Редакция материалны әзерләүдә ярдәм иткәннәргә өчен «КМҖБ» АҖ музеена, Соцгород тарихын өйрәнүче Наталья Урейскаяга рәхмәтен җиткерә.



Өеннән эшенә кадәр Королёвка нибары 15 минут әкрен генә җәяү барасы булган!

Бүген бирелә Королёвны мөгаен агачлар гына «хәтерлидер». «Крылья Советов» паркы аллеяләре буйлап йөргәндә конструктор ниләр уйлады икән?

Фото: Александр Ефремов

Автор Николай Морозовның «Предчувствие космической эры» документаль фильмы материалларын, Анатолий Эдельманның «Записки инженера-ракетчика» хатирәләрен, Наталья Королёваның «Отец» китабын, Королёвның хатыны Нинага язган хатлары тупланган «Королёв. Горизонт событий. Нежные письма сурового человека» җыентыгын, Борис Чертокның «Ракеты и люди» хатирәләрен файдаланды.

«БУЫННАР» ПРОЕКТЫ

БЕЗ БЕЛГӘН **ШҮРӘЛЕ**

1945 ел. Сугыш. Җиңүгә кадәр тагын ике ай калган. Ә Казанда – премьера! «Шүрәле» – беренче татар балеты…

Автор:
Ольга Туманская

ЧЫНГА АШМАГАН ХЫЯЛ

1939 ел. Урамда атлар пошкыруы, тояк тавышлары ишетелгәли, ул да түгел шалтырап трамвай уза, кешеләр сөйләшүе колакка керә. Кинәт кенә әлеге гадәти ыгы-зыгыны шомлы, гаҗәеп матур музыка боза. Үтеп баручыларның кайсыдыр борылып карый. Көйнең кайдан килүен эзли. Өстән! Зур кунакханә тәрәзәләре аша моң агыла. Кунакханә бүлмәләренең берсендә рояль артында бөдрә чәчле егет утыра – 25 яшьлек Фәрит Яруллин...

Әгәр үз вакытында Мәскәү консерваториясе профессоры, күренекле педагог Генрих Литинский Фәрит Яруллинны күреп өлгермәгән булса, гаҗәеп «Шүрәле» балеты туар идеме икән? Генрих Ильич аны болай дип искә төшерә: «Яруллин бик тирәнгә яшерелгән, кулланылмый яткан гаҗәеп бай фантазиягә ия искиткеч талантлы кеше. Әлеге сәләтне келәшчә белән тартып чыгарырга кирәк. Һәм, әгәр бу тормышка ашса, гаҗәеп матурлык туачак иде».

Сүз уңаеннан, «Шүрәле» балетын язу идеясе үзе Литинскийга бәйле. Тукай әкияте белән танышканнан соң, ул әлеге әсәр белән шулкадәр илһамлана ки, яраткан укучысына, сынап карау нияте белән, аның беренче өзекләрен язарга бирем бирә. Нәтиҗә укытучыны канәгатьләндерә, шуңа күрә ул яшь шагыйрь Әхмәт Фәйзигә либретто язу үтенече белән мөрәҗәгать итә. Эш кызып китә!

– Яруллин беренче картинаны тәмамлый, аннан икенчесен. Биюгә яраклашуы, тәэсир итү көче буенча көйне мактап бетереп булмый, – дип яза Генрих Литинский Казанга, балетмейстер Гай Таһировка язган хатында, һәм шунда ук аны автордаш-хореограф булырга чакыра.

Литинский, әлбәттә, Гай Хаҗиевичның инде «Шүрәле» балетына язган сценарие барлыгы турында белми. Дөрес, сценарий бер генә актлы була, дип раслый балетмейстерның биографы Владимир Горшков: алай гына да түгел, Таһиров версиясен театр җитәкчелеге булачак постановканың нигезе итеп кабул иткән була. Әмма, бераз уйлаганнан соң, Таһиров шундый фикергә килә: кемнең «Шүрәле»се кызыклырак булуы турында Литинский белән бәхәсләшмәвең хәерлерәк. Һәм ул Литинскийның тәкъдимен кабул итә.

Балет буенча эшләргә талантлы Ленинград балетмейстеры Леонид Якобсонны да чакыралар. Эш шунда: «Шүрәле»не 1941 елда Мәскәүдә үтәргә тиешле Татар сәнгате декадасы программасына кертү турында карарны махсус комиссия кабул итә. Үтә дә җаваплы эш! Якобсон беренче һәм өченче актларны куярга тиеш була. Фәйзи либреттосы белән танышканнан соң, ул аны йомшаграк дип таба һәм сценарийны шактый үзгәртеп язарга уйлый. Бу хәл Яруллинны көйне дә үзгәртергә мәҗбүр итә. Гаҗәеп көч, киеренкелек сорала! Өстәвенә, бик кыска вакыт эчендә.

…Һәм менә ул Университет белән Бауман урамнары чатында урнашкан «Совет» кунакханәсендә – номерга рояле белән бергә бикләп куелган. Бернинди чикләүләрсез иҗат итү шарты белән. Ул иҗат итә дә, ә инде киеренкелек тәмам чиктән ашканда, ялгызлыгыннан яңгыр торбасы буйлап төшеп кача. Хәер, кунакханәдәге «тоткыннар»дан ул берүзе генә булмый. Тулы бер катны татар мәдәнияте эшлеклеләре били – барысы да Декадага әзерләнә. Җиһанов «Алтынчәч» операсы буенча эшли, Мозаффаров «Галиябану»ны яза. Эшләргә куратор итеп әлеге дә баягы Литинский билгеләнгән була. Һәр иртәне Генрих Ильич номерлар буйлап йөри, тикшерә, төзәтә, мактый, орыша…

Әлбәттә, 25 биючедән торган труппага – Татар опера театрының балет составы ул вакытта әнә шуның кадәр кешедән тора – мондый көчле куелыш буенча эшләве бик авыр була. Татария җитәкчелеге башкаладан «Остров танца» дип аталган күренекле хореография театры коллективын, һәм шулай ук Мәскәү һәм Ленинград балетларында иҗат иткән танылган осталарны чакыра. Нәтиҗәдә Казан театры труппасы 90 кешегә кадәр арта. Эш гөрли! Якобсон үзенең актларын Мехчылар клубында кабатлый һәм репетицияләргә Таһировны кертми. Моны ул гаять зур дулкынлануы белән аңлата.

«Шүрәле» премьерасының вакытын сугыш башлануы боза – тиз арада җиңүгә ирешергә насыйп булмый. Театрның штатын яңадан кыскарталар, балет труппасында бары тик җиде генә кеше кала. Таһиров урман кисү эшләренә чакырыла, аннан соң – Казан тирәли ныгытмалар төзелешенә. Яруллин фронтка китә. Литинский яраткан укучысын сугышка җибәрмәс өчен бик зур көч куя. Ул Яруллинны тылга кайтарту максатында нинди генә инстанцияләргә мөрәҗәгать итми, чөнки аның укучысы – «күренекле композитор һәм татар милли мәдәнияте өчен гаять зур байлык булып тора». Ләкин Литинскийның омтылышлары, тырышлыклары максатына ирешә алмый – Фәрит Яруллин сугышның иң хәтәр урыннарында – әле Курск дугасында, әле Белоруссия өчен барган бәрелешләрдә катнаша. «Минем «Шүрәле»не шулкадәр сәхнәдә күрәсем килде. Бер генә күзем белән булса да... Аның музыкасы миндә яши, ул һәрвакыт минем белән бергә», – дип яза композитор «Шүрәле» турында үзенең хатыны, балет артисткасы Галина Сачекка. Ләкин юк, әлеге хыялларга тормышка ашарга насыйп булмый…

БИИБЕЗМЕ... АВЫЛЧА?!

– Аякларың бармы?
– Бар.
– Ыштан киеп йөри аласыңмы?
– Алам.
– Димәк – артист!

Тарих битләренә теркәлгән контексттан аерып алынган әлеге сөйләшү елмаю уятырга мөмкин, моның сугыш вакытында Казанда ачылган күпләгән госпитальләрнең берсендә барган сөйләшү икәнлеген аңламаганда, әлбәттә. Гай Таһиров яраланган солдатлар арасында биюче барлыгын ишетә һәм тизрәк йөгерә – кадрлар мәсьәләсен хәл итәргә! Сугыш вакытында ир-атлар арасында биючеләргә кытлык бик зур була. Кайчак ирләр партияләрен хатынкызлар башкарырга мәҗбүр. Тамашачылар искә төшерә: кайвакыт артисткалар, зал алкышлый башлагач, үзләренең мәһабәт ирләр образларын башкаруларын онытып, реверанс ясыйлар. Яшь аралаш көлүләр әнә шунда була да инде.

Фотолар Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрының музей архивыннан алынды

Личный листок

по учету кадров

1. Фамилия ЯРУЛЛИН

Имя Фарид отчество Загидуллович

2. Пол муж. 3. Год, число и м-ц рождения 1 января 1914г

4. Место рождения г.Казань
(село, деревня, город, район, область)

5. Национальность татарин 6. Соц. происхождение служащий-музыкант

7. Партийность б/п партстаж (месяц и год вступления) партбилет к/карточка №

8. Состоите ли членом ВЛКСМ, с какого времени и № билета

9. Образование высшее

Название учебного заведения и его местонахождение	Факультет или отделение	Год поступления	Год окончания или ухода	Если не окончил, то с какого курса ушел	Какую специальность получил в результате окончания учебного заведения, указать № диплома или удостоверения
Казанское музыкальное училище	класс виолончели	1930	1933		
Рабфак при Мос.консерват.	кл.композ.	1933	1934		
Тат.оперная студия Москов. консерватории	класс композиции	1934	1938		композитор

10. Какими иностранными языками и языками народов СССР владеете
русский,татарский
(читаете и переводите со словарем, читаете и можете объясняться, владеете свободно)

11. Учёная степень, учёное звание

12. Какие имеете научные труды и изобретения
Балет "Шуралэ" в 3-х действиях. Песни о комсомоле, о Родине, Романсы /21 название/, обработка татарских, башкирских песен/12 назв./ Инструментальные произведения /12 назв./Симфония № 1/2части/

13. Выполняемая работа с начала трудовой деятельности (включая учебу в высших и средних специальных учебных заведениях, военную службу, участие в партизанских отрядах и работу по совместительству).

При заполнении данного пункта учреждения, организации и предприятия необходимо именовать так, как они назывались в свое время, военную службу записывать с указанием должности.

Месяц и год: вступления	Месяц и год: ухода	Должность с указанием учреждения, организации, предприятия, а также министерства (ведомства)	Местонахождение учреждения, организации, предприятия
1931	1932	Пианист и виолончелист Казанского театра рабочей молодежи - ТРАМ	Казань, ул.Плетнева клуб им.Вахитова
1932	1933	Пианист-концертмейстер Татарского радио-центра /совмещал с учебой/	Казань ул.К.Маркса д.36
1934	1938	Учеба в оперной студии при Мос. Консерватории	Москва ул.Герцена д.9
1939	1941	Тат.гос.театр оперы и балета композитор	Казань ул.Баумана 48 Большой театр
1941 июль	1941 [illegible]	Ульяновское пехотное училище курсант	
1942	сентб.	Действующая армия лейтенант командир стрелкового взвода 19 танкового корпуса	

Леонид Жуков – балет артисты, балетмейстер. 1944–1947 елларда Казанда эшли.



Әхмәт Фәйзи – либретто авторы.



Гай Таһиров – 1938–1952 елларда Татар опера театрының баш балетмейстеры.

Заманы никадәр генә авыр булса да, Таһиров «Шүрәле» турында уйлый, онытмый. Вакытын бушка уздырмый: балет студиясе студентлары белән шөгыльләнә, тәҗрибәле артистларның осталыгын чарлый, фольклор экспедицияләренә йөри. Бервакыт шундый сәяхәттән гаять зур табыш белән кайта – 52 халык биюе! Барысын да эшкә җигә. Фольклор буенча әлеге тәҗрибә Гай Хаҗиевичка «Шүрәле»нең икенче актын сәхнәләштергәндә бик кирәк булып чыга – тамашачы каршында үзенең бөтен матурлыгы һәм үзенчәлеге белән татар авылы килеп баса. Безнең төбәк өчен шулкадәр кадерле, якын көйләр һәм образлар килчәктә балетка тагын да җетерәк төсләр өстәячәк.

«ШҮРӘЛЕ» ДӨНЬЯ БУЙЛАП АТЛЫЙ

...Бары тик 1944 елда гына, гаять зур тырышлыклар нәтиҗәсендә, Татар опера һәм балет театры кабат «Шүрәле»гә алына. Биючеләрнең күпләренә әле бу вакытта 16 яшь тә тулмаган, оркестрга уен кораллары гына түгел, музыкантлар да җитми. Халык күп булырга тиешле күренешләрдә балет артистлары белән бергә вокаль группаныкылар да уйный. Бу юлы беренче һәм икенче күренешләрне сәхнәләштерергә элек Зур театр солисты, ә 1944 елдан Казан ТЮЗының баш балетмейстеры булып эшләгән Леонид Жуков чакырыла. Икенче күренеш – Таһировныкы.

Сүз уңаеннан, үзе йөргән экспедицияләрдә Гай Хаҗиевич татар биюләрен генә тупламый, халык костюмнарын да җыя. Еш кына театрга Казан артында кия торган костюмнар эләгә. Таһиров балетка татарларга хас пластиканы өсти, биюләргә милли костюмны кертеп җибәрә – «Япмалы бию» дә, Сөембикә яучы костюмын караган музыкаль номер да әнә шул рәвешле барлыкка килә.

Балетның төп героинясы булган Сөембикә кош-кыз ролен Анна Гацулина башкара, югыйсә сугышка кадәр ул бары тик кечкенә кошчык ролен генә башкарырга тиеш була. Күп яктан Таһировның хуплавы, аның ярдәме нәтиҗәсендә балетка 29 яшендә килгән, гаҗәеп язмышка ия биюче – татар балетының беренче йолдызы әнә шулай кабына! Кошчык образы репетицияләрендә ул вакытта планлаштырылган Декаданың баш балетмейстеры Гацулинаның яше турында сорагач, исе китеп: «Сез элек кайда булдыгыз соң?» – дип сорый. Гацулина әле тагын егерме ел театр сәхнәсендә балкыячак, таң калган тамашачы, мөкиббән китеп, аның аягыннан ялгыш кына төшеп калган туфлиен сораячак, ә сәхнә арты хезмәткәрләре тактага ясалган спектакль күренешләрен бүләк итәчәк.

«Шүрәле»не куйганда кабынган тагын бер татар балеты йолдызы Бари Әхтәмов булачак. 1945 елның 8 мартындагы премьерада артист Али-Батыр ролен башкара, әмма балет сәнгате тарихына ул иң шәп Шүрәле булып кереп калачак – соңгы көннәренә кадәр Әхтәмов белән дус булган Леонид Якобсон аның турында нәкъ менә шулай язып калдырган. Сүз уңаеннан, балетның алга таба язмышы Якобсон белән бәйле була. Әлеге эше өчен Ленинград балетмейстеры Сталин премиясенә лаек дип табыла.

Казанда узган премьера зур уңыш казана. Һәм Якобсон аны Киров исемендәге Ленинград театрында (хәзерге – Мариинка) сәхнәләштерергә тәвәккәлли. Яңа партитураны Мәскәү композиторлары Владимир Власов һәм Владимир Фере башкара – һәм бу шулай тиеш була да, чөнки Ленинградта һәм Мәскәүдәге Зур театрда балетны өч составлы оркестрлар башкара! Фәрит Яруллинның гаҗәеп музыкасын бөтен дөнья нәкъ менә әлеге куелышта ишетәчәк.

«Шүрәле»нең уңышы искиткеч була. Сөембикә ролен – Майя Плисецкая, Былтыр партиясен Владимир Васильевның башкаруы гына да ни тора! Балет ил буйлап атлый, ул дистәләгән сәхнәдә куела, ә аннан соң, СССР чикләрен узып, Болгария, Монголия, Польша, Чехословакия, Румыния, Албания, Мексика театрлары афишаларын бизи....

– «Шүрәле» – сәхнәдән төшмәячәк әсәр ул, – ди Нәҗип Җиһанов премьера алдыннан балетның куелышын тикшерү комиссиясе утырышында. Бу 1945 елның 6 марты була. Бүген дә, күпме еллар үтүгә карамастан, «Шүрәле» безнең белән бергә Җиһүне бәйрәм итә.

Материалны әзерләгәндә А. Алмазованың «Фәрит Яруллин һәм аның «Шүрәле» балеты. Тормышының һәм иҗатының өйрәнелмәгән сәхифәләре». В. Горшковның «Гай Тагиров – балетмейстер», Д. Перегулованың «Казанский балет», Л. Донина, Г. Давлетьянова һәм Р. Такташның «Формирование сценических традиций национального балета как отражение идентичности татар», А. Кадыйрованың «Первая прима-балерина республики еще танцует!» дип аталган китаплары файдаланылды.

Редакция Татар дәүләт опера һәм балет театрының музей фондларын саклаучы Галия Акчуринага материалларны әзерләүгә күрсәткән ярдәме өчен рәхмәтен белдерә.

Сөембикә –
Кристина Андреева.

«БУЫННАР» ПРОЕКТЫ

«ҮЛЕМСЕЗ ПОЛКНЫҢ» ҮЛЕМСЕЗ ВАКЫЙГАЛАРЫ

Татарстаннан фронтка киткән 700 мең кешенең 350 меңе генә әйләнеп кайткан. Политрук Мөхлис Сәрвәр улы Хәеров – беренче исемлектә. Ул 1942 елның 26 августында Ржев янында һәлак булган. Сугышка киткәндә, бөтен гаиләсенә бәйрәм ясаган.

Радист Валентина Петровна Макова әле бүген дә исән – аңа 96 яшь һәм ул, шул буынның күпләре кебек, әлеге куркыныч дүрт елны бер дә исенә төшерергә яратмый. Әмма хәтерләргә туры килә, чөнки сугышны онытсак, кабат сугыш башланырга мөмкин. Шунлыктан, хөрмәтле укучыларыбыз, еллар үткән саен кадере арта гына барган әлеге үлемсез вакыйгаларны без сезнең ярдәм белән тупларга булдык.

ГАИЛӘ ПОРТРЕТЫ ТАРИХЫ

1942

Мөхлис Хәеров фронтка китәр алдыннан гаиләсе белән бергә фотога төшә.

Фотолар Гадел Хәеровның шәхси архивыннан алынды

Автор:
Гадел Хәеров

ИСТӘЛЕККӘ – ФОТО

Сугыш башланыр алдыннан гына минем бабам, Сәрвәр мулла улы Мөхлис, гаиләсе белән Казанга күченгән – Красин урамындагы иске сәүдәгәр йортының ун квадрат метры биш кешене сыендырган. Мөхлис фронтка китәр алдыннан, барысы бергә җыелып, фотога төшәргә булалар.

Әлбәттә, матур итеп киенәләр. Хәлимә сандыктагы бердәнбер купшы күлмәген эзләп ала. Мөхлис исә хром итекләрен кунычлары кояшта ялтырарлык итеп чистарта. Аларны шыгырдатып, бүлмә буйлап йөреп карый. «Шипр» хушбуен сибенә. Үтүкләнгән китель һәм галифесын киеп, билен каеш белән буып куйгач, барысы да тынып кала. Хәрби кием кигәч, Мөхлиснең хәтта тавышы да кискенәя. Барысын да, рәткә тезеп, якындагы фотосалонга алып китә ул.

Фотограф, фокусчы кебек, кара балдахин астына кереп чума да лаклы зур тартмадан «кош очыра». Аның рәсемне әзерләвен көткән арада яңгыр юып киткән

Ржев янында барган каты сугышлар.

Фотода: беренче рәттә уңнан сулга – Измаил Хөсәен улы Хөсәенов, Люция, Хәлимә апа, икенче рәттә сулдан уңга – Альберт һәм Рево.

җәйге шәһәр буйлап йөриләр, кафега кереп утыралар, стаканнар тирәсендә бөтерелгән шөпшәне куа-куа, дюшес белән хушланалар.

Әтиләре сугышка китә бит! Бу фотога төшү һәм алюминий вазалардан туңдырма ашау балалар өчен үзенә бер бәйрәмгә әйләнә. Яңа хәрби кием кигән гаилә башлыгыннан баштарак бераз ятсынсалар да, узып баручыларның аңа сокланып каравын күргәч, тиз арада бөтен фашистны дөмектерәчәк көчле һәм зур әткәйләренең кочагына сеңәләр – бер дә үзләреннән еракка җибәрәселәре килми шул...

Иртән Мөхлис йоклап ятучы сабыйларын үбә, күзе белән аларны, хәтерендә саклар өчен, тагын «фотога төшерә» дә, ачкычларын һәм булган бар акчасын тумбочкада калдырып, чыгып китә...

Бер елдан ул кабат пәйда була. Ябыккан, чәче кыркылган, үзенә дару исе сеңгән. Госпитальдән фронтка китеп барышы. Саубуллашырга дип керә.

УЛ РЖЕВ ЯНЫНДА ҺӘЛАК БУЛДЫ...

Татарстаннан фронтка киткән 700 мең кешедән 350 меңе генә әйләнеп кайткан. Политрук Мөхлис Сәрвәр улы Хәеров – беренче исемлектә. Ул 1942 елның 26 августында Ржев янында һәлак була. Күңелгә шунда ук Твардовский сүзләре килә:

Я убит подо Ржевом,
В безымянном болоте,
В пятой роте, на левом,
При жестоком налёте.
Я не слышал разрыва,
Я не видел той вспышки,–
Точно в пропасть с обрыва –
И ни дна ни покрышки.
И во всем этом мире,
До конца его дней,
Ни петлички, ни лычки
С гимнастерки моей.

Тверь өлкәсе Зубцов районы Яйково авылы янындагы туганнар каберлегендә җирләнгән ул. Анда һәйкәл куелган, артында кыр җәйрәп ята. «Бөек Ватан сугышы каһарманнарына. Рәхмәтле Ватан», – дип язылган.

БЕРЕНЧЕ СУВОРОВЧЫЛАРДАН БЕРСЕ

Фронтта геройларча һәлак булган Мөхлиснең улы Ревоны 1944 елда ачылган Казан Суворов училищесына чираттан тыш кабул итәләр. Әтием үзе моны болайрак искә ала:

– Училищега керергә теләүчеләр бик күп иде, чөнки анда керү урам йогынтысыннан саклап кала, тормышта үз юлыңны табу өчен зур мөмкинлекләр ача. Фронт кичкән, әмма сугыш кырында тупасланмаган укытучылар күп кенә суворовчыларга яуда һәлак булган әтиләрен алыштырды.

Ялтыравыклы төймәле, «КазСУ» дип язылган кызыл погонлы кара форма үзе үк кичәге ваемсыз үсмерләрне үзгәртте, безнең өчен инде бөтенләй башка тормыш башланды. Иртәнге алтыда йокыдан тору, зарядка, иртәнге аш, дәресләр, хәрби әзерлек...

Безне хәтта атта йөрергә дә өйрәттеләр. Моның өчен Германиядән нәселле атлар кайтарттылар. Аларның савырына свастика тамгасы төшерелгән. Матурлар, тик усаллар. Минеке Овация кушаматлы иде, шикәр биргәч, иреннәре белән йомшак кына итеп ала да, аннары барыбер тешли.

Тиздән Америка машиналары пәйда булды: ике виллис, ике додж, суда йөзә торган ике студебеккер. Һәм безне автомобиль йөртергә өйрәтә башладылар. Бер дә эшсез утырмадык.

ЯТИМНӘР ТУРЫНДА КАЙГЫРТЫП...

-Училищеда тәрбияләнүчеләрне ашату патша Россиясендәге кадетлар корпусы үрнәгендә оештырылган иде. Бу – генералиссимусның вакытында кабул ителгән һәм алдан күрүчән карары, шул рәвешле ул сугышта һәлак булган кызылармиячеләрнең балаларын кайгырта һәм яңа хәрби кадрлар әзерли.

Безне югары разряд буенча ашаттылар. Училищега контейнерлар белән какао, йомырка порошогы, коры сөт, май, галетлар, боткалар, ит һәм балык консервлары, казылык, шоколад кайтартыла. Сосискалар, эре калибрлы пулемет патроннары кебек, махсус тубусларда. Суворов училищесы диварлары артында кешеләрнең ничек авыр яшәвен без, әлбәттә, белә идек. Миннән тыш та тагын ике баласы белән тол калган әниемә сугышта үтерелгән әтием өчен аена 38 сум пенсия бирелә. Базарда исә кара ипи 100 сум тора.

Безнең натураль ашамлыкларыбыз да бар иде. Паркның бер башында дуңгыз фермасы һәм терлек абзары төзеделәр, анда берничә сыер асрадылар. Яңа савылган сөтне ашханәгә чиләкләп ташыйлар иде. Эремчек ясыйлар. Шул чакта ашаган кәтлит һәм атланмайлы бәрәңге боламыгы тәмен әле хәзер дә хәтерлим.

Училищены тикшерергә дип Мәскәүдән килгән генерал Панин безнең зиннәтле савыт-сабадан ашавыбызны күреп гаҗәпләнде. Әйләндерә-әйләндерә карады да, аш савытының төбендә свастика билгесен һәм Reichskanzlei, ягъни «Рейхканцелярия» язуын күреп алды. Кызара-бүртенә, аш савытын идәнгә тотып бәрде. Аның фәрманы буенча бөтен савыт-сабаны ваттылар, китек-ватыкларны Горький паркындагы чокырга томырдылар...

Мин Суворов училищесына безгә биргән тәрбиясе белән белеме өчен бик рәхмәтлемен. Ашатулары һәм киендерүләре өчен дә. Хәрби булмасам да, язмышым башкача язылды – КАИда укыдым, аннары укытырга калдым, докторлык диссертациясен яздым...

1942



«БУЫННАР» ПРОЕКТЫ

ШОМЛЫ ДӘВЕРНЕҢ СОҢГЫ МОГИКАННАРЫ

Ул үзен гадәти язмышлы кеше дип саный. Валентина Петровна Маковага хәзер 96 яшь. Кечкенә генә буйлы, җыйнак-какча гәүдәле. Сабыр да, тынак та, балаларча кызыксынучан, тере, шаян да. Мин аны пулялар сызгырып очкан яу кырында, лагерь диварлары эчендә, тоткыннар арасында күз алдына китереп карыйм. Аннары сөйләшү барышында кинәт кенә янып киткән карашы белән очрашам да, ышана алмыйм. Ачык тәрәзәдән карап торган бөреләргә ишарәләп: «Яшәү нинди ямьле...» – дип кабатлый ул. Без инде күптәннән җуйган тәмле бер телдә сөйләшә. Керә-керешемә: «Рада знакомству с вами, барышня», – дип каршы алды...

ЗОЯ КОСМОДЕМЬЯНСКАЯГА ИЯРЕП...

– Мин үземне әллә ни гаҗәеп язмышлы кеше дип исәпләмим, гадәти язмыш иде ул безнең заман өчен, – дип башлады сүзен Валентина Петровна. – Минә исән калуым – анысы могҗиза...

Безнең чыгарылыш кичәсе 17 июньдә булды. Ә 22 сендә сугыш башланды. Сугышка кадәр мин Свердловск университетының филология факультетына гариза биргән, укырга китәргә тиеш идем, әмма гаиләбезнең карары катгый булды: өйдә каласың.

Апасы Нина Макова урман хуҗалыгында эшли башлый, Валентина 1942 елның мартында район прокуратурасына секретарь булып урнаша. Зоя Космодемьянскаяны ерткычларча җәзалап үтерүләре турындагы дәһшәтле хәбәр тетрәндерә. Комсомол яшьләрне: «Сез фронтка кирәк!» – дип агитацияли башлый. Сугыш кырларындагы батырлыкларга рухланып, бер төркем яшь кызлар да яуга китәргә карар кыла. Алар арасында Валентина да була.

СНАРЯДЛАР ЯНӘШӘДӘ ШАРТЛАГАНДА...

Валентина беренче чакыруга эләкми. Чираттагы чакыруда аны мәктәптә бергә укыган дус кызлары – Маргарита Васильева һәм Галина Ласкина белән бергә дәшеп алалар. Әнисе район военкоматына кызын авылда калдыруларын үтенеп бара, әмма гаризасы булгач, һичшиксез, озатырга тиешбез, дип, кире борып кайтаралар.

– 1942 елның 3 маенда без, иңнәребезгә биштәр асып, пароходка утырып Уфага киттек. Анда безне башта беренче чакыру буенча җибәрелгән кызлар белән бергә тоттылар, карантин тикшеренүе узганнан соң, кабат пароходка төяп, Горький шәһәренә радистлар курсына озаттылар.

1942 елның май азагында Горький шәһәренең (хәзерге Түбән Новгород. – Ред.) Канавино районында радистлар курсында укый башлый Валентина Макова. Уку октябрь аена кадәр дәвам итә. Курсларда армия тәртибе хөкем сөрә иде, дип искә ала:

– Иртәнге алтыда торып басабыз, иртәнге ашны ашыйбыз да укырга керешәбез. Аннан, төшке ашны ашагач, тагын укыйбыз. Кичке аштан соң, 23 сәгатьтә, отбой бирәләр, егылып йоклыйсың. Үзебез өчен буш вакыт калмый да иде диярлек. Безне тиз арада фронтка җибәрер өчен әзерләделәр. Махсус предметтан тыш, стройга тезелергә дә өйрәттеләр, кичләрен рота белән йөрергә дә чыгаралар иде.

Кызларның бөтен вакыты диярлек радиоэшкә өйрәнүгә багышланган була. Ягъни, Морзе әлифбасына нигезләнеп, ачкыч белән эшләүгә.

1942 елның 18 октябрендә укулар тәмамлана. Курсларны уңышлы узган кызларны Мәскәүгә Кызыл Армиянең Төп элемтә идарәсенә озаталар. Сокольникидагы казармаларда бер ай торканнан соң, фронтларга билгелиләр. Валентина Макова Көньяк-Көнбатыш фронтка җибәрелә.

Алар билгеләнгәндә, 278 нче Укчы дивизия Сталинградны азат итү сугышларында катнаша. 1942 елның 11 декабрендә бирегә җибәрелгән кызлар полкның элемтә ротасына килеп җитә. Декабрьдә Сталинградның үзендә дә, тирәсендә дә иң авыр сугышлар бара.

– Мине икенче номер (икенче номер итеп гадәттә ир-атларны билгеләгәннәр, чөнки алар рация өчен кирәкле коточкыч авыр аккумуляторларны күтәреп йөргәннәр. – Ред.) белән бергә укчы батальонга җибәрделәр – рация буенча элемтә урнаштырырга кирәк иде. Әмма озак та үтмәде, дошман кайда икәнлегебезне ачыклады. Андый шартларда эшне дәвам итеп булмый иде. Дошман артиллериясенең элемтәне «тотып» алуын абайламый кала алмыйсың: снарядлар янәшәңдә үк шартлый башлый...

Безне, радистларны, полк командирының команда һәм күзәтү пунктына телефончылар итеп күчерделәр. Берәмләп дежур тордык, мөмкинлек булганда, икенчебез бераз черем итеп ала иде. Декабрь азагында өстебезгә танклар килә башлады, бу минем ут аша узган тәүге зур чыныгуым булды. Ротада авыр җәрәхәт алучылар күбәйде, үлем очраклары да үзен көттермәде.

1943 елның гыйнвар башында аларның полкын Сталинградтан төньяккарак җибәрәләр. Дошман өстенә бару инде Харьков юнәлешендә дәвам итә.

Фотолар Валентина Макова, Аркадий һәм Михаил Хлебниковлар архивыннан.



Өч бертуган Макова: Нина, Валя, Оля. 1934 ел.

«ҖИР БЕЛӘН КҮК ӘЙЛӘНЕП КАПЛАНДЫ...»

– Сугышка кергәнче үк безне яхшылап кисәттеләр: командирлар белән дә, рядовойлар белән дә үзеңне тәртипле тот, монда – яу кыры, танцы-фәлән түгел, – дип сөйли Валентина Макова. – Өс-башны да чиста-пөхтә тотарга кирәк иде, чәчне-башны туздырып йөрмәскә. Хәрбиләрнең берсе белән дә, бигрәк тә командирлар белән (алар бәйләнгән, игътибар күрсәткән очракларда) якын мөнәсәбәтләргә кермәскә.

– Ә бәйләнә иделәрме? – дип төпченәм.

– Ул күбрәк үзеңне ничек тотуыңа бәйле булгандыр, – ди Валентина Петровна тыйнак кына. – Кызлар арасында төрлесе булды, билгеле. Чытлыграклар да бар иде... Әмма кисәтү кырыс. Мин үзем ул кисәтүне шунда ук хәтеремә киртләп куйдым.

1943 елның 8 мартында Валентина Макованы укчы батальонга билгеләләр, ул анда радиоэлемтә өчен җавап бирә. Ике атнага сузылган сугышлар вакытында хәтерендә нәрсә калганын болай сөйли:

– Япан кыр, пулялар, шөпшәләр кебек, яннан сызгырып оча. Юынырга да, өс-башыңны карарга да мөмкинлек юк диярлек. Хәтта ашавын да төннәрен генә ашыйбыз. Элемтә булдырудан тыш, яралыларга беренче медицина ярдәме күрсәтү белән дә шөгыльләндек. Дошман тоташтан утка тота, хәл алырга бирми...

Ә 1943 елның 22 июль иртәсе аның өчен көтелмәгән хәтәр алып килә.

– Миңа 20 яшь, инде шактый тәҗрибәле сугышчы исәпләнәм. Ул иртәдә тиз генә капкалап алдык та, мин, тын торган арада, янәшәдә агып яткан сулыкка кашык юарга төштем. Шулчак, көтмәгәндә-абайламаганда, һавада әллә каян гына мессершмит пәйда булды. Дошман самолеты, каршылыкка очрамагач, түбәннән кистереп очкан хәлдә, миңа таба пулеметтан бер-бер артлы пуля яудырырга кереште...

Эчемә нәрсәдер китереп бәргәнен тойдым да, аякларым буйлап җып-җылы нидер агуын абайладым. Җир белән күк әйләнеп капланды. Ә асылда ул мин әйләнеп капланганмын икән... Күзәтү пунктында моны күреп алганнар. Үзем нәрсә булганын аңлар хәлдә түгел идем: эчемне актарып ташлаган да, эчәкләрем җиргә салынып төшкән. Рота старшинасы Григорий Калашник мине кичекмәстән эвакуацияләүләрен оештырган. Грабаркага төяп, медсанбатка озатканнар...

Валентина Макованың беренче сугышчан олы бүләге була ул. Әлеге медаль аны соңарып, Бөек Җиңүгә 20 еллыкны бәйрәм иткәндә, 1965 елда гына «эзләп таба». Бу инде 1946 ел үрнәгендәге медаль була...

«ӘНИЕМ БЕЛӘН ӘТИЕМНЕ КҮРӘ АЛСАМ ЯРАР ИДЕ...»

Медсанбат полктан 9 километр ераклыкта урнашкан була. Күпне күргән табиблар да эчәкләре әйләнеп чыккан кызның исән калырына ышанмый.

– Операция өстәлендә хирургның командасын ишетеп аңыма килдем, – дип сөйли Валентина Петровна. – Баштарак аңлый алмый тордым: кайда мин? «Берике-өч... сана!» – дип боерды табиб. 21 гә кадәр санадым да кабат аңымны җуйдым.

Аңына өч көн узгач кына килә. Аны кыр госпиталенә озаталар. Терапевт болай ди: «Ходайга рәхмәтләреңне укы, кызым, мондый җәрәхәт алган кешеләр, гадәттә, исән калмый».

Яралыларны Уфада оешкан эвакогоспиталь кабул итә. Валентина Петровна әйтүенчә, андый госпитальләрдә медперсонал күпкә яхшырак – квалификациясе ягыннан тәҗрибәлерәк, җитдирәк булган. Валентина Макованы хирург бик җентекләп карый.

– Ә мин бары бер генә җөмлә сытып чыгара алдым, – ди Валентина Петровна. – Исән калып, әнием белән әтиемне күрә алсам ярар иде...

Яралары һәм операция җөе госпитальгә китергәндә тоташ үлек кенә була. Ике атнадан соң аны санитар самолетта Воронеж өлкәсендәге Россошь шәһәренә җибәрәләр.

Валентина Петровна тагын бер эпизодны искә ала:

– Шундый авыр шартларда да кешеләр искиткеч кешелекле иде, – ди ул. – Алай гына да түгел, әдәпле, итагатьле. Әйтерсең, тирәюньдә бомбалар шартламый, ә без исә – балга биергә килгән туташлар белән әфәнделәр... Эвакогоспитальдәге олы яшьтәге хирург миңа «минем барышням» дип мөрәҗәгать итә иде. «Тереләсең, әлбәттә, туган ягыңа кайтасың, менә күр дә тор!» – әнә шул сүзләрен һич оныта алмыйм...

«СИН МИҢА КАПРИЗЛАР КҮРСӘТЕП ТОР ТАГЫН!..»

Россошьтагы госпитальгә илткәндә санитарларның үзара сөйләшүләрен ишетә: профильле урынга туры килмәде, нәрсә булып бетәр инде моның белән, диләр.

Баштарак сүзнең нәрсә турында барганын абайламый. Хатын-кызлар бүлегенә элагә ул. Аннан кала, тагын 2–3 хатын була, аларның сыкрану-сызланулары һаман ко-

Автор: Луиза Янсуар

Дәвалау факультеты, 1 нче курс. 1945 ел.

лак төбендә тора, ди Валентина Петровна. Нинди яра белән ятулары турында сорый – берсенеке – аборт, икенчесенең – ялкынсыну...

Кечке ашка кара ипи белән борчак боткасы китерәләр.

– Миңа моны ашарга ярамый, – ди Валентина Петровна.

– Нәрсә тоттырсалар, шуны аша! Әнә, солдатлар үлек эчендә ята, син монда капризларыңны күрсәтеп тор тагын миңа! – дип җикеренә санитарка, аны кемнеңдер походтагы «хатыны» дип уйлап.

– Мин дә бит – үлек эчендә, минем бәйләвечләремне алыштырырга кирәк, – дип пышылдый Валентина.

Шуннан соң санитарка дежур табибны чакырта. Диетик ашау билгелиләр дә, поездга утыртып, тылга – Камышин шәһәренә озаталар. Монда ул ике атна тора. Әмма яралары җитдирәк дәвалау таләп иткәнгә, Саратовка җибәрәләр. Монда Валентина Макова өч ай ята.

«СИН СОҢ НИЧЕК БАЛА ТАБАРСЫҢ...»

Госпитальдә аңа медицина хезмәте начальнигы – баш табиб Раиса Петровна Панкова аналарча җылылык белән карый, аерым игътибар күрсәтә.

– Ул минем хәтеремә чын табиб символы булып кереп калды, – дип искә ала Валентина Петровна. – Озын буйлы, күз явын алып торган аксыл-сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле... Аның 14 яшьлек кызы бар иде, кызының миңа охшаган булуын телим, диде бервакыт Раиса Петровна. Ул мине бер караудан үз итте. Җәлләгәндер инде. Бөтенләй бала гына булганбыз лабаса без ул чакта!

– Бу кызга 16 яшьтән дә ары юктыр, – диде табиб беренче обход вакытында. – Хәер, 14 не дә биреп була...

– Миңа 20 яшь, – дип җавап кайтара Валентина.

Раиса Петровна кызны ярасын карый да, тел шартлата:

– Син соң ничек кияүгә чыгарсың да бала табарсың?!

– Ә мин кияүгә чыгарга җыенмыйм, – ди Валентина. – Минем тизрәк әтием белән әнием янына гына кайтасым килә!

КҮКЛӘРНЕҢ МОГҖИЗАСЫ

1943 елның 14 декабрендә Валентина Маковага коры паек, тиешле документларны хәстәрләп тоттыралар да, инвалид буларак, кайтарып җибәрәләр. 19 декабрьдә ул Камбарка станциясенә килеп җитә. Станциядә пассажирлар өчен кунарга ачык һавадагы бер лавка каралган була. Валентина транспорт табарга тырышып карый, әмма барып чыкмый. Кич җитә, чатнама суык. Камбаркадан аның авылына кадәр юл – трасса буйлап 19 километр, ә Чулман аша турыдан – 15 километр.

Шинельдән булгач, җәяү дә кайтып җитәрмен, дип тәвәккәлли кыз. Әмма яралары үзенекен итә – тиз арада хәлдән тая. Шул чакта – ни могҗиза! – җигелгән атлы берәү килеп туктый. Җитмәсә, чанасында урын да буш! Березовкага бара булып чыга. Толыпка төренеп утыргач, инде юлда барганда, Валентина Макова бу ир-атның апасы Нинаның ире булуын ачыклый. Шулай итеп, кадер-хәстәрдә өенә – туганнары кочагына кайтып җитә.

Җизнәсе Виктор Васильковның юлына очравын Валентина Петровна әле хәзер дә Күкләрнең ярдәме, могҗизасы дип саный...

КИЯҮГӘ – ЛАГЕРЬГА...

1944 елда Валентина Макова Казан дәүләт медицина институтына укырга керә. Бер-бер артлы апасы Нина һәм әнисе үлеп китәләр. Дәүләт имтиханнарын тапшыргач, Валентинаны, дипломлы белгеч буларак, Башкортостанга билгелиләр. Березовкада әтисе белән апасының 4 яшьлек кызы Вера берүзләре калган була. Шуңа күрә Березовкада эшләргә рөхсәт алып, 1949 елның сентябреннән санэпидстанциядә эпидемиолог булып эшли башлый. Әтисен, кечкенә Верочканы тәрбияли.

«Кияүгә чыгарга җыенмыйм» дип кырт кискән Валентинаны үзенең насыйбы 1950 елның июлендә эзләп таба. Ул мәктәп елларыннан ук таныш авылдашы Аркадий Хлебников булып чыга.

– Мин мәктәптә укыганда Аркаша район газетасы редакциясендә эшләде, ә мин мәктәп газетасы өчен җаваплы идем, – дип сөйләде Валентина Петровна. – Аркаша бик яхшы, игътибарлы ир һәм әти булды. Тормышка карашларыбыз да туры килде, бер-беребезне бер караштан, ярты сүздән аңлап яшәдек, шөкер...

Кияүгә чыккач, туй сәяхәтенә чыгып китәләр алар. Мәскәүдә, Казанда, Киевта, Миргородта булып кайталар. Аннары, 1956 елда, Аркадий Хлебниковны МВД гаскәрләре буенча Ангарлагерьга лагерь пункты начальнигы итеп билгелиләр. Шулай итеп, Валентина Макова, инде Хлебникова фамилиясен алып, ире артыннан Себергә китеп бара...

– Андагы контингент бик чуар иде, – ди ул, – Квантун армиясенең әсирлеккә төшкән япон хәрбиләре дә, сәяси тоткыннар да, җинаятьчеләр дә. Тирә-юньдә исә – очсыз-кырыйсыз тайга...

Валентина Макова ире һәм улы Михаил белән. Себер, 1951 ел.

«ҮЗЕГЕЗНЕ ГУМАНЛЫ ТОТЫГЫЗ»

Лагерьда, – Лена ярларында яшәгән елларын үтә бер җылылык һәм саклык белән искә ала ул. Биредә 1951 елның 28 апрелендә уллары Михаил дөньяга килә. 1954 елның 11 октябрендә кызлары Наташа туа.

– Матди яктан без бик яхшы яшәдек, хезмәт хакына өстәп, Себер өстәмә акчасы да ала идек, – ди. – МВД системасында озак еллар эшләгән өчен дә түләделәр.

Төрле хуҗаларда фатирларда яшиләр. Алты ел эчендә тугыз урын алыштыралар.

– Соңгы өч елда дүрт хуҗага бүленгән йортта тордык, – дип искә ала Валентина Петровна. – Аңа кадәр – бик яхшы фатирда: ике зур гына бүлмәсе, кухнясы, иркен балконы бар иде. 1952 елның гыйнварыннан мин лазаретта терапевт вазыйфасын башкарырга керештем. Лазаретта 400–500 ләп кеше була торган иде. Берара хатын-кызлар лазареты да эшләде. Махсус бүлек тә бар иде – анысында аеруча куркыныч тоткыннарны, нигездә, җинаятьчеләрне, тоталар. Тәрәзәләрендә һәм ишекләрендә – тимер рәшәткәләр. Табибны обход вакытларында һәрчак надзиратель озатып йөри. «Зона»га без коралсыз керә идек, әмма һәрвакыт сак белән. Табибларны эшкә алганда, баштан ук кисәтеп куйдылар: үзегезне гуманлы тотыгыз, тоткыннарга беркайчан да арестантлар икәнлеген искә төшермәгез, рәнҗетмәгез...

– Лагерь чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган дивар артында иде. Территориянең почмагы саен – солдатлар урнашкан вышкалар. Хастаханә дә уратып алынган, анда керә торган пунктта һәрчак кораллы солдатлар кизү тора. Махсус пропусклар белән йөрдек.

КАЗАНГА – ТЫНЫЧ ТОРМЫШКА...

Күп тә үтми, армиядә һәм МВД сафларында кыскартулар башлана. Аркадий Хлебниковны армиядән капитан дәрәҗәсендә кыскарталар.

– Себердә яшәгән алты ел эчендә без бары тик бер генә тапкыр отпускта булдык, – дип искә ала Валентина Петровна. – 1953 елда Березовкага кайтып килдек, Казанда Аркашаның туганына хәл белергә сугылдык. Аркаша Казандагы финанс-икътисад институтының читтән торып уку бүлегенә керде. 1956 елның августында Казанга кайттык.



Действителен при предъявлении
личных документов
ПРОПУСК № 54
НА ПРАВО ВХОДА В ЗОНЫ
ЛАГПУНКТОВ АНГАРЛАГА
МЮ СССР

Ангарлагерьга керү өчен бирелә торган пропуск

– Казанда 11 нче номерлы хастаханәнең 8 нче амбулаториясенә участок терапевты булып эшкә урнаштым, – дип сөйли Валентина Петровна. – Аркаша да, кайту белән, озак вакыт эшсез җәфа чикте. Гәрчә бөтен дәреслекләрдә дә СССР да соңгы эш таба алмый интегүче кеше 1932 елда теркәлгән, дип язсалар да.

1958 елда, институтны «бишле»гә генә тәмамлап, Аркадий Хлебников, ниһаять, Куйбышев исемендәге химзаводка үз белгечлеге буенча эшкә урнаша. Ул анда гомере буе эшли. Зур хөрмәт казана.



Себер, Лена. елгасы. 1954 ел.

Михаил Хлебников, улы:
– Мин үземнең лагерьда туганлыгымны еллар узгач кына аңладым. Ә ул чакта башыма да килми иде. Без бит «зона» эчендә тормадык. Мин аны әни белән әтинең эш урыны дип кенә белә идем. Лагерь начальнигы улы икәнлегемне ваемлагач, әни белән әтинең эше нидән гыйбарәт булуын аңлагач, тарих белән кызыксына башладым, аларның истәлекләрен теркәдем. Болары – үскәч, балигъ булгач инде. Ә балачагым һәркемнеке кебек үк бер хәсрәтсез һәм рәхәт үтте. Бик матур табигате белән истә калган Себер...

Клара Таҗиева, сәнгать белгече, гаилә дуслары:
– Валентина Петровна участок табибы иде. Безне, авырып киткән балаларны карарга килгәндә, үзен итагатьле, йомшак тотса да, аңардан шүрләп тора идек. Аның һәм иренең нинди сугыш михнәтләре күргәнен үсә төшкәч кенә белдем. Уллары Михаил белән кызлары Наташага музыка дәресләре укыта башлагач, Хлебниковлар гаиләсе белән дуслашып киттем. Ул дуслык гомер буена сузылды. Искиткеч гаилә, чын интеллигентлар. Сугыш чорында да, лагерь диварларында да, тыныч шартларда да бердәй зыялы булып кала алган кешеләр. Без хәзер тарих дәреслекләреннән дә укып белә алмаган шомлы да, данлы да дәвернең соңгы могиканнары.

«БУЫННАР» ПРОЕКТЫ

ТЫЮ САЛЫНГАН ТАРИХ

1944 елның августы. Сугышның иң куркыныч чагы артта калды, аның ничек тәмамланачагында инде беркемнең дә шиге юк. Фронтларда һөҗүм бара. Ә идеологик фронтта хәлләр ничек соң? Монда да кул кушырып утырырга ярамый, дошман йоклап ятмый ул! Иң «уңышлы» идеологик һөҗүм операцияләренең берсе Алтын Урдага каршы ясала.

Автор:
Нияз Әхмәдуллин

ШӘРЫК АЛДЫНДА БАШ ИЮ

1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитетының «Татар партия оешмасында массакүләм-сәяси һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» карары дөнья күрә. Әлеге документ дөньяга чыгар алдыннан, республикада идеологик-сәяси эшнең торышын Мәскәү комиссиясе тикшерә. Аның иң кызган чагында җирле газетада ҮК кураторларының ачуын чыгарган тупланма басыла. ВКП (б) ҮК секретаре Александр Щербаков исеменә доклад җибәрелә: «Красная Татария» республика газетасы редакциясе бу елның 14 июнь көнендә Берләшкән Милләтләр Оешмасы көненә багышланган махсус сан чыгарды. Газетаның беренче битендә редакция исеменнән: «Бу санны без батыр союзникларыбыз – Бөекбритания һәм Америка Кушма Штатларына багышлыйбыз», – дип хәбәр ителә. Газетаның исеме өстендә АКШ, Бөекбритания һәм СССР флаглары сурәте басылган һәм, моннан тыш, инглиз телендә сәламләү лозунгы бирелгән...» Нәтиҗә: газета «Гитлерга каршы коалиция булдыру һәм ныгыту эшендә Советлар Союзының ролен киметә, совет халкының һәм Кызыл Армиянең Гитлер Германиясенә каршы көрәштәге әһәмиятен түбәнәйтә»...

Алга таба эшләр кыза бара. Бер айдан соң Үзәк Комитетка чираттагы доклад китә. Бу юлы уяу комиссия, Җучи олысы (Алтын Урда) тарихын дөрес бәяләмәү, «Идегәй» эпосы каһарманы – хәрби башлык Идегәйнең татар әдәбияты һәм тарихчылары тарафыннан, Алтын Урда хакимиятенә каршы көрәшүче буларак, «хаталы» рәвештә күрсәтелүе, татар халкы үткәннәрендәге, аның милли, мәдәни һәм дәүләтчелек тарихындагы «ялгыш» тикшеренүләр булу сәбәпле, борчылуын белдерә. Болар барысы да совет халыклары дуслыгын ныгытуга комачаулый, Совет власте дошманнары тегермәненә су коя, дип нәтиҗә ясый доклад авторлары.

Иптәшләрнең сүзенә ышанганда, хаталар, чыннан да, куркыныч. Әйтик, Татарстанда «Идегәй» эпосын татар мәдәниятенең иң югары казанышы буларак бәяләргә җөрьәт итәләр икән. Хәтта, гөнаһ шомлыгы, Идегәйне Давид Сасунский, «Юлбарыс тиреле витязь» һ.б. белән бер рәткә куялар. Ул гына да түгел, Идегәйне «азатлык көрәше герое» буларак олылап, «Совет әдәбияты» журналында Нәкый Исәнбәт мондый нәтиҗәгә килә: Туктамышка каршы көрәшеп, Идегәй Алтын Урдада мөстәкыйль дәүләтләр, шул исәптән Мәскәү кенәзлеге барлыкка килү һәм бүленеп чыгу өчен җирлек әзерли...

Партия органнарының ачунәфрәте һәм моның нәтиҗәләре тарих фәне өчен чын мәгънәсендә фаҗига булып чыга. Урта гасырларның әдәби һәйкәле кинәт кенә Сталин идеологлары кулында тарихны кире язу өчен сәбәп-коралга әверелә... Август карарының бер пунктында түбәндәге юллар бар: «ВКП(б) Татар өлкә комитетына Татарстан тарихын фәнни өйрәнү эшен оештырырга тәкъдим итәргә, Татарстан тарихын яктыртуда (Алтын Урданы мактау, Идегәй турындагы ханлык-феодальлек чоры эпосын популярлаштыру) аерым тарихчылар һәм әдәбиятчылар тарафыннан җибәрелгән җитди җитешсезлекләрне һәм хаталарны бетерергә...»

«ДӨРЕС» НӘТИҖӘЛӘР

Юнәлешләр бирелә, тегермән ташы шунда ук әйләнә башлый. Өлкә комитетының беренче секретаре Владимир Никитин, Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Хәмит Ярмөхәммәтов вазыйфаларыннан азат ителә, аларга шелтәләр белдерелә, кешеләр эштән куыла. Алтын Урда чорын тикшерүчеләренең «хаталары»н ачып күрсәтә торган, язучылар, сәнгать белгечләре иҗатында, галимнәрнең тикшеренүләрендә, идеология өчен җаваплы активлар эшендә «дөрес» басымнар куйган идеологик киңәшмәләр дә бер-бер артлы үтә.

Хәзер инде Алтын Урда, рус кенәзлекләрен талаган, артка сөйри торган феодаль дәүләт буларак, бары тик тискәре рухта гына искә алынырга мөмкин. Татар халкы тарихы рус халкы белән берлектә царизмга каршы күтәрелгән восстаниеләр аша гына яктыртыла, милли азатлык хәрәкәте алгарышка каршы хәрәкәт буларак бирелә. Мәскәү кенәзлегенең һәм Россия империясенең колонизаторлык сәясәтен өйрәнүгә тыю салына. Гомумән, хәзер татар халкының чын тарихы 1917 елгы революциядән соң гына башлана.

ВКП(б) үзәк органы – «Большевик» журналында редакция тарафыннан мәкаләләр басыла. Алардагы төп фикер – «Алтын Урданың ролен, фәнгә каршы килеп, зурайту, матурлау» «бөек идея» – «СССР халыкларының ленинчыл-сталинчыл дуслыгы»нан чигенү булып тора да инде. Ә бу исә «халыклар арасында дуслыкның өзелүенә, Совет дәүләтенең куәтен какшатуга» китерә. Моның белән шөгыльләнергә маташкан кеше «дошманның ярдәмчесенә, бөек эшебезгә аяк чалучыга әверелә». Уңга-сулга бер адым ясыйсыз икән, үзегезгә үпкәләгез, янәсе, без кисәттек.

Шундый хәлгә тарыгач, татар халкы тарихы белән нишләргә соң? Алтын Урдада тамырлары

Иллюстрация: Тавил Хаҗиәхмәтов

юк икән, Идел буенда татар каян килеп чыккан да бүгенге бәхетле көненә кадәр кайда, ничек яшәгән? Алар Тәңренең үзеннән, җиде кат күктән туп-туры шушында төшеп утырмаган лабаса! Барлыкка килгән бушлыкны ничек тә булса тутыру өчен, гади генә бер схема уйлап табалар да аны махсус чарада – «Казан татарларының килеп чыгышы турында фәнни сессия»дә (1946 елның 25–26 апрелендә СССР Фәннәр Академиясенең Тарих һәм фәлсәфә бүлеге һәм СССР ФА Казан филиалы белән берлектә үткәрелгән) рәсми ныгытып-беркетеп куялар.

Партия галимнәре Идел буе татарларының нәсел шәҗәрәсе рус халкы кебек үк татар-монгол изүеннән интеккән Кама һәм Идел болгарларыннан гына килә дигән фикердә үзара «килешә». Идел буе Болгары иле Алтын Урда составына вассал дәүләт буларак керә... Казан ханлыгы, имештер, Болгар патшалыгы нигезендә барлыкка килгән, бу исә Алтын Урда таркалу нәтиҗәсендә мөмкин булган. Алтын Урда рус һәм башка изелгән халыкларның көрәше аркасында яшәүдән туктый. Шул рәвешле татар халкы тарихы ул вакыттагы ТАССРның кечкенә территориясе белән чикләнә. Алтын Урданың татар милләте формалашуда зур роль уйнаган бай мәдәнияте белән барлык элемтәләр дә кискен рәвештә өзелә. Нәтиҗәдә, татарлар үткәннәрсез, тамырларсыз кала.

Тарих сәхифәләренең бәяны СССРда алга таба бары тик әлеге идеологик схема гына барды. Соңгы дистә елларда Россия тарихын өйрәнү акрынлап фәнни юнәлешкә салына. Тарих, ниһаять, хакимият хезмәтчесе функцияләреннән арына бара. Бу – катлаулы һәм озак процесс булып чыкты. Күп кенә архивлар ачылды, чит илләрнең тарихи чыганаклары белән танышу мөмкинлеге туды, каты куллы партия, дәүләт цензурасы юк хәзер.

Нәтиҗәдә, илнең үткәнендә күп милләтле тарихның бай төсләрен колачлаган буяулар төрлелеге чагыла башлады. Россия халыклары дуслыгы өчен бернинди куркыныч та юк икән лабаса. Үзара тигезләр арасында дуслык ныклырак була ул, дип өйрәтә тарих галиҗанәпләре.

татмедиа

Язып һәм от!

Телевизор, көнкүреш техникасы, башка күп кенә бүләкләр

Бүләкләр 2019 елның 16 августында уйнатылачак

1 ЯЗЫЛ — 30.06.2019 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә өч басмасына язып (акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)

2 ҖИБӘР — язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр (телефон номерыңны күрсәтергә онытма!) Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ — телевизор, мультиварка, иттарткыч, блендер, йон юрган һәм башка призлар от

Реклама 16+

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында. Акцияне үткәрү вакыты: 22.04.2019 – 20.09.2019
Заявкалар 2019 елның 20 июленә кадәр кабул ителә. Оештыручы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 42нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Фото «Татэнерго» АҖ-нән алынды

Рәүзил Хаҗиев, «Татэнерго» АҖ генераль директоры, июньдә үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә

ТЫРЫШЛЫК ҺӘМ ЮГАРЫ ТАЛӘПЧӘНЛЕК – АНЫҢ ТӨП СЫЙФАТЛАРЫ

Хезмәт эшчәнлеген туган ягы – Әгерҗе районында башлап җибәрә. Аннан соң Яр Чаллы шәһәре башкарма комитетында эшли, шәһәрнең вице-мэры, «Энергосбыт»та баш инженер вазыйфаларын башкара. 2000 нче еллар башында Рәүзил Мәгъсумҗанович – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары, беренче урынбасары. 2011–2012 елларда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе булып эшли.

«Татэнерго» компаниясен җитәкләүне тәҗрибәле идарәчегә тапшыру – уңышлы карьераның чираттагы этабы. Тармак бүгенге көндә актив үзгәртеп корыла, һәм Рәүзил Мәгъсумҗанович әлеге киң колачлы эшне уңышлы башкарып килә.

Энергия нәтиҗәлелеге өлкәсендә хезмәттәшлек өчен рәхмәт

Азат Нигъмәтҗанов,
Казан башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте буенча беренче урынбасары

– Хөрмәтле Рәүзил Мәгъсумҗанович! 60 яшьлек юбилеегыз көнендә, барлык матур теләкләргә кушылып, Казан төзүчеләр җәмәгатьчелеге исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезгә ихлас котлау сүзләре юлларга рөхсәт итегез.

Сез – еллар аша туган җиргә, хезмәткә һәм тормышка ярату хисләрен саклап кала алган шәхес үрнәге. Сез күңелегез белән һаман яшь, замана куйган таләпләргә һәрвакыт әзер. Эшчәнлек төрен алыштыруга әзерлегегез Сезнең өчен мөмкин булмаган нәрсәләр юклыгын күрсәтә. Сез инженерлык эшләрен дә, административ вазыйфаларны да бертөрле тырышлык белән башкарасыз. Һөнәри сәләтегез Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында лаеклы рәвештә бәяләнде. Министр урынбасары вазыйфасында эшләү дәверендә Сез республика үсеше өчен күп нәрсәләр башкардыгыз һәм «Татэнерго» АҖ генераль директоры хезмәтендә дә алгарыш юлыннан атлавыгызны дәвам итәсез.

Эшлекле абруегыз озак еллар дәвамында фидакарь хезмәт итү һәм алга карап планлаштыра белү нәтиҗәсе булып тора. Сезнең тарафтан кабул ителгән дөрес карарлар, энергиянең нәтиҗәлелеге өлкәсендә туа торган проблемаларны кисәтеп, замана белән бергә атлый. Илдә энергетика җитди үзгәрешләр кичерсә дә, Сез, кулыгызны һәрчак пульста тотып, иң прогрессив эшләнмәләрне куллануга кертү карарын кабул итүдән курыкмыйсыз. Электр энергиясен җитештерү, аны дөрес куллану һәм гади кулланучыларның ихтыяҗлары турында барысын да беләсез, нәкъ менә шуңа күрә Сез Россия Федерациясендәге иң эре энергетика компанияләренең берсе белән уңышлы җитәкчелек итәсез.

Күпьеллык фидакарь хезмәтегез өчен рәхмәт белдерергә рөхсәт итегез. Казан кешеләре тормышын елдан-ел уңайлырак ясау юнәлешендә Сезнең белән хезмәттәшлек итүебезгә бик шат. Сезнең алга таба да ирешелгәннәрдә беркайчан да туктап калмавыгызны, республика һәм аның башкаласы Казанның чәчәк атуына зур өлеш кертеп, яңа һөнәри биеклекләр яулавыгызны телибез.

Ныклы сәламәтлек, күтәренке кәеф Сезгә, хөрмәтле Рәүзил Мәгъсумҗанович! Тормышыгызда бәхетле мизгелләр күбрәк булсын, эш көннәрегез – уңышлы, елларыгыз күңелле үтсен!

Фото Казан башкарма комитеты матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

Тәҗрибә һәм яңалыклар бәйләнешенең иң яхшы үрнәге

Борис Тихомиров,
«Казан Гипронииавиа-промы» КТ
генераль директоры

Фото «Казан Гипронииавиапромы» КТнән алынды

– Хөрмәтле Рәүзил Мәгъсумҗанович! «Казан Гипронииавиапромы» КТ коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм!

Хезмәт сөючәнлек һәм фидакарьлек инде күптән Сезнең һөнәри абруегызның аерылгысыз өлешенә әверелде. Карьерагызны түбәннән, нигездән башлаган кеше буларак, Сез һәр көн башкарыла торган хезмәтнең бәһасен бик яхшы беләсез. Җитештерүне оештыру һәм коллективны җитәкләү буенча тирән белем-тәҗрибәгезгә таянып, Сез кешеләрне эшкә рухландыра һәм дөрес социаль сәясәт алып бара беләсез. Шуңа күрә Сезне бизнес-җәмәгатьчелек даирәләрендә хөрмәт итәләр, хөкүмәт структураларында Сезнең киңәшләрегезгә колак салалар.

Киңкырлы административ эш тәҗрибәсе алганнан соң, энергетика тармагына әйләнеп кайтып, Сез үзегез башкарырга алынган теләсә кайсы мәсьәләнең белемегезгә һәм талантыгызга бәйсына алуын исбатладыгыз. Башка югары вазыйфаларны биләгәндә дә Сез ярдәмгә мохтаҗларга бик күп яхшылык кылдыгыз. Һәм бүген дә игелекле эшләрне башкарганда кешеләргә булышу мөмкинлегеннән баш тартмыйсыз.

Хезмәт эшчәнлегегез турында сөйләгәндә, Сезнең талантлы җитәкче буларак, тупланган тәҗрибәне яңалык кертүләр белән шәп итеп бәйли белүегезне һәм югары технологияле проектларга кыю рәвештә алынуыгызны билгеләп үтми булдыра алмыйм. 88 елдан артык тарихы булган компаниянең иминлеге хакына, Сез дистә еллар дәвамында үзегезнең күпкырлы белемнәрегезне оста кулланасыз, компаниянең эш күрсәткечләре елдан-ел нәтиҗәлерәк була бара.

Җылылык челтәрләре тармагы бүгенге көндә актив үзгәрешләр кичерү юлында, һәм әлеге җәһәттән үлчәнелгән, дөрес һәм прогрессив карарлар таләп итүче төрледән-төрле сораулар туып тора. Җылылык хуҗалыгы эшенең перспективалы схемаларын эшләү буенча Татарстан лидер төбәк санала һәм Сезнең компания – Россиядәге коллегалар өчен лаеклы үрнәк.

Сезнең кебек энергияле кеше өчен яшь чик түгел, бәлки тәҗрибә һәм зирәклек чыганагы гына. Спортка, туган якка мәхәббәт, гаилә иминлеге һәм хезмәт сөючәнлек кебек сыйфатларыгыз Сезгә, яңадан-яңа офыкларны ачып, алга таба хәрәкәт итәргә булышсын. Шуңа күрә Сезгә актив озын гомер, ныклы сәламәтлек телим, якыннарыгызның күңел җылысын, хезмәттәшләрегезнең ярдәмен-хуплавын тоеп яшәргә язсын!

Рәүзил Мәгъсумҗанович, Сезгә бәхет, барлык игелекле эшләрегездә уңышлар гына юлдаш булсын!

Нәтиҗәле карарлар һәм кыю җиңүләр теләге

Эдвард Абдуллаҗанов,
Казан дәүләт энергетика университеты ректоры

Фото КДЭУ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

– Хөрмәтле Рәүзил Мәгъсумҗанович! Сезне Казан дәүләт энергетика университеты коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән тәбрикләргә рөхсәт итегез!

Хезмәт юлыгызны Әгерҗе районында инженер-энергетик вазыйфасында башлап, Сез бүгенге көнгә кадәр туган җирегезгә җылы мөнәсәбәтегезне саклап киләсез. Авылдашларыгызга ярдәм кулы сузып һәм янәшәгездәгеләрнең иминлеген кайгыртып, игелекле эшләрегезне сабыр, тыйнак башкарасыз.

Яр Чаллы хакимиятендә эшләгән чорыгызда ТКХ һәм энергетика тармакларын өйрәнү киләчәктә «Татэнерго» АҖнең генераль директоры дәрәҗәсенә ирешү юлында мөһим өстенлек булды. Сез республикада энергиянең нәтиҗәлерәк өлкәсендә күп нәрсәләр эшли алдыгыз. Бу урында энергия куәтләрен арттыру шартнамәсе программасында Татарстанның ҖЭҮ-1 һәм ҖЭҮ-2 җәмгыятьләрен катнаштыруга караган тәкъдим-башлангычыгызны билгеләп үтәсе килә. Әлеге гамәл Татарстанда электр энергиясе кытлыгын хәл итәргә булышты.

Сезгә хезмәттәшлек өчен рәхмәтемне белдерәм. Сезнең кебек алдынгы карашлы җитәкчеләр эшләгәндә мин КДЭУны тәмамлаучыларның имин киләчәге өчен тыныч. Бүген Сез җитәкчелек иткән «Татэнерго» АҖ кайчандыр Татарстанда беренче энергетика югары уку йортын ачуга этәргеч бирде. КДЭУ бүгенге көндә ихтыяҗ зур булган профессионалларны укытып чыгара. Аларның күпләре республикабызда энергия саклаучы технологияләрне үстерергә ярдәм итеп, Сез җитәкләгән компаниядә хезмәт куя.

Мин Сезне ихтыяр көченә, харизмага ия, бернинди авырлыклар каршында туктап калмый торган кеше буларак беләм. Сез туплаган тәҗрибә, фикер киңлеге җылылык һәм энергетика тармакларында иң алдынгы проектларга җитәкчелек итәргә мөмкинлек бирә. Һөнәри өлкәдә коллегаларыгыз арасында ихтирам казандыгыз, киңәшләрегезгә республика җитәкчелеге колак сала, федераль дәрәҗәдә дә Сез зур абруйга ия. Куйган хезмәтегез нәтиҗәсендә Татарстан энергетикасы ил күләмендә алдынгы позицияләрне били, киләчәктә дә нәтиҗәле карарларыгыз һәм якты җиңүләрегез күп булсын.

Сезгә чын күңелдән киң күләмле проектларның булып торуын, һәр башлангычыгызның уңышка ирешүен телим. Янәшәгездәге кадерле затлар – туганнарыгыз һәм якыннарыгызның хуплавын, ярдәмен тоеп яшәгез, коллегаларыгыз һәм фикердәшләрегез куелган бурычларны хәл итүдә таяныч булсын.

Рәүзил Мәгъсумҗанович, Сезгә иминлек, зур уңышлар юлдаш булсын!

Дәрт-дәрман белән тулы тормыш

Рифнур Сөләйманов,
«Татэнергосбыт» АҖ директоры

– Хөрмәтле Рәүзил Мәгъсумҗанович! «Татэнергосбыт» АҖ коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне чын күңелдән күркәм бәйрәмегез – 60 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм!

Күпкырлы тирән тәҗрибә һәм узган еллар югарылыгыннан караганда, Сезнең, һичшиксез, горурланырлык эшләрегез күп. Сез – һәрнәрсәдә мөмкинлекләр күрә белүче актив һәм эшлекле кеше.Тирән аналитик сәләт, үткен акыл һәм идарәче таланты Сезгә куелган максатларыгызга ирешергә, иң кыю һәм югары технологияле идеяләрегезне тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Компания хезмәткәрләре зур ышаныч белән Сезнең артыгыздан атлый һәм энергетика тармагында эшләүче башка коллегаларыгыз Сезгә тигезләнә. Сез, һичшиксез, республиканың энергетикага гына түгел, коммуналь проблемаларына кагылышлы мәсьәләләрдә дә үз фикере булган абруйлы шәхес.

Сезнең җитәкчелегегездә «Татэнерго» менә инде шактый еллар дәвамында электр энергиясе җитештерүче Россия компанияләре арасында беренче унлыкка керә. Сезнең турыдан-туры катнашлыгыгыз нәтиҗәсендә Татарстан куәтләрне бүлешү шартнамәсе программасына да керә алды. Бүген дә Сез республиканың энергетик куәтен арттыру мәсьәләләре белән даими рәвештә шөгыльләнәсез. Әлеге уңышлар, һәм шулай ук компания иминлеге хакына Сез башкарган көндәлек хезмәт иң югары бәягә һәм рәхмәткә лаек.

Бер тармакта эшли торган хезмәттәшегез буларак, минем Сезнең белән киңәшләшер һәм акыллы җавап ишетер сорауларым һәрвакыт булып тора. Шуңа күрә Сезгә чын күңелдән нәтиҗәле һәм үзара файдалы хезмәттәшлегебез өчен рәхмәт әйтәсем килә. Сезнең кебек профессионал белән янәшә торып эшләү зур бәхет кенә түгел, энергетика бизнесы үсешен һәм бу үсешнең күркәм нәтиҗәләрен ачык күрә алу мөмкинлеге дә.

Сезгә бәхет һәм сәламәтлек телим. Тормышны яратуыгыз беркайчан да сүнмәсен-сүрелмәсен, ныгый гына барсын. Йортыгызга – бәрәкәт, үзегезгә яңадан-яңа җиңүләр һәм казанышлар юлында уңышлар телим!

Фото «Татэнергосбыт» АҖнән алынды

Еллар дәвамында казанган хөрмәт

Алексей Юмангулов,
«Түбән Кама ҖЭҮ» ЖЧЖ директоры

– Хөрмәтле Рәүзил Мәгъсумҗанович! Күркәм юбилей көнегездә «Түбән Кама ҖЭҮ» ЖЧЖ коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән ихлас котлауларны һәм матур теләкләрне кабул итеп алыгыз.

Безнең энергосистемада Сезне югары интеллектка ия, хезмәт сөючән кеше, лаеклы тормыш мәктәбе үткән, бай идарәче тәҗрибәсе туплаган җитәкче буларак беләләр һәм хөрмәт итәләр. Татарстан Республикасының иң эре энергетика холдингы белән җитәкчелек итүгә керешеп, Сез үз иҗат потенциалыгызны тулы көченә куллана алдыгыз.

Гомуми стратегияне аңлауга, үзара ышаныч һәм хөрмәткә корылган әлеге хезмәттәшлек безнең өчен бик кадерле.

Сезгә ихлас күңелдән ныклы сәламәтлек һәм иминлек телибез. Янәшәгездә һәрвакыт ышанычлы дусларыгыз булсын, ә туганнарыгызның һәм якыннарыгызның яратуы һәм хуплавы эшчәнлегегезнең барлык юнәлешләрендә дә яңа казанышларга һәм уңышларга ирешергә көч-куәт бирсен!

Фото «Түбән Кама ҖЭҮ» ЖЧЖнән алынды

Валерий Сорокин,
«АК БАРС» БАНК ГАҖ Директорлар советы рәисе,
«Связьинвестнефтехим» АҖ генераль директоры,
майда үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Үсеш векторларын билгеләп

– Хөрмәтле Валерий Юрьевич! Шәхсән үз исемемнән һәм »Татэнерго» АҖнең күпсанлы коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Сезнең хезмәт биографиягез тулысынча Татарстан Республикасы белән бәйләнгән. Нигез салынганнан бирле Сез генераль директор вазыйфасын үтәгән «Связьинвестнефтехим» АҖнең икътисадый стратегиясен уңышлы эшләрлек итеп төзү нәтиҗәсендә, ул Татарстан холдинглары арасында аерым урын алып тора. Бүген «Связьинвестнефтехим» АҖ, күпләгән җитди проектларны тормышка ашырып, республиканың сәнәгый һәм икътисадый сәясәте үсешен билгеләүдә актив катнаша.

Профессиональлек, белем, эшкә системалы якын килә белү, күркәм шәхси һәм эшлеклелек сыйфатлары Сезнең белән эшләргә һәм аралашырга туры килгән һәркемдә тирән ихтирам уята.

Хөрмәтле Валерий Юрьевич! Холкыгызга хас лидерлык сыйфатлары киләчәктә дә республика иминлеге хакына югары максатлар куярга һәм аларны уңышлы тормышка ашырырга ярдәм итсен! Энергетика тармагына күрсәткән ярдәмегез өчен чын күңелдән рәхмәт. Сезгә ныклы сәламәтлек һәм күтәренке кәеф телим!

Реклама
Фото «Татэнерго» АҖнән алынды

Дамир Кәримуллин,
«КМҖБ» АҖ
генераль директоры

Һәр эшегездә уңыш юлдаш булсын

– Хөрмәтле Валерий Юрьевич!

Казан моторлар җитештерү берләшмәсе коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне күркәм бәйрәмегез – 55 яшь тулган көнегез белән котлыйм!

Әлеге матур бәйрәм көнендә Сезгә чын күңелдән иминлек һәм бәхет теләргә рөхсәт итегез.

Без Сезне чын лидер, талантлы җитәкче һәм оештыручы буларак беләбез. Максатчан булуыгыз нәтиҗәсендә Сез тормышта күп нәрсәләргә ирештегез. Күркәм эшләрегез, карьерагыз нәкъ менә шуны раслый. Хезмәт иткән предприятиегезгә 16 ел дәвамындагы тугры калуыгызны да билгеләп үтәсе килә. Әлеге вакыт эчендә холкыгызның көчле яклары бар колачында ачылды. Бай хезмәт тәҗрибәсе, энергия, тирән белем һәм эшкә тугрылык Сезгә республикабызның икътисадый куәтен арттырырга ярдәм итә.

Сез авырлыклардан курыкмыйча, үз көченә ышанып, янәшәдәгеләрнең ярдәменә таянып, җитди проектларны гамәлгә ашырырга алынучылар токымына карыйсыз. Сезгә хас югары профессиональлек, принципиальлек, партнерларыгыз һәм хезмәттәшләрегез белән дөрес мөнәсәбәтләр урнаштыра алу сәләте күркәм нәтиҗәләргә китерә. «СИНХ» АҖ, төп акционер буларак, «КМҖБ» АҖ ндә барган күп кенә процессларга йогынты ясый, компаниянең капиталлашуына ярдәм итә. Безнең предприятиеләребезне озак еллар дәвамындагы партнерлык мөнәсәбәтләре бәйли, уртак эшләребез һәрвакыт тотрыклы һәм ышанычлы.

Сезгә барлык эшләрегездә һәм башлангычларыгызда да – уңышлар, янәшәгездәгеләрнең ихтирам-хөрмәте юлдаш булсын!

Ныклы сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс көч-куәт телибез, иң кыю идеяләрегез, теләк-ниятләрегез тормышка ашсын!

Үзегезгә дә, якыннарыгызга да – бәхет һәм иминлек!

Реклама
Фото «КМҖБ» АҖнән алынды

Дмитрий Самаренкин, «Казан май комбинаты» АҖ Директорлар советы рәисе, Россия туплы хоккей федерациясе Башкарма комитеты әгъзасы, июньдә үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

– Хөрмәтле Дмитрий Анатольевич!

Борис Скрынник,
Халыкара туплы хоккей федерациясе (FIB) һәм Россия туплы хоккей федерациясе президенты

Россия туплы хоккей федерациясе исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 50 яшьлек юбилеегыз белән котлап, ихлас рәхмәтемне белдерергә рөхсәт итегез!

Сез гомерегезнең шактый зур өлешен актив эшкуарлык эшчәнлегенә багышладыгыз, ә күркәм уңышларыгыз һәм казанышларыгыз Сезне киләчәкне күрә белеп эш итүче җитәкче һәм Татарстан Республикасын, бүгенге җәмгыятьне үстерүгә шактый өлеш кертүче оста менеджер булуыгызны күрсәтә. Тулаем спортны һәм аерым алганда рус хоккеен яратуыгыз Сезнең менә дигән оештыру сәләтегезгә шәп тандем булып тора. Спорт дөньясына зирәк акылы белән дә, кайнар йөрәге белән дә эш итүче искиткеч профессионалга ия!

Безнең Сез «Динамо-Казан» хоккей клубы җитәкчелегендә һәм Россия милли җыелма командасы генераль менеджеры постында эшләгән вакыттагы күпьеллык үзара файдалы хезмәттәшлегебез иң кыю планнарны гамәлгә ашыруда искиткеч максатчанлык һәм югары профессионализм үрнәге булып тора. Спорт күзлегеннән караганда кыска гына вакыт эчендә Сезнең бәһаләп бетергесез ярдәмегез нәтиҗәсендә динамочылар коллективына туплы хоккей буенча Россия югарылыгына гына түгел, дөнья дәрәҗәсенә күтәрелергә мөмкин булды. Хоккейчылар Дөнья кубогы һәм Россия кубогы иялəре булдылар, шулай ук ил чемпионаты бүләкләренең тулы комплектын алуга ирештеләр. 2011 елда Казанда уздырылган туплы хоккей буенча дөнья чемпионаты һәм анда Россиянең ирләр командасының Идел ярлары буенда яуланган җиңүе безнең хезмәттәшлекнең аерым бер күркәм мизгеле булып тора!

Басымны үз кадрларыгызны әзерләүгә ясап, Сез идарәчеләр арасында беренчеләрдән булып нәтиҗәлелекнең сикәлтәле юлыннан киттегез. Бик вакытлы кабул ителгән карарның инде үз җимешләрен бирүен күрү куанычлы хәл: Казанда «Динамо» хоккей клубының нигезен тәшкил итүче яшь профессионаллар үсеп килә. Бу Татарстан Республикасында безнең милли спорт төрен үстерү өчен өметле мәйданчык барлыкка килүе турында сөйли.

Сезнең кебек актив кеше өчен 50 яшь – чик түгел, әлбәттә, ул тупланган зирәклек һәм ирешелгән казанышлар югарылыгыннан тормыштагы уңышларга борылып карар өчен мөмкинлек бирә торган чираттагы этап кына. Бу көчлекуәтле кешеләргә хас дәрт-дәрманның профессиональ һәм тормыш тәҗрибәсе белән күркәм рәвештә үрелеп баруын күрсәткән матур чор.

Сезгә ихлас күңелдән эшегездә тагын да зуррак җиңүләр, яңа офыклар, ныклы сәламәтлек һәм озын гомер, йортыгызга бәрәкәт һәм иминлек, гаилә бәхете телим! Уртак спорт хыялларына ирешү юлында хезмәттәшлегебез өчен Сезгә зур рәхмәт!

Реклама

Фото Россия туплы хоккей федерациясе матбугат хезмәтеннән алынды

ТАИФ
ГРУППА КОМПАНИЙ

Югары дәрәҗәдәге профессионаллар

Хөрмәтле Ринат Тәлгатович!

Сезне һәм Сезнең йөздә «ТКМИ-3» АҖ коллективын чын күңелдән күркәм юбилей датасы – компаниягә нигез салынуның 40 еллыгы белән котлыйбыз.

Шушы еллар эчендә Сез җитәкләгән компания, бүгенге юбилей көненә саллы нәтиҗәләргә ирешеп, зур һәм катлаулы юл үтте – хәзерге вакытта күп кенә эре компанияләр Түбән Кама монтаж идарәсенә иң мөһим һәм җаваплы проектларны ышанып тапшыралар.

ТКМИ-3 белгечләре – югары дәрәҗәдәге профессионаллар – иң куркыныч җитештерү объектларында эшләр башкаралар, Татарстан һәм Россиянең стратегик яктан әһәмиятле сәнәгать предприятиеләрендә эшлиләр. «ТАИФ» компанияләр төркеменең төзелә яисә реконструкцияләнә торган бер генә объекттагы эш тә Түбән Кама монтаж идарәсе коллективы катнашыннан башка эшләнми. Сез җитәкләгән компания партнерлары белән үз мөнәсәбәтләрен хөрмәт, үзара файдалы хезмәттәшлек һәм алынган йөкләмәләрнең һичшиксез үтәлеше принципларына таянып алып баруын билгеләп үтү аеруча куанычлы. Моның белән компания үзенә сыналган, намуслы һәм төзелеш-монтаж эшләрен ышанычлы башкаручы дигән абруй яулады.

Чын күңелдән Сезгә һәм Түбән Кама монтаж идарәсе коллективына нык сәламәтлек һәм иминлек, иң кыю проектлар һәм планнарыгызның тормышка ашуын, ышанычлы адымнар белән киләчәккә атлавын телибез. Алга таба да «ТКМИ-3» АҖ дистә еллар дәвамында тупланган тәҗрибә һәм хезмәт коллективының данлы традицияләре иң яңа технологияләрне һәм инженер эшләнмәләрен гамәлгә кертү өчен ышанычлы фундамент булып торган шундый ук уңышлы һәм перспективалы компания булып калсын! «ТКМИ-3» АҖнең һәр киләчәк юбилее Татарстан Республикасы, Россиянең үсеше һәм чәчәк атуы хакына яңа һөнәри җиңүләр һәм казанышлар белән билгеләп үтелсен!

«ТАИФ» Компанияләр төркеме

Реклама

Еллар дәвамында ирешелгән абруй

Илгиз Латыйпов,
«ТАИФ» АҖ генераль директорының төзелеш һәм капиталь ремонт буенча урынбасары

Фото «ТАИФ» АҖ нән алынды

«Бергә җыелу – эшнең башы. Бергә булу – прогресс. Бергә эшләү – уңыш» – Генри Фордның әлеге сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Шул ук вакытта теләсә кайсы предприятиенең эшлекле абруе кинәт кенә пәйда булмый, ә еллар дәвамындагы тырыш хезмәт нәтиҗәсендә туплана. Предприятиегезнең 45 еллык тарихы күпме уңышлы проектларны һәм башлангычларны үз эченә сыйдырган! Һәрвакыт үсешкә омтылу, уңышка юнәлеш ала белү, монтажлау эшләре базарындагы яңалыкларны төгәл күзәтә бару – болар барысы да предприятиегә теләсә кайсы, хәтта иң катлаулы чорларда да Татарстанның һәм Россиянең куркыныч җитештерү объектларында механомонтаж эшләре базарында лидерларның берсе булырга мөмкинлек бирә. «ТКМИ-3» АҖ – предприятиедә кешеләргә сакчыл мөнәсәбәт кебек күркәм традициянең заманча корпоратив рух белән гармонияле бәйләнеше яшәүгә ачык мисал.

Предприятие коллективына ихлас күңелдән иминлек һәм барлык күркәм эшләрендә уңышлар телим, 45 – предприятие өчен менә дигән яшь. Предприятиегезнең төп байлыгы – кешеләр. Җаваплы, алдынгы карашлы һәм эш сөючән белгечләр. Аларның һәркайсы предприятие үсеше өчен үз көчен кертә. Аларга чын күңелдән нык сәламәтлек, күңел күрлеге һәм яңадан-яңа казанышлар телим!

Реклама

Кзыл Яланның мәдәният учагы – башлангыч мәктәпне дә, клубны да сыендырган бина.

КЗЫЛ ЯЛАН: КЕЧКЕНӘ ДӘ ТӨШ КЕНӘ

Кзыл Ялан дип язылган элмә такта янына килеп туктадык. «И, шунда да авылның татарча атамасын хаталы язганнар», – дип уйлап куйдым. Соравымны бирми кала алмадым. Кзыл Ялан рәсми рәвештә шулай языла икән, татарча да.

Чистай районында матур исемле авыллар күп. Ни өчен Кзыл Ялангa тукталдыкмы? Безгә аның турында тирә-якның иң тырыш авылы дип сөйләделәр.

ӨЧ КЛАССКА БЕР УКЫТУЧЫ

Кзыл Ялан Татар Талкышы авылы җирлегенә керә. Биредә 93 хуҗалык бар, 262 кеше яши. Кибете, башлангыч белем бирү мәктәбе, мәчете, фельдшер-акушерлык пункты бар. Мәдәният йорты дип тә өстәр идем, анысын узган ел ябып куйганнар. Куркынычсызлык таләпләренә туры килми икән. Аңа карап авыл мәдәни учаксыз калмаган. Төрле бәйрәмнәрдә авылдашлар җыелып концерт куя. Кайда дисезме? Башлангыч мәктәп бинасында! Бер сыйныфны клуб өчен махсус ясаганнар. Алай гына да түгел, шул ук «сыйныфта» авыл музее да яши.

– Монда тагын бер-ике буш кабинет бар икән, әле җирле үзидарәне дә сыендыра аласыз, – дим, уенынчынын бергә кушып.

Ә чынлап сөйләшкәндә, юк, болай берләштерү бер дә начар түгел. Бөтенләй мәдәни учаксыз калганчы, шулай булса да – яхшы.

Кзыл Ялан башлангыч мәктәбендә 7 бала укый. Бу өч класска. Беренче сыйныфта – 1 бала, икенчедә – 2, өченче сыйныф бөтенләй юк, дүртенчедә 4 бала белем ала икән. Һәм барысы бер кабинетта укый, аларга бер укытучы белем бирә.

– 45 минутны өчкә ничек бүләсез? Балаларга дәресне өйрәтергә, өй эшен тикшерергә кирәк бит, – дип сорадым Кзыл Ялан мәктәбенең бердәнбер укытучысы Раилә Гиниятуллинага.

– Әйе, болай укуның аерым кыенлыклары бар инде. Ләкин минем тәртипкә салынган: бер сыйныфка тема өйрәткән арада икенчесенә язарга, өченчесенә укырга бирәм. Бездә зуррак балалар кечерәкләрне «шефлыкка» ала, ягъни бер-берсенең өй эшләрен тикшерә, хәтта билге дә куя.

Күп тапкырлар буялган агач идәннәр, совет заманыннан калган парта-шкафлар… Үзебез укыган мәктәпкә кайткан кебек булдым. Биредә ашханә дә юк. Балалар салкын паек белән туклана.

– Ризыкны бала саныннан кайтаралар, – диде Раилә ханым. – Чәйне үзем кайнатам. Балалар тагын өйләреннән савытка салып пешкән ризык алып килә. Аны, бергә утырып, тәмле итеп ашыйлар. Класска ризык исе тарала… Менә шулай яшибез.

Мәктәпкә ата-аналар да килгән иде. Алар белән дә сөйләшеп алдык. Сыйныф җитәкчеләреннән бик канәгать булуларын белдерделәр.

– Уртанчы сыйныфта укучы балаларны алырга авылга көн саен

Фото: Александр Ефремов

Мәктәпкә ата-аналар да килгән иде. Сыйныф җитәкчеләреннән бик канәгать булуларын белдерделәр.

Автор:
Руфия Фазылова

Кзыл Ялан башлангыч мәктәбенең бердәнбер укытучысы – Раилә Гиниятуллина.

автобус килә икән. Башлангычларны да Татар Талкышы мәктәбенә йөртәсегез килмиме? – дим.

– Андый сүзне әйтә күрмәгез! – диде бер ана.

– Ник?

– Балаларны тилмертү була ул. Болай алар йокыдан вакытында торып мәктәпкә килә. Рәхәтләнеп йөриләр. Дәресләре беткәч, өйләренә кайтып китәләр. Ә күрше авылга йөрсәләр, иртәнге җиде тулганчы чыгып китәргә кирәк. Дәресләре беткәч тә, зуррак балаларны көтеп, икегә кадәр утыралар. Безнең Раилә кебек укытучы һәр мәктәптә юк әле ул!

– Конкуренция булганда, баланың белем дәрәҗәсе яхшырак була, дигән фикер дә яши бит, – дип, һаман үз фикеремне белдерәм.

– Улым быел шушы мәктәпне тәмамлый, – дип сүзгә кушылды Энҗе Исхакова. – Мин үзем дә укытучы. Һәм чагыштырып әйтә алам: балаларның белем дәрәҗәсе башка мәктәпләрдән аерылмый. Дүрт укучының өчесе «4», «5» билгеләренә укый. Барысы да бик актив. Абыйлы-энеле, апалы-сеңелле шикелле алар...

– Әйе, балалар бик тату, – дип, әлеге ханымның сүзен җөпләде Раилә Гинаятуллина да. – Зурраклары кечкенәләргә ярдәм итә. Алар көне буе бергә. Мәктәптән кайтып, ашап-эчкәннән соң, янә бергә урамда уйныйлар. Кечкенә коллективның үз плюслары бар аның...

Кзыл Ялан мәктәбенең киләчәге өметле әле: мәктәпкәчә яшьтәге берничә бала бар икән. Киләсе елга өч укучы киләчәк. Димәк, авылның үзеге булган бу бина ябылмаячак. Кзыл Яланлылар өчен шунысы кыйммәт.

КОМБАЙНЧЫ СТАЖЫ – 70 ЕЛ

Кзыл Ялан чагыштырмача яшь авыл. Татар Талкышы авылыннан дистәләгән гаилә бирегә 1930 елда килеп урнашкан. (Ике авыл арасы җиде чакрым –авт.) Халык, уңдырышлы җирне махсус читтәрәк калдырып (иген үстерергә дип), ихаталарын куак, агачлар янына салган. Авыл оешкач та туган кешеләрнең берсе – Равил абый Мирсияпов. 1934 елгы ул. Комбайнчылар нәселеннән. Әтисе Фәйзрахман абыйның сугышка киткәндә кырда комбайны кала. Өч ел яу кырында йөреп, исән-имин туган ягына әйләнеп кайткач, Фәйзрахман абый яңадан үз комбайнына утыра.

– Безгә техника җене кагылган инде, – ди Равил абый. – Мин ундүрт яшемнән әти белән кырда – комбайнчы ярдәмчесе булып эшләдем. 1951–1952 елларда Тәтеш районына барып, трактор, комбайн йөртүчегә укыдым. Шофер таныклыгы алдым. Шул гомердән бирле руль артыннан төшмәгән инде. Хәтта армиядә дә трактор, комбайнда эшләдем. Ул чагында шоферлар бик дефицит иде. Миңа «учебка»дан соң ефрейтор исеме бирделәр.

Равил Мирсияпов 1953–1956 елларда Украинада хезмәт иткән. Комбайнда шунда эшләгән.

– Ул елларда Украинада колхозлашалар гына иде әле, – ди тәҗрибәле механизатор. – Колхоз рәисе безнең ротага килеп, солдатлар алып китә иде. Урып-җыю эшләре беткәнче шунда, кырда эшләдем.

Иң гаҗәбе – Равил Мирсияпов бүген дә комбайн, трактор йөртә, аларны үзе ремонтлый.

– Язын тракторы белән авыл кешеләренең бакчасына бәрәңге утыртып бирде, – диде бабайның кызы Рокыя апа. – Кыш буе гараждан керми, техникасын төзәтә. Ни дисәң дә, алар яңа түгел бит, гел карап торырга кирәк. Аннан җәе буе кырда инде...

Равил абый Мирсияпов бүген дә комбайн, трактор йөртә, үзе ремонтлый.

Шәйхетдиновлар гаиләсе.

– Эшләргә көче булгач, әйбәт инде, – дим, исем китеп.

– Күз тимәсен. Исәнлеге дә, акылы, зиһене дә егетләрнеке кебек. Бөтен кеше әйтә: эшли генә күрсен. Эштән туктаса, чиргә сабышачак ул.

Равил абый тормыш иптәше Әлфия апа белән ике ул, бер кыз тәрбияләп үстергән. Олы кызлары Рокыя апа Яр Чаллы шәһәрендә яши, ләкин атна саен кайтып йөри. Беренчедән, биредә эш күп – Равил абыйның әле ике сыеры, бозаулары бар. Икенчедән, әнисе – Әлфия апа инде соңгы елларда аягында бик йөри алмый. Аны тәрбияләргә кирәк.

– Өч ел элек йөрәк өянәгеннән кинәт кенә энем вафат булды, – диде Рокыя апа. – Төп нигезгә күченеп кайткан иде ул. Әти белән бергә пай җирләрен алып эшкәрттеләр. 9 сыер алган иде. Ул үлгәннән соң, әнинең хәле авырайды. Хәсрәт баса... Әти, молодец, бирешмәскә тырыша. Сыерларны да энекәшнең истәлеге итеп тота, дип уйлыйм. Шуңа да бетер дип, кырт кисмим.

Равил Мирсияповның дәрәҗәле исеме дә бар – РСФСРның атказанган механизаторы ул. 1974 елда Мәскәүдә «Москвич» машинасы тапшырганнар үзенә.

– Кыйммәтле бүләкләр, исемнәр, медальләр күп инде, – диде бабай. – Чистай районының Мактаулы гражданины мин. Алтмыш яшьлек юбилеема районнан да җиңел машина бирделәр. Шул вакытта район җитәкчесе: «Машина биреп пенсиягә озатмыйбыз, чөнки син әле тагын күп еллар эшләргә тиешсең. Ә бу бүләк – сине хөрмәт иткәнгә күрә», – диде. Тәки җитәкче сүзен тыңладым бит. Лаеклы ялга чыкканга октябрьдә егерме биш ел була, тагын бер биш ел эшлим әле, Алла боерса...

Мирсияповлар гаиләсендә барысы да комбайнчы. Әлфия апа дистә еллар ире белән бергә – комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгән. Ике уллары да гел шул хезмәттә булган. Хәтта кызлары Рокыя да энеләре армиядә булганда әтисе белән көзге урып-җыюда катнашкан.

КАЙДА ҖИҢЕЛ?

Кзыл Яланның гаҗәеп бер урыны бар – Талкыш елгасы башланган җир. Күл кебек, түп-түгәрәк ул. Тирә-ягын куаклар басып алган. Шунда ук кыр-болын җәелеп китә. Кыскасы, авыл халкына ял итәр өчен урын эзләп ерак йөрисе түгел. Кзыл Ялан үзәнлеккә урнашкан. Берәр метр казуга ук, су чыга икән. Җирне казып, үзләренә күл ясаучы гаилә дә бар. Җәен анда су коеналар, хәтта балыклар үрчетәләр. Бу тырыш кешеләр – Шәйхетдиновлар гаиләсе. Аларның ихатасын күрдек тә шаккаттык. Яшәү өчен моннан да матуррак урын бармы икән? Нәкъ Талкыш елгасы янында...

– Үзем дә көн саен шушы матурлыкка сокланам, бигрәк тә җәйләрен, – ди хуҗабикә Дания Шәйхетдинова. – Эштән бушаган арада, әлбәттә. Быел әле җиңелрәк, сыер саварга, техника йөртергә кеше алдык.

Дания апага күптән түгел ТРның Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре исеме биргәннәр. Үзенең крестьян-фермер хуҗалыгы бар. Тормыш иптәше Рафаэль абый белән бер кыз, бер ул тәрбияләп үстергән. Раил дә КАИның икътисад факультетын тәмамлагач, әти-әнисе янына кайткан. Яшь егет дәүләттән грант алып, фермер булып теркәлгән. Ана белән улның бүген икесенә ике хуҗалык. Дөрес, ул рәсми төстә генә инде. Йөз баштан артык хайваннары да бергә тора, 350 гектар җирне дә бергә эшкәртәләр.

– Фермер булып 2012 елда теркәлдем, – диде Дания Шәйхетдинова. – Ул елны миллион ярым сум грант алдым. Аңа техника сатып алдык. Ферманы үз акчабызга салган идек. Әлбәттә, ирем Рафаэль белән эшлибез. Мин белемем буенча икътисадчы, Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтын тәмамладым. Нигездә, документ эшләрен мин алып барам. Җир эшкәртү, чәчү-уру, малларны карау – барысы да ирем өстендә. Һөнәре буенча инженер ул. Улыбыз да җәй буе әтисе белән басуда булды, печән чабу, иген җыю... Югары белем алгач та, авылга кайтам, диде. Без каршы килмәдек. Авылда рәхәтләнеп эшләргә була.

Шәйхетдиновларның урыны мал асрау өчен шулкадәр уңайлы ки, фермер булмый мөмкин түгелдер. Бакчалары болынга терәлеп үк тора. Көтү йөртер өчен менә

Җирне казып, үзләренә күл ясаучы гаилә дә бар. Җәен анда су коеналар, хәтта балыклар үрчетәләр.

Шул ук «сыйныфта» авыл музее да урнашкан.

– Станокта бәйләргә өйрәтергә төрле семинарларга, Сабантуйларга йөрим, – ди Линара Мөэминова.

дигән урын. Су янәшәдә генә. (Ул җирләрне үзләренә арендага алганнар.)

– «Яшь фермер» программасы буенча 2017 елда 3 миллион сум грант алдым, – диде Раил. – КАИның икътисад факультетын тәмамладым мин. Шәһәрдә калырга уйламадым да. Егерме меңгә селкенеп йөргәнче... Үзе грант алгач, әни аның тәртибен белә. Документлар белән булышты. Ул акчага трактор алдык. Җир эшкәртү өчен безнең хәзер барлык техникабыз да бар.

– Яшьләргә фермер булып теркәлү авырмы? – дим.

– Бер җирдә дә җиңел түгел. Дәүләт ярдәме булмаса, техника ала алмыйсың, дип уйлыйм. Мисал өчен, әни грант алган 2012 елда тракторны 600 мең сумга сатып алдык. Быел ул 1 миллион 600 мең сумга якын. Үз акчаңа гына ничек аласың? Әле бит бер трактор белән генә эш бетми, аңа тагын җайланмалары да кирәк. Шуңа күрә грант алудан курыкмаска кирәк. Беренче елда булдырып булмаса, киләсе елга тырышып карарга кирәк. Артыннан йөрергә туры киләчәк, әлбәттә. Тик, әйтәм бит, кайда җиңел?!

ТАТАР АВЫЛЫНДА БАШКОРТ КЫЗЫ

Кзыл Ялан башлангыч мәктәбе бинасында авыл клубы да урнашкан, дип искәртеп узган идем. Аның җитәкчесе – Линара Мөэминова. Башкортостанның Баймак районы, Карамалы авылы кызы ул. Тормыш иптәше Илнур белән Сургут шәһәрендә танышканнар. Гаилә корганнан соң, 2011 елда Кзыл Яланга кайтканнар. Ике ул үстерәләр.

– Белгечлегем буенча укытучы мин, – диде Линара. – Мәктәпкә укытучы кирәкмәгәч, клубка эшкә кердем. Авыл кешеләрен, балаларны ничек кызыксындырырга? Иң беренче шул турыда баш ваттым. Һәм уйлап таптым да – станокта бәйләү түгәрәге оештырырга! Урындык япкычлары, идәнгә палас, намазлыкка кадәр бәйләп була. Балаларны да, өлкәннәрне дә җәлеп итәргә кирәк. Дөрес уйлаганмын, бүген безне тирә-як авылларда, республикада да беләләр. Станокта бәйләргә өйрәтергә төрле семинарларга, Сабантуйларга йөрим. Россиянең төрле шәһәрләренә дә алып чыгалар.

– Ә станокта бәйләргә кайчан өйрәндең? – дим.

– Кияүгә чыккач. Каенанам да башкорт кызы. Каената белән алар да Сургутта танышканнар. Һәм яшәргә Кзыл Яланга кайтканнар. Нәкъ безнең язмыш инде... Дөрес, каенанам алай заказга бәйләмәгән, вакыты да булмаган инде аның. Ә мин көн саен бәйлим. Ике сәгатьтә зур бер урындык җәймәсе эшләп чыгам.

Станокның размерлары төрле. Аны Линараның тормыш иптәше Илнур үзе ясый икән. (Хәтта ясап сата да). Хобби дип башланган эш менә шулай, ипилек-тозлык булса да, акча да китерә башлаган.

– Бәйләү түгәрәгенә килгән апалар белән бик күңелле, – ди Линара. – Клубның бит әллә нинди җиһазлары юк. Ә бу очрашып, аралашу өчен дә бер форсат. Балалар да кул эшенә яратып өйрәнә. Бәйрәмнәргә концерт та әзерлибез. Үзебезгә күрә тырышабыз, мәдәният учагын сүндермәскә омтылабыз.

...Нурлы бу авыл. Гади, кунакчыл кешеләренең йөзләрендә самимилек, җылылык бар. Бер гасырлык тарихына да күп калмаган Кзыл Ялан авылы шул нурын киләчәктә дә югалтмасын иде.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Кзыл Яланның исеме «алан» сүзе белән бәйле. Биредә ачыклык булган. Кып-кызыл чәчәкләр үскән. Шуны күреп кешеләр яңа оешкан авылны «Кызыл алан» дип йөртә башлаган. Ләкин ни өчендер документларда «Кзыл Ялан» дип язганнар. (Күрәсең, руслар шундый атама биргән). Өлкән кешеләр аны күбрәк «Кызыл Алан» дип йөртте.

Татар Талкышы борынгы, бик зур авыл булган. Патша власте бетерелгәч, 1930 елда, авылның күп кешеләре төрле якка күченеп утырган. Шул елларда якын-тирәдә берничә авыл барлыкка килгән, шул исәптән Кзыл Ялан да. Халык Татар Талкышыннан үз йортлары белән күченгән. Бер хуҗалыкка 30 сутый җир бүлеп бирелгән. Бүген дә ул нигезләр исән, бары тик яңартылган гына.

Рәмзия Сафина, Татар Талкышы авылы җирлеге башлыгы урынбасары.

НОМЕР КӘЕФЕ: ШАУ ЧӘЧӘКЛЕ МАЙ АЕ

2019 елның мае, аннан алдагы 74 елның майлары кебек үк... ап-ак чәчәкле булды. Агачларда яшел бөреләр яфрак ярырга да өлгермәде, ул арада алар алмагач, чия, шомыртларның ап-ак чәчәкләренә күмелде... Иң очларыннан башлап, тамырларына кадәр ак чәчәктә агачлар. Ел саен безгә шундый чәчәкле яз килә, һәм ел саен безне үзенең илаһи гүзәллеге белән таң калдыра – карап, сулап, фотога төшереп туя алмыйбыз!

Май төсе – Җиңү төсе, безнең ветераннарның чал чәчләре төсе, яңа иркле тормыш башлану төсе. Безнең җиңүчеләребезгә бу гүзәл май өчен дә, барлык киләсе май айлары өчен дә зур рәхмәт!

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

1980 нче еллар. Нәшрият бинасы.